М. И. Мәхмутов, К. З. Хәмзин, Г. Ш. Сәйфуллин

# ГАРӘПЧӘ-ТАТАРЧА-РУСЧА АЛЫНМАЛАР СҮЗЛЕГЕ

(ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА КУЛЛАНЫЛГАН ГАРӘП ҺӘМ ФАРСЫ СҮЗЛӘРЕ)

М. И. Мәхмүтов төзегән гарәп теле грамматикасы белешмәсе кушымта итеп бирелде

II том

«Иман» нәшрияты
Казан 1993

М. И. Махмутов, К. З. Хамзин, Г. Ш. Сайфуллин

# АРАБСКО-ТАТАРСКО-РУССКИЙ СЛОВАРЬ ЗАИМСТВОВАНИЙ

(АРАБИЗМЫ И ФАРСИЗМЫ
В ЯЗЫКЕ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ)

С приложением
справочника по арабской грамматике,
составленного М. И. Махмутовым

II том

Издательство «Иман»
Казань 1993

Редакторлары:

*Р. С. Газизов,*
*М. Г. Гыймадиев, И. Г. Гыйльфанов*

# ТӨЗҮЧЕДӘН

80 нче елларның уртасында җәмгыятьтә башланып киткән демократизация процессы Россиядәге рус булмаган халыкларның милли хәрәкәтенә киң юл ачты. 1991 нче елны Татарстан суверенитеты турында Декларация кабул итү милли мәдәниятне торгызу эшендә яңа этап булды; тел, әдәбият тарихы һәм татар халкының үзенең чын тарихы тирәнтен өйрәнелә башлады.

Татар галимнәре үз язмышлары һәм басма хезмәтләре өчен борчылмыйча гына эшли башладылар; алар татар һәм гарәп мәдәнияте мөнәсәбәтләре тарихы, Ислам дине мәсьәләләре буенча китап-мәкаләләрен ачыктан-ачык мәйданга чыгара башладылар. Татар мәктәбен торгызу, яңарту һәм ана телендә укыту өчен кызу эш башланды.

...Мең елга якын татарлар гарәп язуыннан файдаланалар, милли мәктәпләре җитәрлек күп була, XX йөз башында, башка халыклар белән чагыштырганда, Россиядә иң укымышлы халыкларның берсе була. Ләкин 20—30 нчы елларда милли мәдәният зур зыян күрә: халыкның теләге белән исәпләшмичә, ике мәртәбә алфавит алмаштырыла, өлкән буынны ана телендә надан калдыралар, яшь буынны элекке бай әдәби мирастан аералар, мәхрүм итәләр. Гасырга якын коммунистлар партиясе тарафыннан Ислам мәдәниятен эзәрлекләү нәтиҗәсендә милли традицияләргә сусаган халык, рухи таланганлыгын сизеп, озак еллар тыелып торган дини китапларга сузыла.

Лексикасыннан меңләгән гарәп сүзе һәм гыйбарәләре алып ташланган татар теленә бүген игътибар артты. Элекке вакытта «гарәп» дигәнне надан чиновниклар күрә алмаганнар: алар аны бай Ислам мәдәнияте татар теленә, халыкның культурасы үсешенә, китап, язу таралуына гаять көчле (һәм заманасына күрә прогрессив) йогынты ясаган, мәгърифәт китергән Ислам культурасы белән түгел, фәкать дини йолалар белән генә бәйләп аңлаганнар. Хәтта гарәп хәрефләрен мыскыл итеп «комган хәрефләре» дип йөрткәннәр.

Мәгълүм ки, барлык телләрнең дә үсеш тарихы башка телләрдән сүзләр алу шикелле объектив күренеш белән нык бәйләнгән. Бу күренеш татар әдәби теле тарихына да карый. Башка телләрдән кергән күпсанлы алынмалар катламында гарәп һәм фарсы телләреннән алынганнары да шактый урын алып тора. Бу алынмаларның күп гасырларга сузылган тарихы бар. Аларның күбесе әдәби телдә генә түгел, бәлки халыкның гарәп-фарсыны үз сүзе итеп аңлаган (кабул иткән) сөйләм телендә дә киң кулланыла. Мисал өчен, китап, дәфтәр, хат, мәктәп, иман, сабый, сабыр, вөҗдан, намус, каләм, сандык һәм меңләгән шуңа охшашлы көн дә кулланыла торган сүзләр татар сүзләре түгел дип, кем генә әйтә алыр икән?

XX йөзнең башына чаклы булган әдәби әсәрләр телендә (китап телендә) гарәп-фарсы сүзләре татар телендә җитешмәгән сүзләр өчен

генә түгел, хәтта татар телен чупли торган һәм аны аңларга кыенлаштырган, төп үз сүзләре урынына да кулланылган. Ләкин XX йөз башында алынмаларның артыграк өлеше саф татар сүзләре белән алмаштырылган. Калган алынмалар фән һәм әдәби телебезнең совет чоры үсеше башланганчы киң кулланышта булалар.

Соңгы ярты гасыр эчендә элек киң күләмдә кулланылган бу гарәп-фарсы сүзләренең күпчелеге татар теленең үз сүзләре, рус һәм интернациональ сүзләр белән алыштырылдылар. Татар теленә бик кирәкле булган меңләгән сүз һәм сүз тезмәләре алып ташланды. Әдәби телебезнең үсешендә мондый үзгәреш эзлеклелек принцибын җимерде, телне ярлыландырды, ул чор әдәбиятын укуда зур гына читенлек тудыру гына түгел, кешенең хәтта фикерләү сәләтенә дә тискәре йогынтысы булды шикелле.

Татар теленең югалткан сүз байлыгын, теле һәм әдәбиятының милли колориты белән бәйле аның синонимикасын, идиоматик тәгъбирләрен кире кайтару һәм торгызу өчен күп еллар тырышлык күрсәтергә кирәк булыр. Моның өчен халыкны фәнни һәм методик әдәбият белән, мәктәп дәреслекләре, сүзлекләр һәм белешмәләр белән тәэмин итәргә зарурдыр.

1965 нче елны бик зур кыенлыклар белән бастырылган «Гарәп-фарсы алынмалар сүзлеге» милли мәдәниятне советлаштыру процессында бай лексикасы таланган татар теле өчен сүз байлыгы хәзинәсе булды. Ул киң катлау укучылар, укытучылар, студентлар, тәрҗемәчеләргә, әдәбият һәм матбугат өлкәсендә эшләүчеләргә, фән әһелләренә югарыда әйтелгән читенлектән чыгуга ярдәм итүче белешмә-сүзлек итеп төзелде. Аннан файдаланучылар арасында рус телен татар теленә караганда яхшырак белүчеләр булуны искә алып, һәм иске әдәбиятны русчага тәрҗемә итүчеләрнең хезмәтен җиңеләйтү нияте белән, сүзләрнең тәрҗемәсе татар һәм рус телләрендә бирелде.

Сүзләр XIII йөз шагыйре Кол Галидән башлап хәзерге чор шагыйрь әдипләренең әсәрләреннән, шулай ук торле фәнгә караган дәреслекләрдән, элекке чор вакытлы матбугатыннан чүпләп тупланды.

Сүзлеккә, белешмә сүзлек булганга, сүз берәмлеге булган сүзләр генә түгел, әдәбиятыбызда очраган сүз тезмәләре, әйтем һәм мәкаль тосендәге катып калган гыйбарәләр дә кертелде. Сүзләр сүз берәмлеге булган төп формаларында гына алынмады, бәлки әдәбиятта очраган грамматик формаларында да, артикль, бәйлек, зат кушымчалары һ. б. белән бергә килгән хәлендә дә алынды. Мондый сүзләр, татарлар тарафыннан бер сүз итеп үзләштерелгәнлектән, күп очракта кушылып язылалар. Мәсәлән, би-әл-илтифат = билилтифат. Сүзлеккә сүзләр һәм сүз тезмәләре хәзерге татар алфавиты тәртибендә урнаштырылды. Ләкин шуның янында ук шул сүзнең гарәп хәрефләре белән дә (гарәп орфографиясе нигезендә) язылышы күрсәтелде.

Алынмаларга сүзгә-сүз мәгънә бирү белән берләттән, аңлатмалы сүзлекләрдәгечә, аңлатулар һәм, кирәк тапканда, әдәбияттан алынган мисаллар да бирелде. Мисаллар сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен китерү белән бергә, әдәбиятта куллану барлыгын, сүзне бозып яки ясап куллану барлыгын, бик борыннан кулланылуын, яки хәзерге чорда да кулланылуын һ. б. күрсәтү өчен дә китерелделәр; файдаланучыларның

эшен жиңеләйтү өчен мисалларның күпчелеге соңгырак чор, XIX йөз азагы һәм XX йөз башы әдәбиятыннан алындылар.

Сүзлеккә кергән күплек санындагы сүзләр, сүзлектә берлек саны булса, тәрҗемә ителмәде, берлегенә юнәлтелде, берлеге сүзлектә булмаса, яки берлегендә булмаган өстәмә мәгънәсе булса, аларга тәрҗемә бирелде. Мәсәлән, мотәгалликат-ис.— 1) Мотәгалликъның күплеге. 2) Якыннар, кардәшләр. 3) грам. Җөмләнең иярчен кисәкләре; Лосус-ис. к. Караклар (берлеге сүзлектә юк).

Бер үк сүз мөзәккәр (м. р.), моәннәс (ж. р.) формасында килгәндә, мәгънәләрендә аерма булмаса, моәннәсе тәрҗемә ителми, мөзәккәренә юнәлтелә, мәсәлән, балига-кара: балигъ. Сүзләрнең русча мәгънәләре дә татарча мәгънәләреннән чыгып бирелде.

Мисаллар, татарча мәгънәгә иллюстрация булганлыктан, русчага тәрҗемә ителмәделәр. Төп сүзне иллюстрацияләүче сүз тезмәләре, идиомалар, лексик берәмлек булганлыктан, русчага тәрҗемә ителделәр. Мәсәлән, **Кәбаир** мн. от Кәбир. Гонахе кәбаир—«грехи великие» дип тәрҗемә ителде.

Татар теленә кергән гарәп һәм өлешчә фарсы алынмаларының грамматик үзенчәлекләре турында сүзлеккә өстәмә итеп «Гарәп теле грамматикасы белешмәсе» бирелде.

Сүзлеккә материал җыю 1940 нчы елларда башланып, таррак күләмдә 1946 елда ук тәмам була язса да, торле сәбәпләр аркасында (төзүчеләрнең берсе шул вакытларда ук мәрхүм булды, икенчесе милләтчелектә гаепләнеп кулга алынды) сүзлекне матбугатка чыгару мөмкин булмады. Эш тик 1956 нчы елда гына башланды, һәм СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалының тел, әдәбият һәм тарих институтының Гыйльми советы ярдәмендә дәвам иттерелде. Ләкин аны тәмамлауга һәм рәсми шәхесләрнең шундый сүзлекне чыгару идеясенә каршылыгын җиңеп, гарәп хәрефләрен эзләп табуга (Мәскәүдә генә табылдылар), сүзлекне бастырып чыгаруга күп вакыт сарыф ителде. 30 елга якын элек чыккан сүзлек хәзер сирәк табыла торган китапка әверелде.

Сүзлекне төзегәндә фәнни һәм әдәби әсәрләрдән тыш, төзүчеләр беренче басмада исемләп күрсәтелгән элек төзелгән башка сүзлекләрдән дә файдаландылар. Автор Сүзлекнең икенче басмасын хәзерләргә ярдәм иткән өчен Дилара Шакировага һәм китапны мәйданга чыгарышучы Винерулла Якуповка үзенең рәхмәтен белдерә.

Сүзлекнең яңа басмасы галимнәргә халыкның бай тарихын һәм мәдәни мирасын иске чыганаклардан өйрәнергә, борынгы татар һәм гарәп телләре белән кызыксынучыларга ярдәмлек булыр дип ышанасы килә.

Мирза МӘХМҮТОВ

*мәрданә кердем, ник нә арам кирәк* (Сайяди).

**Никях*** نیکاح *м. III.* Өйләнү, өйләнешү. — *м. III.* Женитьба, брак, бракосочетание.

**Нилуфәр** نیلوفر *ф. ис.* Төнбоек. — *п. сущ.* Водяная лилия. (цветок).

**Ним** نیم *ф. ис.* Ярты, ярым. — *п. сущ.* Половина.

**Ним сабый** نیم‌صبی *гф. ст.* Ярты сабый, ярты бала. *Ним сабыйдыр ул, сабыйлык көннәрен бик сагына.* (Дәрд.) — *ар.-п. сс.* Дитя.

**Ниса** نسا *ис. к.* Хатыннар, хатынкыз. — *сущ. мн.* Женщины.

**Нисаб** نصاب *ис.* 1) Башлангыч, нигез. 2) *дини* Зәкят бирерлек үлчәүдәге мал күләме. *Милке там белән нисабка малик булмактыр.* (К. Нас.) 3) Пычак (кылыч) сабы. — *сущ.* 1) Начало, основа. 2) *рел.* Ценз (имущественный). 3) Рукоятка, ручка.

**Нисан** نیسان *ф. ис.* 1) Апрель ае. 2) Апрель яңгыры — ләйсән. *Яз булды, нисан ява пыскып карлар.* (Дәрд.) — *п. сущ.* 1) Апрель. 2) Апрельский дождь.

**Нисар** نثار *ис.* 1) Чәчү, сибү, тарату. 2) Туйда чәчелгән акча. *Алтын-көмеш, энҗү-мәрҗән нисар кылды.* (К. Гал.) — *сущ.* 1) Рассеивание, рассыпание, разбрасывание. 2) Деньги, рассыпаемые (по мусульманскому обычаю) на свадьбе.

**Нисаэ** نسا *кара:* ниса. — *см.* Ниса, нисван.

**Нисби*** نسبی *сф.* Чагыштырма(ча). — *прил.* Относительный.

**Нисбәт*** نسبت *ис.* 1) Бәйләнеш, мөнәсәбәт. 2) Тиңләштерү, чагыштыру. *Электрик заманнары килмеш, мәгънәви яктылыклар да шул нисбәттә алга китмеш.* (З. Һад.) 3) Пропорция. — *сущ.* 1) Отношение; связь. 2) Соотношение. 3) Пропорция.

**Нисбәтән** نسبةً *р.* Тиңләштереп карaганда, чагыштырганда. — *н.* Относительно.

**Нисван** نسوان *ис. к.* Хатыннар, хатын-кыз. — *сущ. мн.* Женщины.

**Нисвәт** نسوة *кара:* нисван. — *см.* Нисван.

**Нисыф** نصف *ис.* Ярты, ярым. *Гарәпләр көррәи әрызның там нисфына хаким улмышлар.* (Г. Ибр.) — *сущ.* Половина.

**Нисфе ләел** نصف‌لیل *гыйб.* Төн уртасы (кич яртысы). — *фр.* Полночь.

**Нисфе нәһар** نصف‌نهار *гыйб.* Төш вакыты, көн уртасы. — *фр.* Полдень.

**Нисьян** نيسيان *м. I.* Онытучанлык, хәтердән чыгару, истә тотмау. — *м. I.* Забывчивость.

**Нитәк, нитәкки, нитәккем** نيته كم ، نيته‌كى ، نيته‌ك *ф. р.* Ничек, ни рәвешле, кебек. *Нитәкки вагыйзьләр вәгазь арасында мөнәсәбәтле хикәяләр китереп.* (К. Нас.) — *п. н.* Как, каким образом, подобно.

**Нифак** نفاق *м. III.* Тыштан яхшы булып, эчтән әшәкелек; икейөзлелек, монафикълык, күз буяучылык, алдакчылык. *Нифак выставкасында күп медаль алганымыз бардыр.* (Г. Тук.) — *м. III.* Лицемерие, притворство, обман.

**Нифас** نفاس *м. III.* 1) Бала тудыру. 2) Аналык каны, бала тудырганнан соң килә торган кан. *Дашкин: „Анда хәез-нифас турында сорамаслар“, — диде.* (Г. Ибр.) — *м. III.* 1) Разрешение от бремени, роды. 2) Послеродовое кровотечение.

**Нихрир** نحرير *ис.* Күп белүче, атаклы галимгә бирелә торган исем. *Ибне Сина исламнарның фәүкылгадә бер нихрирләре, бер мөәллифләре мабиһил ифтихарлары улан надир бер галимнәре иде.* (Ш. ж.) — *сущ.* Весьма знающий, выдающийся (эпитет ученого).

**Нишадир** نيشادر *ис.* Нишатыр (нашатырь). — *сущ.* Нашатырь.

**Нишан** نشان *ис.* 1) Билге, тамга, эз, галәмәт. *Һич калмады шаннан нишан, калды дингә дошман ишан.* (Г. Тук.) 2) Мишень, цель. 3) Егет белән кызның бер-беренә биргән вәгъдә бүләкләре (балдак). 4) Орден; аеру (аерымлык) билгесе. — *сущ.* 1) Метка, след, знак. 2) Цель, мишень. 3) Обручальное кольцо. 4) Орден; знак отличия.

**Нишин** نشين *ф. ис.* Эш башында торучы дигән мәгънә бирә торган ярдәмче сүз. **Тәхет нишин** — тәхеттә утыручы; **садыр нишин** — башта торучы. — *п. сущ.* Модальное слово, придающее смысл „стоящий во главе...“.

**Ништәр** نيشتر *ф. ис.* Хирургия пычагы, кан алучының тамыр кисү пычагы. *Хәҗҗәм аның тамырына ништәр орса.* (К. Гал.) — *п. сущ.* Ланцет, скальпель.

**Ниябәт** نيابت *ис.* 1) Вәкиллек. 2) Урынбасарлык. — *сущ.* 1) Представительство. 2) Замещение.

**Нияз** نياز *ф. ис.* Үтенү, үтенеп сорау, ялыну, ялвару. *Һөрмез шаһга бер* — *п. сущ.* Просьба, мольба.

*җарияне җибәреп, хөҗрәсенә килмәкне нияз итте.* (К. Нас.)

**Ният*** نيت *ис.* Ңият, теләк, максат.
*сущ.* Намерение, цель.

**Ниһал** نهال *ф. ис.* Агач үсентесе. *Сәрве ниһал* — кипарис үсентесе (ботагы). *Булды ул кыз һәм җанан сәрве ниһал.* (Мөхм.)
*п. сущ.* Молодое деревцо, побег растения.

**Ниһан** نهان *ф. с.* Яшерен, серле.
*п. прил.* Тайный, скрытый.

**Ниһаять* ниһая** نهايه ، نهاية *ис.* 1) Соң чик. 2) Ахыр чиктә, соң дәрәҗәдә.
*сущ.* 1) Конец, предел, окончание. 2) Наконец.

**Ногман** نعمان *ис.* Лалә чәчәге.
*сущ.* Тюльпан.

**Нократ** نقرات *ис. к.* 1) Болгар дәверендә сугылган вак көмеш акча. 2) Вятка елгасының элекке исеме. 3) *кара:* нокрә.
*сущ. мн.* 1) Монеты, отчеканенные в эпоху Булгарского царства. 2) Название р. Вятки. 3) *см.* Нокрә.

**Нокрә** نقره *ис.* 1) Эретелгән көмеш кисәге. 2) Кечкенә чокыр.
*сущ.* 1) Кусок расплавленного серебра. 2) Ямка.

**Ноксан** نقصان *ис.* Кимчелек, житешсезлек. *Агач рәкыс итмәмәк шагыйрь улан инсанә ноксандыр.* (Г. Тук.)
*сущ.* Недостаток, порок.

**Нокта*** نقطه *ис.* Төртке.
*сущ.* Точка.

**Нокта бәнокта** — хәрефкә-хәреф.
Точка в точку; буква в букву; точь -в- точь.

**Ноктаи назар** نقطهٔ نظر *гыйб.* Караш, берәр нәрсәгә караш.
*фр.* Точка зрения.

**Нокыз** نقض *ис.* Җимерекләр, хәрабәләр; ватыклар; таш ватыклары.
*сущ.* Развалины, руины; обломки; битый камень.

**Нокыл** نقل *ф. ис.* Закуска, шәрап эчкәндә ашый торган татлы аш. *Екет син бадә эчкел, нокыл ашагыл.* (Хорәз.)
*п. сущ.* Сласти, подаваемые к вину, конфеты, засахаренные фрукты.

**Носрәт** نصرت *ис.* 1) Ярдәм. 2) Өстен чыгу, җиңү, уңыш. *Сабыр соңында носрәт бар дип белгәй.* (К. Нас.)
*сущ.* 1) Помощь. 2) Победа, успех.

**Нотфә** نطفه *ис.* 1) Тамчы. 2) *биол.* Нәсел орлыгы, мәни.
*сущ.* 1) Капля. 2) *биол.* Семя, сперма.

**Нотык** نطق *ис.* Хотбә, речь, чыгыш (җыелышларда). *Шул рәвеш нотыкын бетергәчтен ләгыйн, шау кубалар: „яшәсен!.. Амин! Амин!“* (Ш. Баб.)
*сущ.* Хотба; речь, выступление.

**Нохусәт** نحوست *ис.* Бәхетсезлек, уңышсызлык, кара бәхетлелек. *Йөзигә михнәт кирде вә нохусәт тузан ки ултырмыш.* (Мәҗмәгыл хикәя≀ь.) — *сущ.* Злополучность, злосчастье, пагубность.

**Нун** نون *ис.* „Н" хәрефенең исеме. — *сущ.* Название буквы „н".

**Нур*** نور *ис.* Яктылык, ялтыравык. — *сущ.* Свет, блеск.

**Нурани** نورانی *с.* Нурлы, якты, ялтыравыклы. — *прил.* Светлый, ясный, блестящий.

**Нурдидә** نوردیده *гф. ис.* 1) Күз нуры. 2) Кызлар исеме. — *ар. -п. сущ.* 1) Свет очей. 2) Имя собственное (женское).

**Нурын галә нур** نورعلی‌نور *гыйб.* Нур өстенә нур. *Качан кисәң, нурын галә нур улыр имди.* (К. Гал.) — *фр.* Свет к свету — в смысле: было хорошо, стало лучше.

**Нуш** نوش *ф. ис.* 1) Эчкелек, татлы эчемлек, эчә торган нәрсә. 2) Ләззәт. *Эчеп гамь парәсен кылып нуш-нуш...* (К. Гал.) — *п. сущ.* 1) Питьё, сладкий напиток. 2) Сладость; наслаждение.

**Нуша-нуш** نوشانوش *ф.* Кат-кат эчү, күп тапкыр эчү. *Нәшат вә гыйш нуша-нуш кылгыл.* (Хорәз.) — *п.* Глоток за глотком.

**Нәбат** نبات *ис.* Үсемлек, үлән. *Бәс нәбат дигән сүз гарәпчә булып, гомумән җирдә һәрбер тамырдан үсеп чыккан нәрсәне һәммәсен шамилдер.* (К. Нас.) — *сущ.* Растение, флора; растительность, трава.

**Нәбатат** نباتات Нәбат-ның *к.* *Гыйлеме нәбатат дирләр, бер фәндер ки җир йөзендә үскән һәртөрле агачларны вә үләннәрне бәян кыйлучы бер гыйлемлектер.* (К. Нас.) — *мн.* от нәбат.

**Нәбати** نباتی *с.* Үсемлек(кә караган), үсемлек(кә бәйләнешле). — *прил.* Травяной; растительный, ботанический.

**Нәббаш** نباش *ис.* Кабер талаучы. *Ул нәббаш әйтте: „Гомеремдә мең кабер таладым".* (К. Нас.) — *сущ.* Разрывающий могилы для грабежа; грабитель.

**Нәбза** نبضه *ис.* 1) Тамырның бер тапкыр тибүе. 2) Тамыр тибү кадәр вакыт. — *сущ.* 1) Удар пульса. 2) Пульс (временнóе понятие).

**Нәбзә** نبذه *ис.* Бер бүлем, кисәк, парча. *Хәлебездән бер нәбзе.* (М. Гаф.) — *сущ.* Небольшое количество, кусок, частичка.

**Нәби** نبی *ис.* Пигамбәр. *Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәверан.* (Дәрд.) — *сущ.* Пророк.

**Нәбиз** نبيذ *ис.* Хөрмәдән ясалган эчемлек; ширбәт. *Мин сине нәбиз өчен сукмадым, исереклек өчен суктым, — диде.* (К. Нас.) — *сущ.* Финиковое вино; напиток, шербет.

**Нәбирә** نبيره *ф. ис.* Онык. — *п. сущ.* Внук.

**Нәбыз** نبض *ис.* Тамыр тибү. — *сущ.* Пульс, пульсация.

**Нәбүвәт** نبوت *ис.* Пигамбәрлек. *Нәбүвәт изгесе һәм исраилсән.* (К. Гал.) — *сущ.* Пророческая миссия, посланничество.

**Нәвадир** نوادر *ис. к.* 1) Сирәк очрый торган нәрсәләр. 2) Мәзәкләр. *Әсмагый әйтте: „Нәвадир, ягъни мәзах сөйләмәк зиһеннәрне шаяртыр, колакларны ачар".* (К. Нас.) — *сущ. мн.* 1) Редкости; редкие вещи. 2) Анекдоты; смешные рассказы.

**Нәвадират** نوادرات Нәвадир-ның *к.* *Мәгълүм ула ки нәвадират хосусында галахидә бу бер рәүзадыр.* (К. Нас.) — *мн.* от нәвадир.

**Нәвал** نوال *ис.* 1) Өлеш. 2) Бүләк, бирелгән әйбер. — *сущ.* 1) Доля, часть. 2) Дар, подарок, даяние.

**Нәвамис** نواميس *ис.* Намус-ның *к.* — *мн.* от намус.

**Нәвахи** نواحى Нахия-ның *к.* *Сөләйман Мусин нәвахисендә күп фәсадлар кылды.* (К. Нас.) — *мн.* от нахия.

**Нәваһи** نواهى Нәһи-нең *к.* — *мн.* от нәһи.

**Нәвем** نوم *ис.* Йокы. — *сущ.* Сон.

**Нәгамь** نعم *кис.* Әйе, шулай, дөрес. *Шаһзадәнең ля вә нәгамь димәгә мәҗале калмады.* (К. Нас.) — Частица утверждения — да, да так; правильно.

**Нәгяһан** نگاها *ф. р. кара:* нагяһан. — *п. н. см.* Нагяһан.

**Нәгузе биллаһи** نعوذبالله *гыйб. дини* Аллага сыенабыз; алла сакласын. *Нәгузе биллаһи, мөртәт булып китеп.* (З. Биг.) — *фр. рел.* Боже упаси! (мусульманская формула).

**Нәгъмә** نغمه *ис.* Көй, җыр, моң. *Сазының кыллары арасыннан яныл, елап чыга торган нәгъмәләр...* (Ш. Кам.) — *сущ.* Мелодия, напев.

**Нәгъмә саз** نغمهساز *гф. ис.* Көйләүче, җырлаучы. — *ар. -п. сущ.* Певец, поющий.

**Нәгърә** نعره *ис.* Ачы, каты тавыш, акырыш-бакырыш; мөгрәү. *Нәгърәләр берлән диюне уйгата.* (Г. Тук.) — *сущ.* Шум, крики; рёв, мычание.

**Нәгыз** نغز *ф. с.* Яхшы, гүзәл, әйбәт, шәп. — *п. прил.* Красивый, милый, приятный, изящный, чудесный.

**Нәгыйм** نعيم *ис.* Нигъмәт, муллык, киң тормыш. — *сущ.* Благоденствие; блаженство, изобилие.

**Нәгыль** نعل *ис.* 1) Аяк киеме, башмак. 2) Ат дагасы. — *сущ.* 1) Башмаки, лёгкая обувь. 2) Подкова.

**Нәгыш** نعش *ис.* 1) Эчендә үлек ята торган табут. 2) Күмәр өчен табутка салынган үлек, мәет. 3) Җеназа. *Тик мин үлгәчтен карагыз типмәсеннәр нәгышемә.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Гроб с покойником. 2) Покойник. 3) Погребальные носилки; катафалк.

**Нәдамәт** ندامت *ис.* Үкенү, үкенеч. *Гаҗизлектән сөкут кылып, сәламәт булмакың, соңыннан нәдамәт китерүче сүздән хәерледер.* (К. Нас.) — *сущ.* Раскаяние.

**Нәдбә** ندبه *ис.* Яра эзе, яра билгесе. — *сущ.* Порез, шрам, рубец.

**Нәдвә** ندوه *ис.* Киңәшмә, җыелыш, съезд. — *сущ.* Совещание, собрание; съезд.

**Нәдем** ندم *ис.* Үкенү. — *сущ.* Раскаяние.

**Нәдим** نديم *ис.* 1) Бергә яшәүче иптәш, мәҗлестәш, эчкедәш. 2) Матур сүзләр, гүзәл хикәяләр сөйли ала торган кеше. 3) Бер зур кешегә матур хикәяләр сөйләп күңелен ачучы, кәефләндерүче кеше. *Солтан Мөхәммәт үзенең нәдимнәреннән Әхмәт Мәүләвигә боерды.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Приятель, собеседник, собутыльник. 2) Рассказчик смешных историй. 3) Приближённый.

**Нәдрәт** ندرت *ис.* Азлык, сирәклек. *Һәрбер хатында һаман талак кылмакны дагый булган мәкрүһ халь табылыр, бәлки нәдрәт салих булганнары да бар.* (К. Нас.) — *сущ.* Редкость, малость, небольшое количество.

**Нәзаир** نظائر *ис.* Нәзыйрә-нең *к.* — *мн.* от нәзыйрә.

**Нәзаиф** نظائف Нәзыйф-ның *к.* — *мн.* от нәзыйф.

**Нәзакәт*** نزاكت *ф. ис.* 1) Нәзакәт, матурлык, әдәплелек, аһәң нәфислеге. 2) Мөгамәләдә әдәплелек, нечкәлек. *Матур гөлләргә бул былбыл, нәзакәт багына сакчы.* (Дәрд.) — *п. сущ.* 1) Изящество, тонкость, грация. 2) Деликатность; такт, вежливость.

**Нәзар** نظر *ис.* 1) Карау, күз ату, күз салу, игътибар (итү). *Габдел Гафурның хәленә нәзар кылсак...* (З. Биг.). 2) Уйлау, төшенү, фикер йөртү. 3) Караш, уй. — *сущ.* 1) Внимание. 2) Рассуждение, соображение. 3) Взор, взгляд.

**Нәзари** نظرى *с.* 1) Теоретик. *Музыка хакында гасырлардан бирле саклап* — *прил.* 1) Умозрительный, теоретический. 2) Зрительный, оптический.

*килгэн игътикадыннач да нэзари рэвештэ хэбэре юк.* (Г. Ибр.) 2) Күз белэн күрү(гэ бэйлэнешле), оптик.

**Нэзарият** نظريات *ис.* 1) Теоретик мэгълүмат, теория. 2) *мат.* Теорема. — *сущ.* 1) Теория, доктрина. 2) *мат.* Положение, теорема.

**Нэзарэн** نظراً *р.* Караганда, карап, ... күрэ. — *н.* Смотря, глядя.

**Нэзарэт** نظارت *ис.* 1) Карау, күзэтү, контроль. 2) Идарэ итү, идарэ (урыны). — *сущ.* 1) Наблюдение, контроль. 2) Управление, заведывание.

**Нэзафэт** نظافت *ис.* Арулык, пакьлек. *Нэзафэткэ ригаять юк имеш бездэ, нэ бөһтандыр.* (Г. Тук.) — *сущ.* Чистота.

**Нэзаһэт** نزاهة *м. I.* 1) Мораль пакьлек, гыйффэтлелек. 2) Намуслылык, арулык, начар нэрсэлэрдэн ераклык. — *м. I.* 1) Чистота (моральная). 2) Честность, неподкупность, беспристрастность.

**Нэзгъ** نزع *м. I.* 1) Тартып алу, кубару. 2) Җан бирү (газабы). *Аз шат булып, аз көлгэн кеше халэте нэзгъдэ рэхэт табар.* (К. Нас.) — *м. I.* 1) Отнятие, лишение, удаление, устранение. 2) Агония.

**Нэзед** نزد *ф. бэй.* Ян(ында), каршы(нда), ал(дында). *Ит бэне нэзедеңдэ үлмэклэ сэгадэт наили.* (Г. Тук.) — *п. пред.* Близ, у, около, подле.

**Нэзер*** نذر *ис.* Ад.рыну, дини караштан чыгып үз өстенэ үзе алган эш, шартлы вэгъдэ. *Хэмидэнең дэ 25 тиен нэзере бар икэн.* (З. Һад.) — *сущ.* Обет, торжественное обещание.

**Нэзеф** نزف *м. I.* Канау, кан агу. — *м. I.* Кровотечение; истекание.

**Нэзир** نذير *ис.* Куркытучы, алда куркыныч барлыкны хэбэр итүче. *Бу ике эфэндеиең бэширлек вэ нэзирлек итүгэ хаклары барлыкка сүз эйтэ алмыйм.* (Ш. ж.) — *сущ.* Предвестник.

**Нэзлэ** نزله *ис.* Томау, суык тию; катар. — *сущ.* Простуда, воспаление, катар.

**Нэзыйр** نظير *ис.* Охшаш, тиңдэш, иш, үрнэк. *Нэзыйрсыз шагыйрь улдың, афэрин, Пушкин Александр!* (Г. Тук.) — *сущ.* Подобие, копия, образец, пример.

**Нэзыйрэ** نظيره *ис.* 1) Үрнэк, өлге. 2) Икенче бер шагыйрь шигыренэ охшатып язылган шигырь, пародия. — *сущ.* 1) Образец, образчик. 2) Подражание (в стихах), пародия.

| | |
|---|---|
| **Нәзыйф** نظيف *с.* Ару, пакь, пөхтә. | *прил.* Чистый. |
| **Нәзым** نظم *ис.* Тезмә, иҗекләре үлчәнгән, рифмалаштырылган сүзләр, шигырь. | *сущ.* 1) Стихотворение. 2) Стихи, поэзия. |
| **Нәзымән** نظماً *р.* Тезмә буларак, тезмәчә. | *н.* В рифмованном виде. |
| **Нәй** نى *ф. ис.* 1) Камыш. 2) Курай, камыш курай (уен коралы). | *п. сущ.* 1) Камыш, тростник. 2) Камышёвая дудка, свирель. |
| **Нәйзә** نيزه *ф. ис.* Сөнге, штык. | *п. сущ.* Копьё, пика, дротик, штык. |
| **Нәййир** نيير *с.* Нурлы. | *прил.* Светлый. |
| **Нәййирәен** نييرين *ис.* Ике яктырткыч, ике нурлы (ай, кояш). | *сущ.* Два светила (имеется в виду солнце и луна). |
| **Нәйран** نيران *ис.* Утлар; җәһәннәм уты. *Ризык чон янмасын кальбеңдә нәйран.* (Г. Тук.) | *сущ.* Огонь, адский огонь. |
| **Нәйшәкәр** نيشكر *ф. ис.* Шикәр камышы. | *п. сущ.* Сахарный тростник. |
| **Нәкавәт** نقاوت *м. I.* Пакьлек, чисталык, арулык, сафлык. | *м. I.* Чистота, чистоплотность. |
| **Нәкаиз** نقايض Нәкыз-ның *к.* | *мн.* от нәкыз. |
| **Нәкәр** نقار *ф. ис.* Әрләш, кычкырыш, дошманлык. *Идеп нәкарлек аны тәрвиҗ иттем.* (Ут. Им.) | *п. сущ.* Ссора, вражда. |
| **Нәкарә** نقاره *ис.* Уен коралы исеме. *Зарбе нәкар, быргу үкеш чалыныр имди.* (К. Гал.) | *сущ.* Литавры. |
| **Нәкаһәт** نقاهة *ис.* 1) Авыру сәбәпле хәлсезлек. 2) Хәлсезлектән терелә башлау. | *сущ.* 1) Недомогание. 2) Выздоравливание. |
| **Нәкъкад** نقاد *сф.* 1) Тәнкыйтьче. 2) Саф акчаны ялган акчадан аера белүче. | *пр. д.* 1) Критик. 2) Человек, умеющий отличать фальшивые деньги. |
| **Нәкъкаль** نقال *сф.* 1) Күчерүче. 2) Ишеткәнне сөйләүче. | *пр. д.* 1) Переносящий, перевозящий. 2) Переводящий, передающий. |
| **Нәкъкаш** نقاش *сф.* Төрле сурәтләр, бизәкләр төшерүче, бизәкче, буяучы. *Меӊ вә миллион афәрин бу сурәтеӊ нәкъкашенә.* (Г. Тук.) | *пр. д.* Гравёр, художник, резчик, красильщик, маляр. |

**Нәкъли** نقلی *с.* 1) Кешедән ишетеп күчереп сөйләнгән. 2) Күчерелмә.
*прил.* 1) Традиционный, основанный на преданиях. 2) Переписанный, скопированный.

**Нәкълия** نقليه *с.* 1) Күчүгә бәйле, күчә торган. 2) Транспорт. *Батсачы шунда үзе һәм аләте әкълиясе.* (Г. Тук.)
*прил.* 1) Передвижной, подвижный. 2) Транспорт.

**Нәкълият** نقليات *ис. к.* 1) Транспорт белән күчерү, әйберләрне күчерү эшләре. 2) Күчерелмә хәбәрләр, традицияләр.
*сущ. мн.* 1) Транспорт, перевозки, транспортирование. 2) Традиции, предания.

**Нәкълән** نقلاً *р.* Кешеләрдән ишетеп, риваятьләр буенча.
*н.* По преданию, по рассказам.

**Нәкыд** نقد *ис.* 1) Кулда булган алтын яки көмеш акча, акча байлыгы. 2) Нәкъ. *Нәкыд бүлмәнең уртасында тәхет өстендә бер мәхбүбә ятыр.* (К. Нас.)
*сущ.* 1) Наличные деньги; звонкая монета. 2) Точно, как раз.

**Нәкыдән** نقداً *р.* Акчалата, акчасын хәзер биреп.
*н.* Наличными.

**Нәкыз** نقض *м. I.* Бозу, бетерү, вату.
*м. I.* Уничтожение; нарушение; расторжение, разрыв.

**Нәкый** نقی *с.* Пакь, ару, катнашмасыз.
*прил.* Чистый, без примеси.

**Нәкыйб** نقيب *ис.* Сайланган, башкалар тарафыннан хөрмәт ителгән кеше, башлык.
*сущ.* Старшина, глава, председатель, предводитель.

**Нәкыйз** نقيض *с.* Каршы, каршылыклы. *Русларның славян булучылыгы „рус" дип аталуга нәкыйз булмаган кебек, безнең дә төрек (төрки) булып татар и емләнүебезгә каршы түгел.* (Г. Ибр.)
*прил.* Противоречивый, противоположный.

**Нәкыйя** نقيه *ис.* Нәкый-нең *мнс.*
*сущ. жен.* от нәкый.

**Нәкыль** نقل *м. I.* 1) Күчерү, урынын алмаштыру, әйбер күчерү. 2) Сөйләү, телдән телгә сөйләү. *Ростов әхвәлене нәкыль кылгач.* (З. Биг.) 3) Тәрҗемә. 4) Алынма.
*м. I.* 1) Перенос, перевозка, перевоз, перемещение. 2) Передача. 3) Перевод (с языка). 4) Заимствование.

**Нәкыльбәнд** نقلبند *гф. ст.* Хикәяләр җыючы.
*ар.-п. сс.* Собиратель рассказов.

**Нәкыс*** نقص *ис.* 1) Кимлек, житешмәүчелек. 2) Кимчелек, җитешсезлек.
*сущ.* 1) Недостача, нехватка. 2) Недостаток, дефект.

**Нәкышь** نقش *ис.* Бизәк, рәсем, сурәт. *Алтын белән нәкышьләнгән диванда ятыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Рисунок; украшение, резная надпись, резьба.

**Нәкышьбәнд** نقشبند *гф. ис.* Рәсем ясаучы, бизәк төшерүче, рәссам. — *ар. -п. сущ.* Художник, живописец.

**Нәкышьбәнди** نقشبندى *гф.* 1) Рәсем ясаучылык, бизәк төшерүчелек. 2) Бәһаэддин Нәкышьбәнд юлын (дини юл) тотучылар. — *ар. -п.* 1) Живопись, художество. 2) Последователи секты Накшбанда.

**Нәкәс*** نكس *ф. с.* 1) Яраксыз. 2) Тупас. 3) Ялкау, иренчәк, нәкәс. — *п. прил.* 1) Негодный. 2) Грубый. 3) Ленивый.

**Нәм** نم *ф. ис.* 1) Дым, юешлек. 2) Кырау; чык. — *п. сущ.* 1) Влага, сырость. 2) Роса, иней.

**Нәма** نما *кара:* нөма. — *см.* Нөма.

**Нәмаеш** نمايش *кара:* нөмаеш. — *см.* Нөмаеш.

**Нәмаэ** نماء *ис.* Арту, күбәю, үрчү, үсү. *Малга нәмаэ хасил булган өчен, ягъни малга зиядәлек вә артучылык хасил булып...* (К. Нас.) — *сущ.* Вырастание, произрастание; рост, развитие.

**Нәмел** نمل *ис.* Кырмыска. — *сущ.* Муравей.

**Нәмимә** نميمه *ис.* Әләк; яла; сүз йөртүчелек. *Берәү килеп ялганласа яки нәмимә китерсә, аны кабул итү акыл дәрәҗәсен күрсәтеп торадыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Донос, сплетня, клевета.

**Нәмм** نم *ис.* Сүз йөртү. — *сущ.* Сплетничание.

**Нәммам** نمام *ис.* Әләкче, яла ягучы; сүз йөртүче, икейөзле, монафикъ. *Нәммамчылык артын ан йөргән кешедән дуслары вә карендәшләре качар.* (К. Нас.) — *сущ.* Доносчик, сплетник, клеветник, лицемер.

**Нәмнакь** نمناك *ф. с.* Юеш, дымлы. *Күңел пөргамьдер, эмма дидә нәмнакь* (Сайяди). — *п. прил.* Мокрый, влажный, сырой.

**Нәмруд** نمرود Борынгы Бабил хөкемдарларыннан берсенең исеме. — Имя собственное одного из вавилонских царей.

**Нәмунә** نمونه *ф. ис.* Үрнәк, өлге. — *п. сущ.* Образец, образчик.

**Нәмәк** نمك *ф. ис.* Тоз. — *п. сущ.* Соль.

**Нәрд** نرد *ф. ис.* Бер төр отыш уены (харита дип тә атала). *Бер кемсәнә нәрд, ягъни харита уйнаса, гүяки ул кеше кулын дуңгыз канына батырды ...* (К. Нас.) — *п. сущ.* Нарды (игра), синоним харита.

| | |
|---|---|
| **Нәрдбан** نردبان *ф. ис.* Баскыч. | *п. сущ.* Приставная лестница. |
| **Нәрем** نرم *ф. с.* Кадерле, купшы, нәфис. | *п. прил.* 1) Мягкий, нежный, изысканный. 2) Мягко, нежно. |
| **Нәрех** نرخ *ф. ис.* 1) Бәя, бәһа. 2) Такса. *Халыкка зарар булмаса, ризыкка нәрех бәһа тәгайин иттерегез диделәр.* (К. Нас.) | *п. сущ.* 1) Цена, курс (ценных бумаг). 2) Такса. |
| **Нәргис** نرگیس *ф. ис.* 1) Нәргис (сары төстәге матур бер чәчәк). 2) *күч.* Гүзәл кызның күзләре. | *п. сущ.* 1) Нарцисс. 2) *перен.* Глаза красавицы. |
| **Нәрҗис** نرجس *кара:* нәргис. *Китап бер бакчадыр, язулары нәрҗисләредер, ягъни гөлләрдер.* (К. Нас.) | *см.* Нәргис. |
| **Нәсаих** نصائح *ис.* Нәсыйхәт-нең *к.* | *мн.* от нәсыйхәт. |
| **Нәсара** نصارا Нәсрани-нең *к.* | *мн.* от нәсрани. |
| **Нәсегъ** نسغ *ис.* Үсемлек суы, сыгынты. *Нәсегъ агачларның яфракларында хәзерләнә.* (Г. Рәф.) | *сущ.* Сок растений. |
| **Нәсел*** نسل *ис.* Токым, бер ата-бабадан таралган токым. | *сущ.* Потомство. |
| **Нәсер*** نثر *ис.* 1) Чәчү, тарату. 2) Чәчмә әсәр, проза. | *сущ.* 1) Рассыпание, рассеивание. 2) Проза. |
| **Нәсрән** نثراً *р.* Чәчмә рәвешендә, проза рәвешендә. *Ушбуны яздырды нәсрән вөҗданымның көчләве.* (Ғ. Тук.) | *н.* Прозой. |
| **Нәсех** نسخ *ис.* 1) Алмаштыру, үзгәртү, бозу, бетерү, юкка чыгару. 2) Гарәп хәрефләре белән бер төр язу — каллиграфия исеме. | *сущ.* 1) Отмена, аннулирование, уничтожение. 2) Почерк „насх“. |
| **Нәсеҗ** نسج *ис.* 1) Туку, сугу. 2) Тукыма. | *сущ.* 1) Ткание 2) Ткань. |
| **Нәсим** نسیم *ис.* Җиңелчә йомшак җил. *Сәламем гөлгә илт, әй таң нәсиме.* (Хорәз.) | *сущ.* Легкий ветерок. |
| **Нәсия** نسیه *ис.* Бурыч, көтәчәк. | *сущ.* Долг; кредит. |
| **Нәсиян** نسیان *ис.* Онытучанлык. | *сущ.* Забывчивость. |
| **Нәсиҗә** نسجه *ис.* Тукыма; тукылган, сугылган нәрсә. | *сущ.* Ткань. |
| **Нәсрани** نصرانی *ис.* Гайса диненә иярүче, христиан. | *сущ.* Христианин. |

**Нәсраният** نصرانيت *ис.* Христианлык. — *сущ.* Христианство.

**Нәсс** نص *ис.* 1) Текст; төгәл мәгънә. 2) Корьән яки хәдистә ачык әйтелгән төп күрсәтмә. *Нәсс килмәстән борын хәмер эчүне ташлаган Габдулла...* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Текст, изложение. 2) Точный смысл; ясное указание (Корана).

**Нәссаҗ** نساج *ис.* Тукучы. — *сущ.* Ткач.

**Нәсух** نصوح *с.* 1. Эчкерсез, турылыклы, керсез күңелле. 2. Чын-чынлап, чын күңелдән, турылыклы рәвештә, керсез күңел белән. *Хәзрәт тәүбәи нәсух кылып яңадан якын бармаска тиешлеген бәян итте.* (Г. Ибр.) — *прил.* 1. Искренний, сердечный. 2. Искренне, чистосердечно.

**Нәсыб** نصب *м. I.* 1) Хезмәткә билгеләнү. *Ибне Синаның атасы Бәлехтән Бохарага күчкәч, шәһәр якынындагы Хәремсин карьясенә мәэмур нәсыб иделде.* (Ш. ж.) 2) Кадап кую. 3) *грам.* Өст (хәрефнең „ә" сузыгы белән укылышы). — *м. I.* 1) Быть назначенным (на должность, пост). 2) Установка, водружение. 3) *грам.* Диакритический знак для звука „ә".

**Нәсыйб*** نصيب *ис.* 1) Өлеш, пай. 2) Насыйп, язмыш. *Монда ауналган исемнәр үз нәсыйбын алдылар.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Часть, доля, пай. 2) Удел, судьба, доля.

**Нәсыйр** نصير *ис.* Ярдәмче, ярдәм итүче. — *сущ.* Помощник.

**Нәсыйхәт*** نصيحت *ис.* Үгет, яхшылыкка өндәү, вәгазьләү. *Бу нәсыйхәтләремне бәс ишетеп һич кеше үкенмәс.* (Г. Канд.) — *сущ.* Совет, наставление.

**Нәсыйхәтгир** نصيحتگر *гф. ис.* Үгет бирүче. — *ар.-п. сущ.* Советник, наставник.

**Нәсыр** نصر *ис.* 1) Ярдәм. 2) Җиңү, өстенлек. — *сущ.* 1) Помощь. 2) Победа.

**Нәсәб** نسب *ис.* Нәсел-ыру, ата-бабалар, чыгыш. *Тәфкилев безнең тарихта чирканыч, мәлгун нәсәб.* (Ш. Баб.) — *сущ.* Родство, свойство.

**Нәсәби** نسبى *с.* Нәселгә, ыруга караган. — *прил.* Близкий, родственный.

**Нәсәбән** نسباً *р.* Нәселе буенча, нәсел ягыннан. — *н.* По родству.

**Нәтаиҗ** نتائج *ис.* Нәтиҗә-нең *к.* — *сущ. мн.* от нәтиҗә.

**Нәтиҗә*** نتيجه *ис.* Йомгак, сөземтә (эш нәтиҗәсе). — *сущ.* Итог, результат, вывод.

**Нәү иҗад** نوايجاد *гф. ис.* Оригинал хезмәт, әсәр. — *ар.-п. сущ.* Оригинальный труд, произведение.

**Нәүруз** نوروز *ф. ис.* Иранлыларның иске календаре буенча ел башы көне, яңа ел бәйрәме (төн белән көннең язгы тигезлек көне 21 март көненә туры килә). *Нәүширван патша нәүруз көнендә үзләренең гадәт.:әренчә зыяфәт ясады.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Ноуруз, первый день иранского нового года (21 марта).

**Нәүруз бәйрәме** — яңа ел бәйрәме. — Новогодний праздник.

**Нәүруз бәете** — яңа ел бәете. — Новогодняя песня.

**Нәфад** نفاد *ис.* Бетү, бетерү, тәмам итү. *Мәкъсудны бу урында кыйлдык нәфад.* (Ак.) — *сущ.* Исчерпание, истощение; завершение, окончание.

**Нәфаис** نفائس *ис. к.* Матур, гүзәл әйберләр; кыйммәтле әйберләр. — *сущ. мн.* Драгоценности; ценные вещи.

**Нәфасәт** نفاست *ис.* 1) Кыйммәтле нәрсә. 2) Гүзәллек, нечкәлек. *Фатыймалар, Фатихалар, Фәүзияләр авызына сандугачлар сал, ходаем, керт нәфа:әт хаузына.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Ценность. 2) Изящество, деликатность, тонкость.

**Нәфегъ** نفع *ис.* 1) Файда. 2) Яхшылык, мал. — *сущ.* 1) Польза, выгода. 2) Благо, добро.

**Нәфел** نفل *ис.* 1) Бүләк. 2) Яхшы эшләр. — *сущ.* 1) Дар. 2) Благие дела.

**Нәфес*** نفس *ис.* 1) Рух, җан. 2) Кеше, гәүдә, зат; 3) Үз(е, м, н). 4) Эчке тойгы; күңел. *Ләкин нәфес моның белән генә канәгать кылмас.* (З. Һад.) 5) Бозык уй. 6) Горурлык. — *сущ.* 1) Душа. 2) Человек, тело, лицо. 3) Сам. 4) Внутреннее чувство. 5) Злонамеренность. 6) Гордость.

**Нәфеспәрәст** نفسپرست *гф. ис.* Эгоизм, үзен-үзе сөючелек. — *ар. -п. сущ.* Эгоизм, себялюбие.

**Нәфес-шәйтан** نفس شيطان *гыйб.* Азу-тузу, бозыклыкка өндәүче эчке тойгы. *Нәфе -шәйтан кергәч, инсан дөньясы азды-тузды, чыкты чиктән һәммәсе.* (Ш. Баб.) — *фр.* Внутреннее чувство, побуждающее к распутству.

**Нәфех** نفخ *м. І.* Өрү, сулыш чыгару. — *м. I.* Дуновение, выдох.

**Нәфи** نفى *ис.* 1) Кире кагылган. 2) Читкә куылган, сөрелгән. 3) *грам.* Юклык (төре). — *сущ.* 1) Отрицаемый. 2) Сосланный, высланный. 3) *грам.* Отрицание.

**Нәфи хәшер** نفى حشر *гыйб.* *дини* Мәхшәр көнен (үлекләрнең терелеп — *фр. рел.* Отрицание воскресения из мёртвых.

тупланулары көнен) юкка чыгару. *Бу игътикад нәфи хәшерне мөстәлзим була диде.* (Г. Ибр.)

**Нәфир** نفير *ис.* Җыелган кешеләр, сугышка кергән бер төркем, гаскәр. — *сущ.* Группа, ополчение, войско.

**Нәфис*** نفيس *с.* 1) Матур, гүзәл, нечкә, нәфис. 2) Сирәк очрый торган. *Бик нәфис алтын еә җәүһәрләр белән мөзәйян китаплары бар иде.* (К. Нас.) — *прил.* 1) Изящный, красивый; прелестный, нежный. 2) Редкостный.

**Нәфисә** نفيسه *ис.* 1) Матур, гүзәл нәрсә. 2) Гүзәл хатын. — *сущ.* 1) Драгоценная вещь, изящная вещь. 2) Красавица.

**Нәфрин** نفرين *ф. ис.* 1) Ләгънәт, бәддога. 2) Күрәлмау, яратмау. — *п. сущ.* 1) Проклятие. 2) Ненависть.

**Нәфрәт*** نفرت *ис.* Җирәнү, күрәлмау. *Дөньяның бу чиктән узган дәһшәте, билгеле, иблискә бойкот-нәфрәте.* (Ш. Баб.) — *сущ.* Отвращение, ненависть, негодование.

**Нәфсани** نفسانى *с.* Хайвани, хайвани табигатькә караган, бозык эчке тойгыга бәйләнешле. — *прил.* 1) Относящийся к низменным желаниям. 2) Скотский.

**Нәфсаниять** نفسانيت *ис.* 1) Дошманлык, ачу, кинә. 2) Үзен артык күрү — эгоизм. 3) Түбән хисләргә бирелү. — *сущ.* 1) Ненависть, вражда. 2) Себялюбие, эгоизм. 3) Подчинение низменным страстям.

**Нәфсе зати** نفس ذاتى *гыйб.* Чыгышы, ясалышы, үзлеге, бөтен торышы. — *фр.* Происхождение, сущность.

**Нәфсе әммарә** نفس امارا *гыйб.* Ямanлыкка (бозыклыкка) тартучы эчке тойгы, тыйнаксызлык; көчле җенси теләк. — *фр.* Похоть, вожделение, распущенность.

**Нәфселәмер** نفس الامر *гыйб.* Төп, асыл, нигез. *Бу куәт синдә нәфселәмердә булган, ләкин начар тәрбия аркасында ул яшерелгән шикелле була.* (Ш. ж.) — *фр.* Сущность, основа.

**Нәфсе ләүвамә** نفس لوامه *гыйб.* Вөҗдан газабы. — *фр.* Угрызение совести.

**Нәфсе мотмәиннә** نفس مطمئنه *гыйб.* Тискәре кичерешләрдән соң тынычлану тойгысы. *Кайт и нәфсе мотмәиннәм, бар, юнәл, кит тәңреңә!* (Г. Тук.) — *фр.* Успокоение, духовное удовлетворение.

**Нәфсе натыйка** نفس ناطقه *гыйб.* Сөйләү (аңлау, төшенү) көченә ия булган зат. — *фр.* Говорящий, рассуждающий, разумный.

**Нәфәка** نفقة *ис.* 1) Ятимнәргә (аерылган хатыннарга) бирелгән акча, алимент. 2) Яшәү өчен кирәк булган мал (азык). *Ул кеше әйтте: „Хәҗгә барырга нәфәкам юк минем“, — диде.* (К. Нас.)

*сущ.* 1) Деньги на содержание сирот, разведённых жён, алименты. 2) Средства на пропитание.

**Нәфәр** نفر *ис.* 1) Ялгыз кеше. *Биш нәфәр мөфәттиш сайланыр иде.* (Х. Чис.) 2) Гади солдат, рядовой.

*сущ.* 1) Один человек. 2) Солдат, рядовой.

**Нәфәс** نفس *ис.* 1) Сулу алу, тын алу, сулыш. *Валлаһи мәнә, ялап бетерә. Кеше нәфәсе авыр бит ул!* (Г. Газиз). 2) Укып өшкерү. 3) Бер сулау озынлыгындагы вакыт.

*сущ.* 1) Дыхание, вздох. 2) Ворожба. 3) Мгновение, миг.

**Нәхафәт** نحافت *ис.* Арыклык,ябыклык, зәгыйфьлек.

*сущ.* Худоба, худощавость; тщедушность, истощённость.

**Нәхел I** نحل *ис.* Бал корты.

*сущ.* Пчела.

**Нәхел II** نخل *ис.* 1) Хөрмә агачы. 2) Яшь килен төшәчәк бүлмәне бизәр өчен, балавыздан ясалып, төрле кыйммәтле ташлар, җимеш рәсемнәре белән бизәлгән агач.

*сущ.* 1) Пальма, финиковая пальма. 2) Декоративное деревцо (вроде новогодней ёлки), устанавливаемое в комнате, предназначенной для невесты.

**Нәхер** نحر *м. I.* Кисү, сую, бугазлау.

*м. I.* Заклание, закалывание.

**Нәхес** نحس *м. I.* Бәхетсезлек, шомлылык, начарлык, уңышсызлык.

*м. I.* Злополучие, несчатье, неудача.

**Нәхиф** نحيف *с.* Ябык, арык. *Гаҗәп син бик нәхиф күренәсең диделәр.* (К. Нас.)

*прил.* Худой, тощий, измождённый.

**Нәхле сәуда** نخل سودا *гыйб.* Гыйшык агачы. *Бетеп җир-җир* (бөтен җирдә тишелеп чыгып) *буй атсын нәхле сәуда.* (Дәрд.)

*фр.* Древо любви.

**Нәххас** نخاس *ф. ис.* Кол белән сату итүче. *Бер көн беркем ирсә нәххаска керде кол алмак өчен* (Мәхмүд бине Гали).

*п. сущ.* Торговец рабами.

**Нәхәви** نحوى *с.* 1) Нәху(гә караган), грамматик. 2) Нәхү белгече.

*прил.* 1) Грамматический, синтаксический. 2) Грамматик.

**Нәхәвиин, нәхәвион** نحوين، نحويون *ис.* Нәхәви-нең *к. Нәхәвиинн̣әп бер адәм хәстә булып...* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от нәхәви.

**Нәхү** نحو *ис.* Синтаксис. — *сущ.* Синтаксис.

**Нәүниһал** نونهال *ф. ис.* Яшь ботак, яшь үсенте. *Бере бер гөл булды, бере нәүниһали* (Сайяди). — *п. сущ.* Молодой побег.

**Нәшан** نشان *ф. кара:* нишан. — *п. см.* Нишан.

**Нәшат** نشاط *ис.* Шатлык, сөенеч, кәефлелек, гайрәт, активлык, җанлылык. *Ләкин халыкта кичәге нәшат, кичәге җан калмаган иде.* (Г. Ибр.) — *сущ.* Бодрость, весёлость, оживление, активность, усердие, энергия.

**Нәшер** نشر *м. I.* 1) Кеше арасына тарату, белдерү, чәчү, җәю. 2) Матбугатта бастырып тарату. *Мәдрәсәләрнең бәднамыны нәшер идәләр.* (З. Биг.) — *м. I.* 1) Распространение. 2) Опубликование, печатание, издание.

**Нәшрият*** نشريات *ис.* 1) Бастырып таратучы идарә. 2) Таратылган китаплар, журналлар. — *сущ.* 1) Издательство. 2) Издания.

**Нәшьә** نشئه *ис.* 1) Барлыкка килү, туу. 2) Кәеф-хәтер хушлыгы... *Чәйне күбрәк сал, нәшьәле булсын диде.* (Ф. Әмир.) — *сущ.* 1) Возникновение, появление. 2) Опьянение, пьяная весёлость.

**Нәшьәт** نشئت *кара:* нәшъә 1. *Дустының нигъмәтенә хәсәд кылмак, дуслык вә мәхәббәтенең авыруыннан нәшьәт итәр...* (К. Нас.) — *см.* Нәшьә 1.

**Нәшү** نشو *ис.* 1) Тишелү, үсеп чыгу, борынлау, шыту, барлыкка килү. 2) Яшь буын. — *сущ.* 1) Рост, возникновение, развитие. 2) Подрастающее поколение.

**Нәү** نو *ф. с.* Яңа, яшь. — *п. прил.* Новый, молодой, юный, свежий.

**Нәүбәт*** نوبت *ис.* Чират. *Уртага иблис чыга нәүбәт алып.* (Ш. Баб.) — *сущ.* Очередь, ряд.

**Нәүбәһар** نوبهار *ф. ис.* Яз башы, иртә яз. — *п. сущ.* Весна, ранняя весна.

**Нәүваб** نواب *ис.* Наиб-ның *к. Һәр вилаяттә нәүваб шәргънең тәхет риясәтендә иганә комиссиясе тәшкил иделәчәк.* (Ш. ж.) — *сущ. мн.* от наиб.

**Нәүгъ** نوع *ис.* Төр, сорт, җенес. — *сущ.* Вид, разновидность, род, сорт, категория.

**Нәүм** نوم *кара:* нәвем. — *см.* Нәвем.

**Нәүмид, нәүмиз*** نومید، نومیز *ф. с.* Өметсез, бернәрсә дә өмет итми торган, өлешсез. *Ля тәйәсү әмерене тот, оныт нәүмизлекне, оныт!* (Г. Тук.) — *п. прил.* Безнадёжный, обескураженный; пришедший в отчаяние, обездоленный.

**Нәүхә** نوحه *ис.* Кычкырып елау (үлгән кеше артыннан). *Бер хатын җеназа артыннан нәүхә кылып, елап барыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Вопль, вскрик, плач.

**Нәүҗәван** نوجوان *ф. гыйб.* Яшь кеше, таза егет. *Фәйрүз шаһ ул вакытта егерме өч яшендә нәүҗәван бер зат иде.* (К. Нас.) — *п. фр.* Юноша, юнец.

**Нәҗабәт** نجابت *ис.* Кадерлелек, хөрмәтлелек, ак сөяклек. — *сущ.* Знатность, благородность, чистопородность.

**Нәҗаиб** نجائب *ис.* Нәҗиб-нең *к.* — *сущ. мн.* от нәҗиб.

**Нәҗасәт** نجاست *ис.* Пычраклык, пычрак (әшәке) әйбер. *Фәкать акча җыю белән ләззәтләнмәк нәҗасәт вә үләксә белән ләззәтләнүче эт кебектер.* (К. Нас.) — *сущ.* Осквернённость, загрязнённость.

**Нәҗат** نجات *ис.* Котылу, исән калу, авырлыктан чыгу. *Юк нәҗат фикрем чөерсәм дә үземнән үзгәгә... тапты нәҗат бер мөнҗидән.* (Г. Тук.) — *сущ.* Спасение, избавление.

**Нәҗах** نجاح *ис.* Өстен килү, җиңеп чыгу, теләккә ирешү; уныш. *Тәрбия буйлә улдыгы вакыт кына әсаслы улыр, һәм дә нәҗах табар.* (Ш. ж.) — *сущ.* Успех, удача, победа.

**Нәҗаши** نجاشی *ис.* Элек заманда хәбәш (Эфиопия) патшаларының кушаматы. — *сущ.* Негус (титул абиссинских царей).

**Нәҗем** نجم *ис.* Йолдыз. — *сущ.* Звёзды (соб.).

**Нәҗес*** نجس *с.* Әшәке, арусыз, пычрак. *Пакьлеге вә нәҗеслеге беленмәгәнлек сәбәпле...* (З. Һад.) — *прил.* Нечистый, поганый, грязный.

**Нәҗиб** نجيب *с.* Тәрбияле нәселдән булган кеше, аксөяк. — *прил.* Благородный, родовитый.

**Нәҗибә** نجيبه Нәҗиб-нең *мнс.* *Гадәтләре аз булган гарәб милләте нәҗибәсе галәмнең ярымына хуҗалык итмеш.* (Г. Ибр.) — *жен.* от нәҗиб.

**Нәҗҗар** نجار *ис.* Балта остасы, столяр. *Бәс Зөләйха шул дәм кирү дүнде.* — *сущ.* Столяр, плотник.

*Нәҗҗарлардан бер сандык хәзерләтте.* (К. Гал.)

**Нәһани** نهانى *ф. с.* Яшерен, астыртын. *Кәлә йөрер якында бер елани, чагарга сахибени ул нәһани.* (Һ. Сал.) — *п. прил.* Тайный, скрытый, затаённый.

**Нәһар** نهار *ис.* Көн, көндез. *Качан китәр кичең, килер нәһарың.* (Г. Тук.) — *сущ.* День, светлая часть суток.

**Нәһари** نهارى *с.* Көндез була торган, көндезге, көндез(гә караган). — *прил.* Дневной.

**Нәһарән** نهاراً *р.* Көндез, көндезен. — *н.* Днём, в светлое время суток.

**Нәһеб** نهب *м. I.* Баскынлык итү, талау; талап алган мал. — *м. I.* Грабёж, ограбление; награбленное.

**Нәһер** نهر *ис.* Елга. *Идел нәһереннән озак дәгел бер татар авылы бардыр.* (М. Ак.) — *сущ.* Река.

**Нәһеж** نهج *ис.* 1) Юл, олы юл. 2) Тәртип, рәвеш, ысул. — *с щ.* 1) Проездная, широкая дорога, путь. 2) Образ, способ.

**Нәһи** نهى *ис.* Тыю, эшне эшләмәскә кушу. *Мөнкәр эшләрдән нәһи кылыр, — диде.* (К. Нас.) — *сущ.* Запрещение делать что-либо.

**Нәһи хазир** نهى حاضر *гыйб. грам.* Юклык төр боерык фигыль. — *фр. грам.* Название глагола в повелительно-запретительной форме.

**Нәһрән** نهراً *р.* Елга буйлап, су юлы белән. — *н.* По реке, по водному пути.

**Нәң** ننك *ф. ис.* 1) Оят, хурлык. 2) Оялчанлык. *Кани нәң, кани намус, кани гарь* (Сайяди). — *п. сущ.* Позор, стыд, срам.

**Нөбәган** نبعان *ис.* Суның җирдән үргылып чыгуы. — *сущ.* Вытекание (воды).

**Нөбәһан** نبهان *ф. ис. к.* Укымышлылар, зур белемлеләр. *Сайяди сәр нөбәһандыр, догасы дәрткә дәрмандыр* (Сайяди). — *п. сущ. мн.* Интеллигенты, образованные люди.

**Нөбүвәт** نبوت *ис.* Пигамбәрлек. — *сущ.* Пророческое звание, пророчество.

**Нөваз** نواز *ф. с.* Юмарт, яхшылык итүче. *Гади кеше гарип нөваз улыр имде.* (К. Гал.) — *п. прил.* Щедрый, добрый.

**Нөдрәт** ندرت *кара:* нәдрәт. — *см.* Нәдрәт.

**Нөдәма** ندما *ис.* Нәдим -нең *к.* — *мн.* от нәдим.

**Нөзүл** نزول *м. I.* 1) Түбән төшү. 2) Юлда берәр йортка вакытлыча туктау (төшү). — *м. I.* 1) Схождение, спуск. 2) Временная остановка на ночлег.

**Нөзһәт** نزهة *ис.* Шатлык, күңел күтәренкелеге, күңел ачу. — *сущ.* Прогулка, развлечение, увеселение, отрада.

**Нөзһәтгяһ** نزهتگاه *гф. ис.* Шатлану (күңел ачу) урыны. *Бер кичә ай яктысында нөзһәтгяһенә чыгып...* (К. Нас.) — *ар.-п. сущ.* Увеселительное место.

**Нөкабаэ** نقباء *ис. к.* Сайланган вәкилләр, аксакаллар, башлыклар. — *сущ. мн.* Старшины, главы; выборные лица.

**Нөкаля** نقلا Накыйль-нең *к.* — *мн.* от накыйль.

**Нөкирә** نکره *ис. грам.* Билгесез исем. *Мәгърифәгә, сыйфатка ярап китә, нөк рә бер вәҗһедән тәхсыйс табса.* (Ак.) — *сущ. грам.* Имя в неопределённном состоянии.

**Нөктә** نکته *ис.* Сүзнең яшерен, үткен мәгънәсе, серле мәгънә. *Сәгъди ләтыйфә сөйләргә яратыр вә әдәби нөктәләргә мәел идәр иде.* (Ш. ж.) — *сущ.* Остроумное слово; замечание, соль, тонкость, пикантность.

**Нөкуд** نقود *ис. к.* Акчалар; мал, байлыклар. *Нөкудләре беткәнлектән, игътибардан сакыйть булдылар.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* Звонкая монета, деньги.

**Нөкыз** نقض *ис.* Берәр бинаның җимереклеге, җимереклек. *Матдәи нөкыз* — җимерелгән бина калдыгы, җимереклек матдәсе. *Уйлә улса кәндем матдәи нөкыз улмыш улыр идем.* (Ш. ж.) — *сущ.* Развалины, руины, обломки.

**Нөма** نما *ф. ис.* 1) Фасад. 2) Мода. 3) Дәрәҗә күрсәткече. 4) Экспонат. 5) Компас. — *п. сущ.* 1) Фасад. 2) Мода. 3) Показатель степени. 4) Экспонат. 5) Компас.

**Нөмаиш** نمایش *ф. ис.* 1) Демонстрация; тышкы күренеш. 2) Тантана. *Зур шәһәргә керде зур шатлык төсе; яңгырады шатлык, нөмаиш алкышы...* (Ш. Баб.) — *п. сущ.* 1) Демонстрация, выставка, показ, внешний вид; наружность. 2) Торжество.

**Нөсус** نصوص Нәсс-ның *к.* *Мәрҗанигә алышырга кем чыдасын, кувәсенә дәләләт кылса нөсус.* (Ак.) — *мн.* от нәсс.

**Нөсхә*** نسخه *ис.* Данә, экземпляр. — *сущ.* Экземпляр, штука.

**Нөсәх** نسخ *ис.* Нөсхә-нең *к.* — *мн.* от нөсхә.

**Нөфүз** نفوذ *ис. к.* 1) Сүз үтемлелек, игътибарлылык, авторитет. 2) Үтеп — *сущ. мн.* 1) Влияние, авторитет, престиж. 2) Проникновение.

керү. *Фәхретдин хәзрәтнең нөфүзене бетергән иде.* (З. Һад.)

**Нөфүз даирә** نفوذدائره *гыйб.* 1) Берәүнең авторитет йогынтысы мәйданы. 2) Авторитетлары белән тәэсир итүчеләр төркеме. — *фр.* 1) Сфера влияния. 2) Влиятельные круги.

**Нөфүс** نفوس *ис. к.* Кешеләр, халык. — *сущ. мн.* Народ, население.

**Нөхас** نحاس *ис.* 1) Бакыр. 2) Бакыр рудасы. 3) Бакыр акча. — *сущ.* 1) Медь. 2) Медная руда. 3) Медные деньги, медяки.

**Нөхаси** نحاسى *с.* Бакыр(дан ясалган); бакыр(га караган). — *прил.* Медный.

**Нөхбә** نخبه *ис.* Иң яхшы, һәр әйбернең иң яхшысы, сайланганы. — *сущ.* Избранное, отборное, самое лучшее.

**Нөшүр** نشور *ис.* 1) Тарату. 2) *дини* Үлгәннән соң терелү. — *сущ.* 1) Распространение. 2) *рел.* Воскресение (из мёртвых).

**Нөҗүм** نجوم *ис.* Нәҗем-нең *к.* *Бөтен инсан вә җир, күккә, нөҗүмгә күңел башлый котырган күк* (кебек) *нөҗүмгә.* (Г. Тук.) — *сущ. мн.* от нәҗем.

**Нөҗүми** نجومى *с.* Йолдызларга һәм йолдызлар гыйлеменә бәйләнешле. — *прил.* Звёздный.

# О

**О** — татар әлифбасында унбишенче хәреф булып, сүз башында гарәп әлифбасының калын әйтелешле өтерле әлифен белдерә. — О — 15-ая буква татарского алфавита. В начале арабских слов означает алиф с даммой.

**Окнүм** اقنوم *ис.* 1) Төп, нигез. 2) Үзлек. 3) Элемент. — *сущ.* 1) Основа, фундамент. 2) Свойство. 3) Элемент.

**Остад, остаз*** استاد ،أستاذ *ис.* 1) Укытучы, мөгаллим. 2) Өйрәтүче, оста. — *сущ.* 1) Преподаватель, учитель. 2) Мастер, умелец.

**Остазанә** أستاذانه *ф. р.* Остазча, осталык белән. — *п. н.* Мастерски.

**Осул** اصول *ис. к.* 1) Нигезләр, нигез кагыйдәләр. 2) Ысул, метод, алым, өйрәнү рәвеше, өйрәнү юлы. *Тәркиб осуле* — синтез методы, синтетик метод. *Тәхлил осуле* — аналитик метод, анализ методы. *Тәхлил-тәркиб осуле* — аналитик-синтетик метод. — *сущ. мн.* 1) Корень, начало, основное правило. 2) Метод, приём, способ.

**Осуле кадим, осуле кадимә** اصول قديم، اصول قديمه *гыйб.* 1) Иске нигезләр, иске тәртипләр. 2) (Укытуда) иҗек методы. — *фр.* 1) Старые основы, старые порядки. 2) Старый слоговой метод (обучения).

**Осуле мәддия** اصول مديه *гыйб.* Аерым иҗекләрне алып өйрәтү методы — силлабик метод. — *фр.* Новый слоговой (силлабический) метод обучения письму.

**Осуле саутия** اصول صوتيه *гыйб.* Балаларны укырга-язарга өйрәтүдә куллана торган аваз методы. — *фр.* Звуковой (фонетический) метод обучения письму.

**Осуле тәгълим** اصول تعليم *гыйб.* Методика. — *фр.* Методика.

**Осуле тәдрис** اصول تدرس *гыйб.* Дәрес бирү, укыту методы һәм алымнары. *Аның осуле тәдрисе җаиз дәгел.* (М. Ак.) — *фр.* Способы преподавания; способы обучения; методы ведения урока.

**Осуле тәрбия** اصول تربيه *гыйб.* Педагогика. — *фр.* Педагогика.

**Осуле җәдид, осуле җәдидә** اصول جديد، اصول جديده *гыйб.* Яңа тәртипләр, яңа нигезләр (укытуда). — *фр.* Новые принципы, новые основы (в обучении).

**Офык*** افق *ис.* Күк чите, горизонт. — *сущ.* Горизонт.

**Охра** اخرى *с.* Башка, бүтән, икенче. — *прил.* Другой, иной.

**Охрави** اخروى *с.* 1) *дини* Ахирәт(кә бәйләнешле). 2) Мәңгелек. *Ул һәйкәлгә мәңге, мәңге көлеп торган охрави бер авыз уярсыз.* (Һ. Так.) — *прил.* 1) *рел.* Потусторонний (мир). 2) Вечный.

# П

**П** — پ. Татар әлифбасында уналтынчы, фарси әлифбасында өченче хәреф булып „пи“ исемендә йөртелә. — 16-я буква татарского, третья буква персидского алфавита.

**Падиша** پادشاه *ф. ис.* Патша, шаһ. — *сущ.* Царь, король, шах.

**Пай** پاى *ф. ис.* Аяк. *Тәхте паеңда сәнең ауланаем, ауланаем.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Нога.

**Пайдар** پايدار *ф. ис.* Аягы нык, нык урнашкан; даими. — *п. сущ.* Устойчивый, прочный, крепкий, постоянный.

**Паймал** پايمال *ф. с.* Аяк астына салып таптала торган, игътибарга алынмый торган, хурлана торган. *Хокуклары паймал ителмәз дигән.* (Ш. ж.) — *п. прил.* Попираемый ногами, растоптанный; попранный.

**Пайтәхет** پايتخت *ф. ис.* Башкала. — *п. сущ.* Столица, главный город.

**Пакизә** پاكيزه *ф. с.* Чиста, керсез, пөхтә. *Пакизә бер хатын икәнлеге беленсә дә...* (З. Һад.) — *п. прил.* Чистый, целомудренный.

**Пакь*** پاك *ф. с.* Таза, ару, саф, чиста. — *п. прил.* Чистый, беспорочный.

**Пакьдаман** پاكدامان *ф. с.* 1) Бик саф, гыйффәтле. *Хөсен ход пакьдаманлыктан арта.* (Хорәз.) 2) Намуслы. — *п. прил.* 1) Целомудренный, непорочный, невинный, чистый. 2) Честный.

**Парса** پارسا *ф. с.* Гыйффәтле, динле. *Хәрабәт эчрә* (эчү йортында), *мәсҗиддә йирем бар, кем уш һәм рәндмен, һәм парсамын.* (Хорәз.) — *п. прил.* Благочестивый, набожный.

**Парча*** پارچه *ф. ис.* 1) Парча (тукыма). 2) Кисәк, бүлем, өлеш, бөртек. *Сүзләмәкдин парча дөрләр сачтылар.* (Мөхм.) — *п. сущ.* 1) Материя, парча. 2) Часть, кусок, доля; отрывок.

**Парә** پاره *ф. ис.* 1) Кисәк, өлеш. *Парә-парә кисмәсә гыйшкы-мәхәббәт кайчысы.* (Г. Тук.) 2) Төркиядә акча исеме. — *п. сущ.* 1) Кусок, часть. 2) Турецкая монета.

**Пасбан** پاسبان *ф. ис.* 1) Каравылчы, сакчы, төн каравылчысы. 2) Полицейский. — *п. сущ.* 1) Сторож, караульный, часовой. 2) Полицейский.

**Пая** پايه *ф. ис.* 1) Дәрәҗә. 2) Баскычның басмасы. 3) Мәртәбә. — *п. сущ.* 1) Степень. 2) Ступенька. 3) Ранг, положение.

**Паян** پايان *ф. ис.* Оч, ахыр, соң. *Гомер михнәт belә паянә килде.* (Хорәз.) — *п. сущ.* Конец, окончание.

**Пинһан** پنهان *кара:* пәнһан. — *см.* Пәнһан.

**Пир** پير *ф. ис.* 1) Карт кеше, күп яшәгән кеше. 2) Берәр дини мәзһәп, дәрвишлек юлын чыгарган кеше. 3) Нигез салучы. — *п. сущ.* 1) Старик, старец. 2) Глава религиозной общины — пир. 3) Основатель.

Пирәзән پیرهزن *ф. ис.* Карчык. — *п. сущ.* Старушка.

Пис (пәст) پیس *ф. с.* Пычрак, начар, әшәке; түбән. *Булса пис эшләргә үч, бирмәскә иблискә көч.* (Ш. Баб.) — *п. прил.* Нечистый, грязный, поганый, низкий, низменный.

Пишдар پیشدار *ф. ис.* Алдынгы, авангард, алда баручы. — *п. сущ.* Авангард.

Пишева پیشوا *ф. ис.* Житәкче. *Җәһаләт кауменең һәм пишевасы.* (Ут. Им.) — *п. сущ.* Вождь.

Пишкадәм پیشقدم *гф. ис.* 1) Укуда башкалардан алда булган шәкерт. 2) Иске мәдрәсәнең тулы уку курсын бетергән хөрмәтле кеше. *Бу Вафа хәзрәтнең иң галим пишкадәмнәреннән Кәбир хәлфә иде.* (Г. Ибр.) — *ар.-п. сущ.* 1) Передовой в учебе, передовик. 2) Уважаемый человек, окончивший полный курс старого медресе.

Пишкяһ پیشگاه *ф. ис.* Алды, каршысы. *Хафа булып торганда, Мәсрүр исемле хас мөгътәбәр хадим пишкяһендә торыр иде.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Место перед кем-либо; перед.

Пишә پیشه *ф. ис.* Эш, шөгыль. *Сабурдин яхшы юктыр пишә кылсам.* (Хорәз.) — *п. сущ.* Постоянное занятие, ремесло.

Пиядә پیاده *ф. ис.* Җәяү, җәяүле. — *п. сущ.* Пеший, пехотинец.

Пияз پیاز *ф. ис.* Суган. — *п. сущ.* Лук.

Поль (пул) پول، پل *ф. ис.* Акча. *Бу иде юксын, бер польгә мохтаҗ.* (Мөхм.) — *п. сущ.* Деньги.

Пот* پت *ф. ис.* 1) Пот, санәм. 2) Табына торган сурәт, икона. 3) Тәре. — *п. сущ.* 1) Идол. 2) Икона, образ. 3) Крест.

Потпәрәст پتپرست *ф. ис.* Потка табынучы. — *п. сущ.* Идолопоклонник.

Потханә پتخانه *ф. ис.* Потка табыну йорты, гыйбадәтханә. *Әлен* (кулын) *алып потханәя керер имде.* (К. Гал.) — *п. сущ.* Храм идолопоклонников.

Пулад پولاد *ф. ис.* Корыч. — *п. сущ.* Сталь.

Пуст پوست *ф. ис.* 1) Тире. 2) Агач кабыгы. — *п. сущ.* 1) Кожа, шкура. 2) Кора, скорлупа.

Пусә (бүсә) بوسه، پوسه *ф. ис.* Үбү, үбеш. *Яшь төрек бәс мөстәбид ядь иснәмәс, пус әйләмәс.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Поцелуй.

Пырак پراق *ф. ис. миф.* Җәннәттә фантастик ат. *Нур тоташты җиргә, күктән иңде нурдан бер пырак.* (Г. Тук.) — *п. сущ. миф.* Фантастический, райский конь.

**Пәдәр** پدر *ф. ис.* Ата, әти. *Шивәзадә, пәдәр вә мадәренең хозурына барып...* (К. Нас.) — *п. сущ.* Отец.

**Пәдәранә** پدرانه *ф. р.* Аталарча, ата шикелле. — *п. н.* Отечески, как отец.

**Пәйвәстә** پیوسته *ф. р.* 1) Тоташтан, өзлексез, даими рәвештә. *Пәйвәстә аны нәфсем эстәр диер имди.* (К. Гал.) 2) Тоташ, кушылган, янәшә. — *п. н.* **1.** Постоянно, беспрерывно. **2.** 1) Постоянный, беспрерывный. 2) Смежный, соединённый.

**Пәйгам** پیغام *кара:* пәям. *Булып бичаралар ул дәмдә пәйгам* (Сайяди). — *см.* Пәям.

**Пәйгамбәр*** پیغمبر *ф. ис.* Нинди дә булса бер динне беренче башлап чыгаручы, өйрәтүче, пигамбәр. — *п. сущ.* Пророк; основатель какой-либо религии.

**Пәйда** پیدا *ф. ис.* Күренү, барлыкка килү, күз алдында күренгән. *Кара ямьсез болытлар булдылар пәйда шул ук хиндә.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Видный, видимый, явный, ясный.

**Пәй дәр пәй** پیدرپی *гыйб.* Бер-бер артлы, берсе артыннан берсе, әкрен-әкрен. *Ки пәй дәр пәй бәлешләргә йөгермә.* (Г. Тук.) — *фр.* Последовательно, шаг за шагом, непрерывно, один за другим.

**Пәйк** پیک *ф. ис.* Хат ташучы, хәбәр китерүче, йомыш-юлга йөрүче, курьер. *Пәйк хәзрәти Җәбраил кәлде хазир.* (К. Гал.) — *п. сущ.* 1) Письмоносец. 2) Вестник, гонец, курьер.

**Пәйкәр** پیکر *ф. ис.* 1) Чырай, йөз. *Күрде ки янында пәри пәйкәр бер адәм торыр.* (К. Нас.) 2) Сурәт, шәкел, тышкы кыяфәт. — *п. сущ.* 1) Лицо, физиономия. 2) Фигура, образ, тело, форма, наружность.

**Пәйман** پیمان *ф. ис.* 1) Союз, договор. 2) Вәгъдә, сүз бирешү, ант. — *п. сущ.* 1) Договор, пакт. 2) Клятва, обещание.

**Пәйрәү** پیرو *ф. ис.* Артыннан баручы, ияручe. — *п. сущ.* Последователь, приверженец.

**Пәллә** پله *ф. ис.* Үлчәү тәлинкәсе. — *п. сущ.* Чаша весов.

**Пәләң** پلنگ *ф. ис.* Барс, леопард, пантера. *Вә чөн пәләң бәдигъ рәң...* (Мәҗмәгыл хикәять). — *п. сущ.* Барс, леопард, пантера.

**Пәнаһ** پناه *ф. ис.* **1.** Сыену урыны, саклану урыны. **2.** Саклаучы, яклаучы. *Ике зөлфең күңелләрне пәнаһе.* (Хорәз.) — *п. сущ.* **1.** Укрытие, убежище; прибежище, защита. **2.** Защищающий, укрывающий.

**Пәнд** پند *ф. ис.* Үгет, вәгазь, нәсыйхәт. *Пәнд вә хикмәт әйтмәгә син кандыргыл.* (К. Гал.) — *п. сущ.* Совет, наставление, нравоучение.

**Пәнеҗ** پنج *ф. сан* Биш. — *п. ч.* Пять.

**Пәнҗәшәнбә*** پنجشنبه *ф. ис.* Атна кич. — *п. сущ.* Четверг.

**Пәнҗә** پنجه *ф. ис.* 1) Кул чугы, биш бармак. 2) Биш тырнаклы хайван аягы, ерткыч хайванның алгы аяклары. *Вакыт кортылмага бу пәнҗәләрдән.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* 1) Кисть руки, пятерня. 2) Лапа, когти.

**Пәнҗәрә** پنجره *ф. ис.* Тәрәзә. — *п. сущ.* Окно.

**Пәнһан** پنهان *ф. с.* Яшерен, яшертен, яшеренү. *Якын кәлә, ул кошлар улды пәнһан.* (К. Гал.) — *п. прил.* Скрытый, затаённый, спрятанный.

**Пәракәндә** پراکنده، پراکنده *ф. с.* 1) Таркаулык, таркау. 2) Җыйнаксыз, тәртипсез. *Күңеле тәшвишләрдән вә пәракәндәлекләрдән хали булмас.* (К. Нас.) — *п. прил.* **1.** Разброд, раскол. **2.** Рассеянный, беспорядочный.

**Пәрва** پروا *ф. ис.* Курку, тартыну, саклану. — *п. сущ.* 1) Опасение, страх. 2) Забота, спасение.

**Пәрвасыз** (пәрвайсыз) — игътибарсыз, саксыз. — Невнимательный, беспечный.

**Пәрваз** پرواز *ф. ис.* Очу, һавага очу. *Ул пәри аннан чыгып һавада пәрваз итеп йөргәндә...* (К. Нас.) — *п. сущ.* Полёт, летание.

**Пәрванә** پروانه *ф. ис.* 1) Ут әйләнәсендә очып йөри торган күбәләк. *Бер гәдай җан фидаем, гыйшкыңа пәрванәем.* (Г. Тук.) 2) Әйләнеп тора торган көпчәк, канат. — *п. сущ.* 1) Бабочка, летающая вокруг огня. 2) Винт, маховое колесо.

**Пәрвәрдикяр** پروردکار *ф. ис. дини* Тудыручы, яратучы, алла. — *п. сущ. рел.* Творец, создатель, бог.

**Пәрвәриш** پرورش *ф. ис.* 1) Тәрбия, тәрбияләү, карау. *Ул угланны... аңа бирдем, пәрвәриш кылгай*. (Мәҗмәгыл хикәять). 2) Үрчетү, асрау. — *п. сущ.* 1) Воспитание, уход. 2) Разведение.

**Пәри*** پری *ф. ис. миф.* 1) Җен төркеменнән иң матуры. 2) *күч.* Матур, гүзәл, сылу. — *п. сущ. миф.* 1) Фея, пери. 2) *перен.* Красавица.

**Пәри пәйкәри** پری پیکری *гыйб.* Пәри төсле матур, гүзәл. *Күрде ки янында пәри пәйкәри бер адәм торыр.* (К. Нас.) — *фр.* Красивая, как пери.

**Пәри рох** پری رخ *гыйб.* Матур, гүзәл, сөекле. — *фр.* Периподобная, феєподобная красавица.

**Пәришан (пришан)** پریشان *ф. с.* Һәлакәткә төшкән, таркау, таралган, бозылган, харап булган. *Иранлылар Юнанстанга җиткәнче пришан булдылар.* (Х Чис.) — *п. прил.* 1) Рассеянный. 2) Расстроенный, загубленный; разбитый.

**Пәрту, пәртәү** پرتو *ф. ис.* Яктылык, нур чагылуы. — *п. сущ.* Свет, луч, блеск.

**Пәрәнҗ** پرنج *ф. ис.* Дөге. — *п. сущ.* Рис.

**Пәрәст** پرست *ф. ис.* Табынучы, бер нәрсәне артык бирелеп яратучы. — *п. сущ.* Поклоняющийся чему-либо, обожатель.

**Пәрәстиш** پرستش *ф. ис.* Табынучылык, гыйбадәт итүчелек, бирелгәнлек. — *п. сущ.* Культ, обожание, поклонение.

**Пәрһиз** پرهیز *ф. ис.* 1) Саклану. 2) Авыр (майлы) аштан саклану. *Ул гаять мохтаҗ була торып заһидлеккеннән вә пәрһизлегеннән сөаль кыйлмады.* (К. Нас.) — *п. сущ.* 1) Опасение, остережение. 2) Пост, воздержание от жирной пищи.

**Пәст** پست *ф. ис.* Түбән, хурлыклы, пычрак, әшәке. — *п. сущ.* Низкий, подлый, презренный; грязный.

**Пәшиман** پشیمان *кара:* пөшәйман. — *см.* Пөшәйман.

**Пәшкәш** پشکش *ф. ис.* Бүләк. — *п. сущ.* Подарок.

**Пәштепәнаһ** پشتپناه *кара:* пөштипәнаһ. — *см.* Пөштипәнаһ.

**Пәям** پیام *ф. ис.* Хәбәр, китерелгән мәгълүмат; өндәмә, мөрәҗәгать. *Дили шәбхун идәр һәрбер пәямы.* (Дәрд.) — *п. сущ.* Весть, послание, извещение, воззвание.

**Пәһлеван*** پهلوان *ф. ис.* 1) Батыр. 2) Көчле, куәтле, көрәшче. *Пәһлеванга бирделәр алтын сәгать.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* 1) Герой, витязь. 2) Чемпион, силач, атлет, борец.

**Пө** پر *ф. ис.* Тулы. *Пөр нур* — нурга тулы, нурга чумган. *Зыясыннан әһали улды пөр нур.* (Г. Тук.) — *п. прил.* Полный, заполненный.

**Пөргамь** پرغم *ф. ст.* Гамьгә (кайгыга) тулы, тулы хәсрәттә. *Күңел пөргамьдер, әмма дидә нәмнакь* (Сайяди). — *п. сс.* Огорчённый.

**Пөртәкъсыйр** پرتقصیر *гф.* Гаебе, кимчелеге тулы. *Мин фәкыйрь пөртәкъсыйр бу хикаяте гаҗибәне ... ике телгә тәсныйф кылдым.* (Ә. Ү. К.) — *ар.-п.* Отягченный грехами, пороками; недостойный, несовершенный.

**Пөхтә*** پخته *ф. с.* Төп мәгънәсе: пешкән, җитешкән; бездә: җыйнак, чиста. — *п. прил.* 1) Созревший, спелый. 2) Аккуратный,

*Бүлмәнең җиһазлары ма ур, килешле карыйлар, матурлык сөйгән бер колның пөхтәлеген сөйлиләр.* (Г. Ибр.) — чистый, опрятный.

**Пөшәйман** پشيمان *ф. ис.* Үкенүче, үткәнгә кайгыручы. *Һичвакыт булмый пөшәйман садә тордым дип кеше.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Раскаивающийся.

**Пөштипәнаһ** پشتيپناه *ф. ис.* Арка таянычы, ярдәмче. — *п. сущ.* Покровитель, защитник.

# Р

**Р** — ر. Татар әлифбасында унҗиденче, гарәп алфавитында унынчы хәреф булып, 200 санына йөри. Татар телендә „р“ сүз башында килми. Бу хәреф белән башланган сүзләр бездә һәммәсе алынма сүзләр. — В татарском алфавите 17-я, в арабском алфавите 10-ая буква; цифровое значение 200. Все татарские слова, начинающиеся с „р“, заимствованы из других языков.

**Раббе** رب *ис.* 1) Хуҗа, ия, тәрбияче. 2) Алла. *Орлыгым сиптем аларның кал бенә каршы килсеннәр өчен раббе әмеренә.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Хозяин, владелец. 2) Господь.

**Рабби** ربى *ст.* Аллам, тәңрем. *Я рабби* — әй аллам. — *сс.* Боже мой.

**Раббәна** ربنا *ст.* Аллабыз. *Мискиннәргә мөнаҗәт, дога кирәк, зарланып телдән салмай раббәнасын.* (Ак.) — *сс.* Бог наш.

**Рабиган** رابعا *р.* Дүртенчеләй, дүртенче булып, дүртенчедән. — *н.* В-четвёртых.

**Рабигъ I, рабига** رابعه ، رابع *сан* Дүртенче. — *ч.* Четвёртый, четвёртая.

**Рабигъ II** ربيع *ис.* Яз. — *сущ.* Весна.

**Рабигый** ربيعى *с.* Язгы, яз(га караган). — *прил.* Весенний.

**Рабигылахыр** ربيع الاخر *гыйб.* Ай елының дүртенче ае исеме. — *фр.* Название четвёртого месяца лунного календаря.

**Рабигыләүвәл** ربيع الاول *гыйб.* Ай елының өченче ае исеме. — *фр.* Название третьего месяца лунного календаря.

**Рабита** رابطه *сф.* 1) Бәйләнеш. 2) Ике нәрсәне бергә бәйләгән җеп. *Адәмнең* — *пр. д.* 1) Связь. 2) Верёвка; нитка.

*малы вә йорты-җире зиядә рабита вә галякасыдыр.* (К. Нас.)

**Рабыйт** رابط *сф.* 1) Бәйләүче, кушучы, тоташтыручы. 2) Союз, лига. — *пр. д.* 1) Связывающий, соединяющий. 2) Союз, ассоциация, лига.

**Рабыт** ربط *м. I.* Бәйләү, ялгау. *Сөякне сөяккә багълар ки, бонлар сөяк арасында рабыт өчен.* (К. Нас.) — *м. I.* Связывание, соединение.

**Рави** راوى *сф.* Сөйләүче, башка бер кешедән ишетеп сөйләүче. — *пр. д.* Рассказчик, пересказчик.

**Равиян** راويان *ис.* Рави-нең *к.* — *сущ. мн.* от рави.

**Рагый** راعى *сф.* Көтүче, хайван багучы, чабан. — *пр. д.* Пастух, чабан.

**Рагыйб** راعب *сф.* Кызыгучы, кызыксынучы, теләүче. — *пр. д.* Желающий, интересующийся чем-либо.

**Раддә** رادە *ис.* 1) Дәрәҗә, чик, чама. 2) Чамалы күләм. *Айлык варәдате йөз сум раддәсендәдер.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Степень, размер. 2) Обьём, приблизительное количество.

**Раз** راز *ф. ис.* 1) Сер, яшерен эш. *Разын гизләп айрык сүз һич димәде.* (К. Гал.) 2) Буяу. — *п. сущ.* 1) Тайна, секрет, тайное дело. 2) Краска.

**Раз дили** رازدلى *ф. из.* Күңел сере. *Ки бер-беригә дип раз дилини...* (Сайяди). — *п. из.* Сокровенная тайна.

**Разый*** راضى *сф.* Риза булучы, ризалык күрсәтүче. — *пр. д.* Удовлетворенный, довольный, согласный.

**Разыйк** رازق *сф.* Ашатучы, ризыкландыручы, ризык бирүче, туендыручы. *Ул мөкаддәр ризкын ашаучыдыр, разыйк түгелдер, — диде.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1. Дающий средства к жизни, питающий. 2. Кормилец.

**Раихә** رائحه *ис.* Ис, аромат. — *сущ.* Запах, дух, аромат.

**Раихәи кәриһә** — начар ис, сасы ис. — Дурной запах, вонь.

**Раихәи тайебә** — хуш ис. *Бәгъзе адәмнәр раихәи тайебә вә ләззәт хасил итмешләр.* (К. Нас.) — Душистый, приятный запах.

**Ракиб** راكب *сф.* Атланучы, атланып баручы, җайдак. — *пр. д.* Всадник, ездок.

**Ракибән** راكبًا *р.* Атланган хәлдә, атланып. — *н.* Верхом.

**Ракид** راكد *сф.* Хәрәкәтсез торучы, тын. — *пр. д.* Тихий, вялый, стоячая (о воде).

**Ракыйб** راقب *сф.* Күзәтүче, күзәтеп (көтеп) торучы. — *пр. д.* Наблюдающий, контролирующий.

**Ракыйм** راقم *сф.* 1) Цифр куючы (цифр сугучы). 2) Язучы. — *пр. д.* 1) Нумерующий. 2) Пишущий.

**Рам** رام *ф. с.* 1) Буйсынучы, буйсынган. *Хатыннар, ирләрнең морадын җан колагы белән тыңлап, рам булыр.* (К. Нас.) 2) Кулга ияләшкән. — *п. прил.* 1) Смирный, покорный, послушный. 2) Ручной, прирученный.

**Рамазан*** رمضان *ис.* Ай елының тугызынчы ае исеме. — *сущ.* Девятый месяц лунного календаря.

**Рами** رامى *сф.* Атучы, ук атучы. *Әгәр атса ялгыш кына бер-бер рами.* (Г. Тук.) — *пр. д.* **1.** Бросающий, мечущий. **2.** Стрелок.

**Ран** ران *ф. с.* Сөрүче, үтәүче мәгънәсен бирә торган суффикс. *Хөкемран* — хөкем сөрүче. — *п. прил.* Суффикс деятеля.

**Расим** راسم *сф.* Рәсем төшерүче, художник. — *пр. д.* Рисующий, художник.

**Расих** راسخ *сф.* 1) Нык, ныкланган, беркетелгән. 2) Оста, тәҗрибәле, тирән белемле. — *пр. д.* 1) Прочный, укреплённый, твёрдый, устойчивый. 2) Опытный, искусный, знающий.

**Раст** راست *ф. с.* Дөрес, рас, чын. — *п. прил.* Верно, правильно.

**Раст килү** — очрау, туры килү. *Төрле-төрле манигъләр раст киләләр.* (З. Биг.) — Встречаться с чем-либо.

**Растгү** راستگو *ф. с.* Туры сөйләүче, дөресен әйтүче. — *п. прил.* Правдивый, говорящий правду.

**Расыйд** راصد *сф.* Астроном, күзәтүче. — *пр. д.* Наблюдатель (чаще всего астроном).

**Ратыб** رطب *ис.* Юеш, кипмәгән, дымлы, яшел, яшь. — *сущ.* Сырой, влажный, свежий, сочный, нежный.

**Рауза** روضه *ис.* 1) Гөл бакчасы, чәчәклек. 2) *миф.* Җәннәт исеме, җәннәт бакчасы. *Торса ул яд иттереп җәннәт сарае раузасын.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Сад, цветник. 2) *миф.* Название рая.

**Рах** راح *ис.* 1) Шәрап. *Хуш эчкел рахны рәйхан эчендә.* (Хорәз.) 2) Шатлык, хозур. — *сущ.* 1) Вино. 2) Веселье, радость.

**Рахилә** راحله *ис.* Өстендә йөк йөртә торган хайван. — *сущ.* Вьючное животное.

**Рахим** راحم *сф.* Мәрхәмәтле, аяучан. — *пр. д.* Милосердный, милостивый.

**Рахәт** راحت *кара:* рәхәт. — *см.* Рәхәт.

**Раши** راشى *с.* Ришвәт бирүче. — *прил.* Подкупающий, дающий взятку.

**Рашид** راشد *сф.* 1) Туры юлда булучы, турылыкта булган кеше. 2) Батыр, кыю, зирәк кеше. *Ике егет, икеләсе ике рашид.* (К. Гал.) — *пр. д.* 1) Правильный, идущий по правильному пути. 2) Храбрый, мужественный, зрелый умом.

**Ражи** راجى *сф.* Сораучы, үтенүче, өмет итүче, ялваручы. *Сабыр кылгыл, хаиф, ражи улгыл имди.* (К. Гал.) — *пр. д.* Просящий, умоляющий, выпрашивающий.

**Ражигъ** راجع *сф.* Кайтучы; кайта торган. *Талакы гайр ражига* — икенче бер иргә бармыйча, кайту мөмкин булмаган төстә хатын аеру. — *пр. д.* Возвращающийся, возвратный.

**Ражил** راجل *сф.* Җәяү йөрүче, җәяүле. — *пр. д.* Пеший, пешеход.

**Ражилән** راجلا *р.* Җәяүләп, җәяү. — *н.* Пешком.

**Ражих** راجح *сф.* Иң яхшы, иң өстен, иң алдынгы. *Әдәпнең сәмәрәсе — гакылы ражихтыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Лучший, превосходный, предпочтительный.

**Раһ** راه *ф. ис.* Юл. *Китәрсә, котлы улсын аңа раһи.* (Һ. Сал.) — *п. сущ.* Дорога, путь.

**Раһзән** راهزن *ф. ис.* Юл кисүче, юлбасар. — *п. сущ.* Разбойник, бандит, грабитель.

**Раһиб** راهب *ис.* Монах. — *сущ.* Монах.

**Раһибә** راهبه *ис.* Хатын монах. — *сущ.* Монахиня.

**Риба** ربا *ис.* Процент алу. ... *Ришвәт вә риба тарикы илә мал казанып...* (З. Биг.) — *сущ.* Лихоимство, ростовщичество.

**Рибахур** رباخور *гф. ис.* Зур процент алучы. — *ар.-п. сущ.* Ростовщик.

**Рибех** ربح *ис.* Табыш, файда. — *сущ.* Доход, прибыль, барыш.

**Ривак** رواق *ис.* Зиннәтле чатыр; галерея. — *сущ.* Портик, балдахин; галерея, ложа.

**Риваять*** روايت *ис.* Берәр хәбәр яки сүзне икенче бер кешедән күчереп сөйләү; роман, хикәя. — *сущ.* Рассказ, повесть, легенда, роман, версия.

**Ригая, ригаять** رعايه ،رعايت *ис.* Кайгырту, карау, игътибар итү, олылау, хөрмәтләү. „... *әгәр дусың өч турыда хифыз вә ригая кыйлмаса*", — *диде.* (К. Нас.) — *сущ.* Забота, внимание, уход, попечение, покровительство; уважение.

**Ригаятән** رعايةً *р.* 1) Олыларча. 2) Олылап, хөрмәт итеп; хөрмәт белән. — *н.* 1) Покровительственно. 2) Почтительно, с уважением.

**Риза*** رضا *ис.* Разыйлык, разый булу; карышмау, буйсыну. — *сущ.* Довольство, удовлетворение; согласие, подчинение.

**Ризаг** رضاع *м. I.* Сөт иму. — *м. I.* Питание грудью (сосать грудь).

**Ризагый** رضاعى *с.* Сөт имүдән булган, сөт имүгә бәйләнешле. — *прил.* Молочный.

**Ризагый теш** — сөт теше. — Молочный зуб.

**Ризван** رضوان *ис.* 1) Разыйлык, күңел хушлыгы. *Без каршыңда ризванбыз.* (Г. Тук.) 2) *дини* Җәннәт хезмәтчеләреннән берсенең исеме. Җәннәт бакчалары сакчысы. *Бераздан чыкты ризван.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Довольство, удовлетворение, согласие; благожелательность. 2) *рел.* Имя собственное одного из слуг рая. Сторож райского сада.

**Рида** ردا *ис.* Киң кием, дәрвишләр киеме. — *сущ.* Широкополый плащ, одежда дервишей.

**Ризык*** رزق *ис.* Ашамлык, азык. — *сущ.* Продукт, пища, пропитание.

**Рикъкать** رقت *ис.* Нечкәлек, күңел йомшаклыгы. *Ачып укый башлаганда күңеленә рикъкать килеп.* (К. Нас.) — *сущ.* Тонкость, нежность, мягкость, деликатность.

**Рикъкыять** رقيت *ис.* Коллык, әсирлек. — *сущ.* Рабство, неволя.

**Рисалә** رساله *ис.* Мәкалә, кечкенә китап, брошюра... *Газета вә рисаләләр чыгып...* (З. Һад.) — *сущ.* Послание, статья, трактат; брошюра.

**Рисаләт** رسالت *ис.* Илчелек, пәйгамбәрлек. *Нәбүвәт, рисаләт булдачысән.* (К. Гал.) — *сущ.* Пророческая миссия.

**Рисвай*** رسواى *ф. с.* Хур (мәсхәрә) ителгән, гаепләре ачылып хурлыкка төшкән. — *п. прил.* Опозоренный, обесчещенный, посрамленный.

**Ритыл** رطل *ис.* Сыек әйберләр үлчәве, пыяла савыт. — *сущ.* Мера жидких тел; кубок, чаша.

**Рифгать** رفعت *ис.* Күтәрелеш, югарыга ашу. *Татарлар рифгате, шаны чиксез кат күкләргә китсен.* (Г. Тук.) — *сущ.* Поднятие, возвышение, подъём.

**Рифык** رفق *ис.* Йомшаклык, юашлык, түбәнчелеклелек, мәрхәмәтлелек. *Ушбу бәлагә мөбтәлә булган кешеләргә рифык итмешләр.* (К. Нас.) — *сущ.* Доброта, мягкость, снисхождение, жалость.

**Рих** ريح *ис.* 1) Җил. 2) Ис. 3) Газ. — *сущ.* 1) Ветер. 2) Запах. 3) Газы.

**Рихе сар-сар** — бик каты суык җил. *Рихе сар-сар төсле син болгандыручы булмасаң.* (Г. Тук.) — Сильный, холодный ветер.

**Рихләт** رحلت *ис.* 1) Күчү, урыннан күчеп китү. 2) Үлү (дөньядан күчү.) — *сущ.* 1) Переезд, перемена места. 2) Кончина.

**Ришвәт*** رشوت *ис.* Үз файдасына эшләсен өчен бирәүгә бирелгән акча, бүләк. — *сущ.* Взятка.

**Ришвәт хор** رشوت خور *гф. ис.* Ришвәт алучы. — *ар.-п. сущ.* Взяточник.

**Риштә** رشته *ф. ис.* 1) Җеп, бау. 2) *мед.* Урта Азиядә тәнгә чыга торган бертөрле чир. — *п. сущ.* 1) Нить, верёвка волокна. 2) *мед.* Ришта (болезнь в Средней Азии).

**Рия*** ريا *ис.* Бер эшне кешегә күрсәтү өчен генә, ялганнан гына эшләү, икейөзлеләк. — *сущ.* Лицемерие, двуличие.

**Рияз** رياض *ис.* Бакчалар, чәчәклекләр. — *сущ.* Сады, цветники.

**Риязият** رياضيات *ис.* Математика. — *сущ.* Математика.

**Риязый** رياضى *с.* 1) Математик, математика белгече. 2) Ябыгу өчен ашаудан тыелып, ашау һәм эчүдә чикләнүче, аз ашаучы. 3) Спортчы. — *прил.* 1) Математик. 2) Воздерживающийся в пище с целью уменьшения веса. 3) Спортсмен.

**Риязыйюн** رياضيون Риязый- нең *к.* — *мн.* от риязый.

**Риязәт** رياضت *ис.* Теләкләрне тыеп тору, ашау һәм эчүдә чикләнүчелек. — *сущ.* Воздержание в пище.

**Риякяр** رياكار *гф. ис.* Эшне кешегә күрсәтү өчен генә, ялганнан гына эшләүче кеше, икейөзлелек итүче. — *ар.- п. сущ.* Лицемер; двуличный, притворный, ханжа.

**Риякяранә** رياكارانه *гф. ст.* Икейөзлелек белән, рияланып. — *ар.-п. сс.* Двулично, притворно, лицемерно.

**Риясәт** رياست *ис.* Рәислек итү, башлык булу (сайланып куелган кешенең). *Риясәт әсасы хәсәб вә нәсәб түгелдер, бәлки гакыл вә фазылдыр.* (Г. Фәез.) — *сущ.* Главенствование, председательствование.

**Рияx** رياح Рих-нең *к.* — *мн.* от рих.

**Рияән** ريآ *р.* Кешегә күрсәтү өчен генә, ялганнан гына. *Ихлас күңелдән булмаенча, рияән егъламакый дип бел.* (К. Нас.) — *н.* Притворно (что-либо делающий).

**Риәт** رئة *ис. анат.* Үпкә. *Ике риәт дигәнемез ике олы әгъзадыр, күкрәк куышын тутырып торалар.* (К. Нас.) — *сущ. анат.* Лёгкие.

**Рижа** رجا *кара:* рәжа. — *сущ. см.* Рәжа.

**Рижал** رجال *ис.* Рәжел I-нең *к.* — *мн.* от рәжел I.

**Рижале могтәбәран** — игътибарлы ирләр. — Почтенные мужи.

**Рижгать, рәжгать** رجعت *ис.* Кайту, чигенү, кире кайту, дүнү. *Сез заты гали бурая рәжгатеңез белән хата япмышсыз.* (Г. Ибр.) — *сущ.* Возвращение, отступление.

**Рижел** رجل *ис.* Аяк. — *сущ.* Нога.

**Робагый** رباعی *с.* 1) Дүртле. 2) *грам.* Тамыры дүрт хәрефле фигыль. 3) Дүрт юллы тезмә. *Әллә нинди робагыйлар укый, синнән башка тора алмыйм, ди* (Г. Газиз). — *прил.* 1) Четверной, состоящий из четырех. 2) *грам.* Четырехбуквенный глагол. 3) Четверостишие.

**Робагый мөжәррәд** — тамыры дүрт хәрефле фигыль. — Четырехбуквенный глагол.

**Робагый мәзид** — тамыры дүрт хәрефле фигыльгә хәрефләр арттырып ясалган биш, алты хәрефле фигыль. — Глагол, в котором имеется более четырёх букв.

**Робагыйять** رباعیت *ис.* Дүрт юллы, ягъни ике бәетле тезмәләр. — *сущ.* Четверостишие.

**Робгъ** ربع *сан* Дүрттән бер, чирек. — *ч.* Четвертая часть, четверть.

**Рокга** رقعه *ис.* 1) Записка, язма, кәгазь кисәге. 2) Гарәп язуының каллиграфик бер төре. — *сущ.* 1) Записка, клочок бумаги. 2) Разновидность (арабского) почерка.

**Ромман** رمان *ис.* Анар җимеше. — *сущ.* Гранат (фрукт).

**Ромых** رمح *ис.* Сөнге. — *сущ.* Пика, копьё.

**Ротубәт** رطوبت *ис.* Юешлек, дым. *Күз эчендә өч төрле ротубәт бардыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Сырость, влажность.

**Рохсар** رخسار *ф. ис.* Йөз, яңак, чырай. *Әя пәри рохсарларның күреккә бае.* (Хорәз.) — *п. сущ.* Обличье, общий вид, лицо.

**Рожуг** رجوع *ис.* Кайту, кире кайту, элекке хәленә кайту. — *сущ.* Возвращение.

**Ру** رو *ф. ис.* Йөз, бит. — *п. сущ.* Лицо, физиономия.

**Рубәрү** روبرو *ф. р.* Кара-каршы, йөзгә йөз.

*п. н.* Лицом к лицу.

**Руи зәмин**
**Руй зәмин**
**Руе зәмин** } روی زمین *ф. гыйб.* Жир йөзе. *Руи зәминчән, ягъни җир йөзеннән булырмын диде.* (К. Нас.)

*п. фр.* „Лицо земли“, земля.

**Руз** روز *ф. ис.* Көн, көндез.

*п. сущ.* День.

**Рузгяр** روزگار *ф. ис.* 1) Заман, вакыт. 2) Яшәү. 3) Җил.

*п. сущ.* 1) Время, эпоха. 2) Жизнь. 3) Ветер.

**Рузи** روزی *ф. ис.* 1) Ризык, көнлек азык. 2) Язмыш, өлеш. *Рузи кылса мән колыңа хак зәбан...* (Мөхм.)

*п. сущ.* 1) Хлеб насущный, дневное пропитание. 2) Судьба, удел, доля.

**Рузнамә** روزنامه *ф. ис.* 1) Газета. 2) Көндәлек дәфтәр, календарь.

*п. сущ.* 1) Газета. 2) Дневник, календарь.

**Рузә** روزه *ф. ис.* Ураза.

*п. сущ.* Ураза (мусульманский пост).

**Рум** روم *ис.* Грек, византияле.

*сущ.* Грек, византиец.

**Румал, руймал** رومال *ф. ис.* Сөлге, йөз сөрткеч, яулык.

*п. сущ.* Полотенце, платок.

**Руми** رومی *с.* Рум иленеке, грек иленеке, грекныкы.

*прил.* Греческий, византийский.

**Русияһи, русияһ** روسیاه *ф. ст.* Йөз каралыгы, кара йөз. *Иң бөек максат безем хөр мәмләкәт — хөр Русия! из генә кузгалмыйбыз без, и груһе русияһ.* (Г. Тук.)

*п. сс.* Бесславный, опозоренный.

**Рух*** روح *ис.* Җан, рух. *Укып рухыңны гали әйләсәң, җибрил булу мөмкин...* (Г. Тук.)

*сущ.* Дух, душа.

**Рухан** روحاً *р.* Рухи яктан. *Шулай ук мин рухан үләрменмени.* (Г. Сон.)

*н.* Духовно.

**Рухани*** روحانی *с.* 1) Дин башлыгы, рухани. 2) Рухи, җан(га караган), җанныкы, эчке. *Аларны рухани ләззәтләреннән аерырга теләмәдек.* (М. Гаф.) 3) Исеме бар, гәүдәсе юк нәрсә (пәри, җен).

*прил.* 1) Духовный, представитель духовенства; мулла. 2) Внутренний, духовный. 3) Дух, демон.

**Руханиять** روحانیت *ис.* Руханилык.

*сущ.* Духовность.

**Рухи** روحی *с.* Рух(ка караган).

*прил.* Духовный, душевный.

**Рух рахәт** روح راحت *гыйб.* Җан рәхәте, җанга рәхәтлек. *Рух рахәт мөҗдәләрвән диюр имди.* (К. Гал.)

*фр.* Душевное спокойствие, моральное удовлетворение.

**Рух рәван** روح روان *гф. гыйб.* Китүче җан, китүче рух. *Елый хан кычкырып: и җаннарым, и каһарманнарым, җаным сөйгән ике шаһзадәм, и рухым рәваннарым.* (Г. Тук.)

*ар.-п. фр.* Уходящая душа.

**Рәббани** ربانى *с. дини* Аллага караган, алланыкы, алла тарафыннан булган.

*прил. рел.* Божественный, божеский.

**Рәббания** ربانيه Рәббани-нең *мнс.*

*жен.* от рәббани.

**Рәбиб** ربيب *ис.* Үги ул, асрап үстергән бала. *Әй бүре, куемны үтердең, хәлбуки син ул куйның рәбибесең.* (К. Нас.)

*сущ.* Пасынок, воспитанник, питомец.

**Рәбибә** ربيبه Рәбиб-нең *мнс.*

*жен.* от рәбиб.

**Рәва** روا *ф. с.* Яраклы, ятышлы. *Тәҗавез әйләмәк хәддин рәвамы* (чиктән үтеп эш итү ярыймы). (Һ. Сал.)

*п. пр.* Дозволительный, допустимый, приемлемый, приличествующий.

**Рәвабит** روابط *ис. к.* Бәйләнешләр, элемтәләр.

*сущ. мн.* Связи, отношения, союзы.

**Рәван** روان *ф. ис.* Китүче, агучы, юнәлүче.

*п. прил.* Идущий, уходящий; текущий.

**Рәваих** روايح Раихә-нең *к.*

*мн.* от раихә.

**Рәваҗ** رواج *ф. ис.* Таралу (сатуда); базарда уңышлы сатылу.

*п. сущ.* Распространение, обращение (товара).

**Рәвеш*** روش *ф. ис.* Рәвеш, төс, ысул.

*п. сущ.* Образ действий, метод, способ, приём.

**Рәгаиб** رغائب *ис. к.* 1) Хыяллар, теләкләр. 2) Рәҗәб аеның беренче җомгасында дини бәйрәм кичәсе.

*сущ. мн.* 1) Мечты, желания. 2) Религиозный праздничный вечер в первую пятницу месяца „рәҗәб".

**Рәгаяә** رعايه *ис. к.* Бер дәүләтнең халыклары.

*сущ. мн.* Подданные, население.

**Рәгъбәт** رغبت *ис.* 1) Теләү, омтылыш, кызыксыну, кызыгу. 2) Үрнәк. *Шәһәр әһалисе Гайниҗамал абыстайны рәгъбәттә тоталар иде.* (М. Ак.)

*сущ.* 1) Желание, стремление, страсть. 2) Образец, пример.

**Рәгъмән** رغماً *р.* Карышып, беләторып, каршылык итеп. *Бөтен куәтле манигъларга рәгъмән үсә.* (Җ. Вәл.)

*н.* Несмотря на..., наперекор, назло.

**Рәгъна** رعنا *ф. ис.* **1.** Гүзәл, матур, күңел тапкыч, ямьле. **2.** Бер гөл (чәчәк) исеме. — *п. сущ.* **1.** Миловидный, красивый, изящный. **2.** Название цветка.

**Рәгъшә** رعشه *ис.* 1) Сискәнү, куркудан калтырау. 2) Туңудан калтырау. — *сущ.* 1) Дрожь, трепет. 2) Озноб.

**Рәгыд** رعد *ис.* Күк күкрәү. — *сущ.* Гром.

**Рәгый** رعى *ис.* Утлату, хайван көтү. — *сущ.* Пастьба, скотоводство.

**Рәгыйф** رعيف *ис.* Икмәк, кабартма. *Дөньяның эше өч түгәрәк нәрсә өстендә әйләнәдер: динар, дирһәм, рәгыйф.* (К. Нас.) — *сущ.* Лепёшка.

**Рәгыйя, рәгыйять** رعيه، رعية *кара:* рәгаяэ. *Адәмнең гакылы падиша, ә башка төрле мөгамәләсе вә кыйлмышлары рәгыйять мәнзилендәдер.* (К. Нас.) — *см.* Рәгаяэ.

**Рәгым** رغم *ис.* 1) Күрәлмау, белә торып бирәүгә начарлык эшләү. 2) Каршы хәрәкәт. — *сущ.* 1) Ненависть, отвращение. 2) Противодействие.

**Рәд (рәдд)** رد *ис.* Кабул итмәү, кире кайтару, кире кагу ... *баш кодаларның тәклифене рәд итмәеп.* (М. Ак.) — *сущ.* Отвержение, отказ.

**Рәддия** رديه *ис.* Кире кагу, юкка чыгару, дөрес түгеллеген күрсәтү. — *сущ.* Опровержение.

**Рәдиф** رديف *ис.* 1) Запаста тора торган гаскәр. 2) Берәүгә ияреп баручы, арттан баручы, иярчен (планета). — *сущ.* 1) Запасные воинские части. 2) Последователь; спутник (планета).

**Рәдиэ** ردئ *с.* Начар, бозык, бозылган. *Тәнәффес васитасы белән ләтыйф һава эчкә кергәч, филхаль эчнең хәрарәтеннән бер кәйфият рәдиэ кәсеп итәр.* (К. Нас.) — *прил.* Плохой, негодный.

**Рәеб** ريب *ис.* Шик, шикләнү, шөбһә. — *сущ.* Сомнение, неуверенность.

**Рәзаил** رذائل Рәзаләт-нең *к.* — *мн.* от рәзаләт.

**Рәзаләт** رذالت *ис.* Хурлык, түбәнлек, яманлык. — *сущ.* Низость, гнусность, подлость.

**Рәзанәт** رذانت *ис.* Ныклык, тынычлык, җитдилек, мөһимлек. — *сущ.* Спокойствие, невозмутимость, серьезность, важность.

**Рәззак** رزاق *ис.* Ризык бирүче, аш бирүче. — *сущ.* Дающий средства к жизни, питающий.

**Рәзил** رذيل *с.* Түбән, хур, начар. *Күп саташтырдык рәзил шәйтанны чын инсан белән.* (Г. Тук.) — *прил.* Низкий, подлый, порочный.

**Рәзилә** رذيله Рәзил-нең *мнс.* — *жен.* от рәзил.

**Рәзыйг** رضيع *с.* 1) Сөт кардәше. 2) Имчәк баласы. — *прил.* 1) Молочный брат. 2) Грудной ребёнок.

**Рәи** رأى *ис.* Караш, фикер, уй, акыл. *Рәие вә тәдбире зәгыйфь кешенең дошманы куәтле булыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Взгляд, мнение, мысль, разум.

**Рәи саиб** رأى صائب *гыйб.* Туры фикер, хатасыз фикер, дөрес караш. — *фр.* Правильная мысль, правильный взгляд на что-либо.

**Рәис** رئيس *ис.* Башлык итүче, рәис, җитәкче. *Сез рәисе золаманы „Йолдыз“ә хибес иттегез.* (Г. Тук.) — *сущ.* Стоящий во главе; глава, председатель, начальник, управляющий.

**Рәйхан** ريحان *ис.* Зәңгәр чәчәкле хуш исле гөл, рәйхан. — *сущ.* Название цветка базилика.

**Рәкабә** رقبه *ис.* 1) Муен. 2) Шешә муены. 3) Кол, тоткын. — *сущ.* 1) Шея. 2) Горлышко. 3) Раб, невольник.

**Рәкабәт** رقابت *ис.* 1) Ярыш, көндәшлек, башкалардан өстен булырга тырышу, конкуренция. 2) Күзәтү. — *сущ.* 1) Соревнование, соперничество, конкуренция. 2) Слежка, наблюдение, контроль.

**Рәкез** ركز *м. I.* 1) Утырту, кадап кую. 2) Ныклык, тынычлык. — *м. I.* 1) Втыкание, вбивание. 2) Спокойствие, твердость.

**Рәкъкас** رقاص *ис.* Биюче. — *сущ.* Пляшущий, плясун.

**Рәкъкасә** رقاصه *ис.* Биюче хатын, балерина ... *рәкъкасә: „Кул һөнәрем юк, аяк һөнәрем бар“, — диде.* (К. Нас.) — *сущ.* Танцовщица, балерина.

**Рәкъсан** رقصاً *р.* Биеп, бию белән. — *н.* Пляской, танцем.

**Рәкыйб** رقيب *ис.* 1) Конкурент, бер эштә башкалардан өстен булырга теләүче, ярышчы. *Рәкыйби Рәкыйб, рәкыйбең булды Рахманкул вафат.* (Ш. Баб.) 2) Саклаучы. — *сущ.* 1) Конкурент. 2) Наблюдатель, стоящий на страже.

**Рәкыйк** رقيق *ис.* 1. Юка, нечкә, нәзек. 2. Иректән мәхрүм ителгән, кол. — *сущ.* 1. Тонкий, мягкий, нежный. 2. Невольник, раб.

**Рәкым** رقم *ис.* Цифр, сан сүзләрен күрсәтә торгаң билгеләр, саннар (1, 2, 3). — *сущ.* Цифра, номер, число.

**Рәкыс** رقص *ис.* Бию. *Сәнең әшгаренә, бәнчә, агач, даш билә рәкъсандыр. Агач рәкыс итмәмәк шагыйрь улан инсанә ноксандыр.* (Г. Тук.) — *сущ.* Пляска, танец.

**Рәкәгать** ركعت *ис.* Намазның аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә куюны эченә алган бер өлеше. — *сущ.* Коленопреклонение, поклон (во время молитвы).

**Рәмад** رماد *ис.* Көл. — *сущ.* Пепел, зола.

**Рәмез** رمز *ис.* Символ, берәр сүзне аңлата торган галәмәт, ишарә. — *сущ.* Знак, символ.

**Рәмел** رمل *ис.* 1) Ком. 2) Ком, вак таш белән күрәзәлек итү. 3) Һәр юлы дүрт „фагыйлатен"нән торган шигырь үлчәве – бәхре рәмел. — *сущ.* 1) Песок. 2) Гадание на песке, мелких камнях. 3) „Рамль" — размер стиха.

**Рәмех** رمح *ис.* Сөнге. *Гарәпчә вәрак рәмхи — очлы яфрактыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Копьё, пика.

**Рәми** رمى *ис.* Ату, ук ату. *Мин димен: „дус, бу рәмиең һич ярамый".* (Г. Тук.) — *сущ.* Бросание, швыряние, стрельба.

**Рәммаль** رمال *ис.* Комга сызыклар сызу юлы белән киләчәк турында хәбәр бирүче, фалчы. — *сущ.* Гадатель на песке, предсказатель.

**Рәмәд** رمد *ис. мед.* Күз авыруы. — *сущ. мед.* Афтальмия, воспаление глаз.

**Рәмәкъ** رمق *ис.* 1) Соңгы сулыш, үлем алдында актык сулышлар. 2) Тереклекнең соңгы калдыгы. *Хәятыннан рәмәкъ калмыш, су бирәем.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Последний вздох. 2) Остаток, искра жизни в теле.

**Рәнд** رند *ф. ис.* 1) Тотнаксыз, типтерүче. 2) Юлдан чыккан кеше, азгын кеше. *Хәрабәт эчрә, мәсҗиддә йирем бар кем, уш һәм рәндмен, һәм парса.* (Хорәз.) — *п. сущ.* 1) Кутила, беспутный, гуляка. 2) Плут, проказник.

**Рәнек, рәң** رنك ، رنگ *ф. ис.* 1) Төс. *Сачы коңгыр рәңдә улып...* (М. Ак.) 2) Хәйлә. 3) Икейөзлелек. — *п. сущ.* 1) Цвет, окраска, краска. 2) Хитрость, обман. 3) Лицемерие, двуличие.

**Рәнеж** رنج *ис.* Авыру, җәфа, мәшәкать, кайгы, ачыну. *Рәнеҗ хәтәр булганын әлнең суыктан белде яз.* (Дәрд.) — *сущ.* Мучение, обида, огорчение, гнев.

**Рәнкин, рәңгин** رنكين ، رنگين *ф. с.* Төсле, матур, зиннәтле, гүзәл. — *п. прил.* Цветной, густо окрашенный, красочный, красивый.

**Рәнкявәр, рәңгявәр** رنكاور، رنگاور *ф. с.* Хәйләкәр, икейөзле. — *п. прил.* Хитрый, двуличный.

**Рәнкярәнк, рәңгярәң** رنكارنك *ф. с.* Төрле-төрле төстәге. — *п. прил.* Разноцветный, разнообразный.

**Рәнҗур** رنجور *ф. ис.* Авыру, хаста, чирле, рәнҗү. — *п. сущ.* Больной, немощный.

**Рәсад** رصد *ис.* Нечкәләп күзәтү, телескоп аркылы кояш, ай, йолдызларны карау. — *сущ.* Наблюдение (в телескоп), высматривание.

**Рәсад ханә** رصدخانه *ф. ис.* Обсерватория. — *п. сущ.* Обсерватория, наблюдательный пункт.

**Рәсаил** رسائل Рисалә-нең *к.* — *мн.* от рисалә.

**Рәсас** رصاص *ис.* Кургашын, кара кургаш. — *сущ.* Свинец.

**Рәсем*** رسم *ис.* 1) Сурәт, рәсем; сызу, язу. 2) Гадәт. — *сущ.* 1) Портрет, чертеж, план, рисунок. 2) Обычай, правило.

**Рәсидә** رسيده *ф. с.* Ирешкән, житешкән, өлгергән. — *п. прил.* Созревший, спелый; достигший, дошедший; совершеннолетний.

**Рәсме хат** رسم خط *гыйб.* Язу — почерк. *Зөләйханың рәсме хатын белә иде.* (З. Биг.) — *фр.* Почерк.

**Рәсми*** رسمی *с.* Официаль, рәсми. — *прил.* Официальный, законный, форменный.

**Рәсмиять** رسميت *ис.* Рәсмилек. — *сущ.* Официальность.

**Рәсмә** رسمه *р.* Көенчә. *Мәху итәрмисән бу рәсмә, дилбәрем, бу шагыйри.* (Г. Тук.) — *н.* Таким образом, таким путем.

**Рәсмән** رسماً *р.* Рәсми рәвештә. — *н.* Официально, по форме.

**Рәссам*** رسّام *ис.* Рәсем ясаучы, художник. *Художниклар вә рәссамнар да бардыр, юк дия алмаслар.* (Г. Тук.) — *сущ.* Рисовальщик, художник, иллюстратор.

**Рәсүл** رسول *ис.* 1) Илче. 2) Пәйгамбәр. — *сущ.* 1) Посланец, посол, посланник, эмиссар. 2) Апостол, пророк.

**Рәтыйб** رطيب *с.* Юеш, дымлы; яшел, яшь. — *прил.* Влажный, волглый, свежий.

**Рәфәкать** رفاقت *ис.* Иптәшлек, юлдашлык. — *сущ.* Сопровождение.

**Рәфаһ** رفاه *ис.* Киң (иркен) тереклек, муллык. *Будыр чын милләтнең раһе рәфаһи.* (Г. Тук.)
*сущ.* Процветание, благосостояние, удобства жизни.

**Рәфаһиять, рәфаһәт** رفاهيت، رفاهت *ис.* Муллык, иркен (киң) тереклек. *Һәрбер милләтнең тәрәкъкый вә тәгали кылып, рәфаһәт, сәгадәт үзәренә хәят сөрә белүе иттифак, иттихад, гайрәт вә сөбат аркасындадыр.* (Г. Ибр.)
*сущ.* Благосостояние, достаток, изобилие.

**Рәфгать** رفعت *ис.* Югарылык, бөеклек; зур дәрәҗә. *Тәмам морадыңча рәфгатьдәдер, дәүләт ияседер, вәлидер, диде.* (К. Нас.)
*сущ.* Возвышение; высокое положение.

**Рәфгъ, рәфыг** رفع *м. I.* 1) Күтәрү, югары мендерү, күтәреп алу. *Рәфгъ улсын җөмлә хәсрәт, фәкъре, хәкъре, мәскәнәт.* (Г. Тук.) 2) Тавышны күтәрү.
*м. I.* 1) Подъём, возвышение. 2) Повышение голоса.

**Рәфигъ** رفيع *с.* 1) Күтәрелгән, күтәренке. 2) Югары, биек. 3) Бөек.
*прил.* 1) Поднятый, приподнятый. 2) Высокий, знатный. 3) Великий.

**Рәфика** رفيقه *ис.* 1) Иптәш хатын. 2) Кәләш, хатын. *Хәсән мулланың гомерлек рәфикасе улган иде.* (З. Һад.) 3) Йомшак күңелле.
*сущ.* 1) Подруга. 2) Спутница, жена. 3) Мягкая, добрая.

**Рәфикъ** رفيق *ис.* Иптәш, юлдаш, дус. *Зәгыйфьләргә рәфикъ, сагларга каид.* (Г. Тук.)
*сущ.* Товарищ, друг, спутник.

**Рәфтар** رفتار *ф. ис.* Мөгамәлә, эш итү, үз-үзен тоту, йөреш-торыш. *Кәрәктер ир углыга нәфәр рәфтар.* (Мөхм.)
*п. сущ.* Обращение, поведение, обхождение.

**Рәха** رخا *ис.* Муллык, иркенлек.
*сущ.* Изобилие, благосостояние, благоденствие, благополучие.

**Рәхавәт** رخاوت *кара*: рәха.
*см.* Рәха.

**Рәхем** رحم *м. I.* Аяу, жәлләү, кызгану, шәфкатьлелек күрсәтү.
*м. I.* Милосердие, сострадание, помилование.

**Рәхим** * رحيم *с.* Аяучан, кеше өчен ачынучы, рәхимле. *Аның үзенең ихтыярында, ходай кадир, рәхим.* (Ш. Кам.)
*прил.* Милосердный, милостивый.

**Рәхман** رحمان *ис. дини* Аяучы, мәрхәмәт итүче (алла эпитеты).
*сущ.* Милосердный, милостивый (эпитет аллаха).

**Рәхмани** رحمانى *с.* Алланыкы, алладан булган, алла тарафыннан булган.
*прил.* Божеский, божественный.

**Рәхмәт** * رحمت *ис.* 1) Аяу, кичерү, мәрхәмәт итү. *Бәлки рәхмәт яңгырыдыр, яшьнәсен ул, яшьнәсен.* (Г. Тук.) 2) Яхшылыкка җавап итеп әйтелә торган сүз.

*сущ.* 1) Милосердие, сострадание, милость. 2) Благодарность. 3) Спасибо.

**Рәхшан** رخشان *ф. с.* Якты, ялтыраучы.

*п. прил.* Блестящий, сияющий.

**Рәхәт** * راحت *ис.* Тынычлык, җан тынычлыгы, ял, унайлык, кинәнү, ләззәтләнү, зәвыклану.

*сущ.* Спокойствие, покой, отдых, удобство, блаженство; наслаждение, удовольствие.

**Рәшад** رشاد *ис.* Туры юл тоту, туры юлга керү.

*сущ.* Вступление на путь истинный.

**Рәшадәт** رشادت *ис.* 1) Туры юлга күндерүчелек. 2) Батырлык, егетлек.

*сущ.* 1) Наставление на путь истинный. 2) Мужество, храбрость.

**Рәшек** رشك *ф. ис.* Көнчелек, көндәшлек, көнләп (кызыгып) ярышу. *Җамалига ай-көн рәшек илтәр ирделәр* (Мәҗмәгыл хикәять).

*сущ.* Зависть, ревность, соперничество.

**Рәшид** رشيد *с. кара:* рашид.

*прил.* см. Рашид.

**Рәэс** رأس *ис.* 1) Баш. 2) Башлангыч. 3) *геогр.* Борын.

*сущ.* 1) Голова, глава. 2) Начало. 3) *геогр.* Мыс.

**Рәэселмал** رأس المال *гыйб.* Төп капитал, мая.

*фр.* Капитал, основной капитал.

**Рәэсән** رأساً *р.* Үзлегеннән, иярмичә.

*н.* Прямо, непосредственно, самолично.

**Рәэфәт** رأفت *ис.* Ачыну, күңел әрнү, кызгану, шәфкать.

*сущ.* Сострадание, жалость.

**Рәяхин** رياحين *ис.* Рәйхан-ның *к.*

*сущ. мн.* от рэйхан.

**Рәүза** روضه *ис. кара:* рауза.

*см.* Рауза.

**Рәүнәкъ** رونق *ис.* Бизәк, гүзәллек, яктылык, ачыклык. *Кәлер рәүнәкъ колубә, сүзләреннән җанә сайкалләр.* (Г. Тук.)

*сущ.* 1) Блеск, сияние. 2) Красота.

**Рәүф** رؤف *ис.* Бик мәрхәмәтле, шәфкатьле, кайгыны уртаклашучы.

*сущ.* Милосердный, добрый, сострадательный.

**Рәушан, рушан** روشن، روشان *ф. с.* Яктыртучы, нурлы, ачык.

*п. прил.* Светлый, ясный, сияющий, лучезарный, лучистый.

**Рәушани** روشانى *ф. ис.* Нурлылык, ачыклык.

*п. сущ.* Сияние, освещение.

**Рәҗа, риҗа** رجا *ис.* Сорау, үтенү, теләү, өмет итү. *Бәйнәлхәуф вә риҗа булмага тәнбиһдер.* (К. Нас.) — *сущ.* Просьба, мольба; желание; надежда, ожидание.

**Рәҗел I** رجل *ис.* Ир кеше, ир — *сущ.* Муж, мужчина.

**Рәҗел II** رجل *ис. к.* Җәяүлеләр. — *сущ. мн.* Пешие.

**Рәҗем** رجم *ис.* Кешене билгә кадәр җиргә күмеп ташлар атып үтерү. (Борынгы гарәпләрдә үлем җәзасының бер төре булган.) — *сущ.* Избиение камнями человека, по пояс зарытого в землю (один из видов религиозного наказания у древних арабов).

**Рәҗим** رجيم *с.* Таш атып куылган (сөрелгән) шәйтан. *Рәҗим шәйтан аздырмага узаныптыр.* (К. Гал.) — *прил.* Побиваемый камнями, проклятый (эпитет дьявола).

**Рәҗәб** رجب *ис.* Ай елының җиденче ае исеме. — *сущ.* Седьмой месяц лунного календаря.

**Рәҗәз** رجز *ис.* Шигырь үлчәвенең бер төре. — *сущ.* Раджаз (стихотворный размер).

**Рәҗүләт, рәҗүлият** رجولت ، رجوليت *ис.* 1) Ирлек, егетлек. 2) Ир булып җиткәнлек. 3) Ирдарлык. — *сущ.* 1) Мужское достоинство. 2) Возмужалость. 3) Мужественность, мужество.

**Рәң** رنگ *ф. ис. кара:* рәнек. — *п. сущ. см.* Рәнек.

**Рәһ** ره *кара:* раһ. — *см.* Раһ.

**Рәһбан** رهبان *ис.* Монах. — *сущ.* Монах.

**Рәһбанияпь** رهبانيت *ис.* Монахлык. *Исламда хәрам булган рәһбанияпь — дәрвишлек каплады, диде.* (Г. Ибр.) — *сущ.* Монашество, аскетизм.

**Рәһбәр** رهبر *ф. ис.* 1) Юл күрсәтүче. 2) Житәкче, юлбашчы. 3) Башлаучы, күрсәтүче. — *п. сущ.* 1) Путеводитель, проводник. 2) Руководитель, вождь. 3) Начинающий, показывающий.

**Рәһеб** رهب *ис.* Курку. — *сущ.* Боязнь, страх.

**Рәһен** رهن *ис.* Заклад, закладка салу. *Бу кәмәрләр сездә рәһен кебек торсын.* (К. Нас.) — *сущ.* Залог, заклад; заложник.

**Рәһин** رهين *ис.* Закладка салынган әйбер. — *сущ.* Заложенная вещь.

**Рәһнәма** رهنما *ф. ис.* Белешмәлек. — *п. сущ.* Справочник.

**Рәһнәмүн** رهنمون *ф. ис.* Юлбашчы, юл күрсәтүче. *Әгәр кәнеҗ галәм арзуың булса, аңа рәһбәр вә рәһнәмүн булаем* (Мәҗмәгыл хикәять). — *п. сущ.* Путеводитель, проводник.

**Рөбубиять** ربوبيت *ис.* 1) Аллалык, тәңрелек, ходалык. 2) Хуҗалык, хөкем йөртүчелек. — *сущ.* 1) Божество́. 2) Господство, власть.

**Рөбыг** ربع *ис.* Дүрттән бер өлеш, чирек. — *сущ.* Четверть, четвертая часть.

**Рөкеб** ركب *ис.* Тез; тез буыны. — *сущ.* Колено; коленный сустав.

**Рөкен** ركن *ис.* 1) Багана, терәк. *Милләтнең иң мөһим рөкене — әдәбият.* (Ж. Вәл). 2) Почмак. 3) Әйбернең төп өлеше. 4) Нигез. — *сущ.* 1) Колонна, столб. 2) Угол. 3) Главная составная часть. 4) Основа.

**Рөкүб** ركوب *ис.* Менү (атлану, арбага утыру). — *сущ.* Посадка (на что-либо, чтобы ехать).

**Рөкүгъ** ركوع *ис.* Иелеп тору, намазда тезләргә таяну. — *сущ.* Поклон в пояс, коленопреклонение.

**Рөмүз** رموز Рәмез-нең *к.* — *мн.* от рәмез.

**Рөсвай** رسواى *кара:* рисвай. — *см.* Рисвай.

**Рөсел** رسل Рәсүл-нең *к.* — *мн.* от рәсүл.

**Рөсуб** رسوب *ис.* Дуен, юшкын. — *сущ.* Осадок, отстой.

**Рөсүм** رسوم *ис.* 1) Рәсем-нең *к.* 2) Пошлина, салым, базар җыемы. — 1) *мн.* от рәсем. 2) Пошлина, налог, сборы.

**Рөтбә** رتبه *ис.* Мәртәбә, дәрәҗә. *Җәлалетдин Сабитовка имам хатыйп вә мөдәррис рөтбәсе игъта кылынды.* (Г. Ибр.) — *сущ.* Степень, достоинство, звание, ранг, чин.

**Рөтубәт** رطوبت *ис.* Юешлек, дым. *Тәбәнәк җирдә рөтубәт күп буладыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Влага, сырость.

**Рөтәб** رتب *ис.* Рөтбә-нең *к.* — *мн.* от рөтбә.

**Рөфәкаә** رفقاٴ *ис.* Рәфикъ-нең *к.* — *мн.* от рәфикъ.

**Рөхем** رحم *ис.* 1) *анат.* Бала капчыгы (корсакта бала ята торган урын). 2) Кардәшлек. 3) Эч як. — *сущ.* 1) *анат.* Матка. 2) Родство. 3) Внутренность чего-либо.

**Рөхсәт*** رخصت *ис.* 1) Ризалык. 2) Ирек, ихтыяр. 3) Рөхсәт, изен. — *сущ.* 1) Согласие. 2) Воля, выбор. 3) Разрешение, позволение.

**Рөхсәтнамә** رخصتنامه *гф. ис.* Рөхсәт язуы. — *ар.-п. сущ.* 1) Письменное разрешение. 2) Отпускное свидетельство.

**Рөшди, рөшдия** رشدى، رشديه *ис.* Башлангычтан югары (урта) мәктәп. — *сущ.* Школа средней ступени.

**Рөшед** رشد *м. I.* 1) Туры юлга китү, туры юл табу, туры юлда булу. 2) Дөрес төшенү, акыл иясе булу. 3) Житешү, балалыктан чыгу. *Ошбу вакыт инсан да рөшед вә бөлуг дәрәҗәсенә ирешкән хисаб иделәдер.* (Ш. ж.) — *м. I.* 1) Быть на правильном пути. 2) Зрелость (ума). 3) Достижение совершеннолетия.

**Рөштә** رشته *ф. ис.* Җеп. *Рөштә әфкяр* — уй җебе. *Мәңа тикмәс олуглар рөштәсигә катыйлмага (катышырга, кушылырга).* (Мөхм.) — *п. сущ.* Нить, волокно.

**Рөэя** رؤيا *ис.* Төш (йокыда). — *сущ.* Сновидение.

**Рөэять** رؤيت *ис.* 1) Күрү, төш күрү. 2) Яңа айны күрү. *Һилал турында күп ызгышканнар: „Рөэятьме, әллә башканымы игътибар итәргә кирәк?“* (Г. Газиз). — *сущ.* 1) Видение, сновидение. 2) Видение новой луны.

**Рөэүс** رؤس *ис.* Рәэс-нең *к.* — *сущ. мн.* от рәэс.

**Рөэүса** روسا *ис.* Рәис-нең *к.* — *сущ. мн.* от рәис.

**Рөҗүгъ** رجوع *м. I. кара:* рожуг. — *м. I. см.* Рожуг.

**Рөҗхан** رجحان *ис.* Өстенлек, артыклык. *Берсеннән берсе артыклыгына хөкем итә алмадым, зирә беренең рөҗханына хөкем итмәкче булдым, икенчесе хөҗҗәд белән килде.* (К. Нас.) — *сущ.* Превосходство; превышение.

# С

**С** — татар әлифбасында унсигезенче хәреф булып, гарәп әлифбасындагы дүртенче хәреф „ث“ (сакау әйтелешле „с“), уникенче хәреф „س“ (нечкә әйтелешле „с“), ундүртенче хәреф „ص“ (калын әйтелешле „с“) хәрефләре урынына йөри. Әбҗәд хисабында ث — 500, س — 60, ص 90 га йөри. — В татарском алфавите восемнадцатая буква, отображает три арабских буквы: а) междузубное „с“ (ث); б) мягкое „с“ (س) и в) твердое „с“ (ص). Цифровое значение ث — 500, س — 60, ص — 90.

**Са** ثا *кара:* си. — *см.* Си.

**Саба** صبا *ис.* Көнчыгыштан искән йомшак җил. — *сущ.* 1) Восточный ветер. 2) Ветерок, зефир.

**Сабавәт** صباوت *ис.* Сабыйлык, балалык. *Очып төш тә сабавәт бимегеннән.* (Г. Тук.) — *сущ.* Детство, Молодость, ребячество.

| | |
|---|---|
| **Сабак** * سبق *ис.* Дәрес. | *сущ.* Урок. |
| **Сабах** صباح *ис.* Иртә, таң. *Сабахка ирешкәч, хатынны куып җибәрделәр.* (К. Нас.) | *сущ.* Утро, рассвет. |
| **Сабах-шам** صباح - شام *ф. р.* Иртәкич. *Бәнем ядымда бу ахшам сабахшам.* (Г. Тук.) | *п. н.* Утром и вечером. |
| **Саббаг** صباغ *ис.* Буяучы, маляр. | *сущ.* Красильщик, маляр. |
| **Сабигань** سابعاً *р.* Җиденчедән, җиденчеләй. | *н.* В-седьмых, седьмым. |
| **Сабигъ** سابع *сан* Җиденче. | *ч.* Седьмой. |
| **Сабика** سابقه *ис.* 1) Үткәндәге эш. 2) Начар вакыйга, җинаять. | *сущ.* 1) Прецедент. 2) Рецидив, повторное преступление. |
| **Сабикан** سابقاً *р.* Моннан элек, электә. | *н.* Раньше, прежде. |
| **Сабикъ** سابق *сф.* 1) Узучы, үтүче. 2) Алда булган. 3) Әүвәлге, үткәндәге. | *пр. д.* 1) Обгоняющий. 2) Предшествующий, предыдущий. 3) Бывший, прежний. |
| **Сабир** صابر *сф.* Түземлек күрсәтүче, түзүче, чыдаучы, сабыр итүче. *Сабир ул, чөн дөшмәмештер эшләрең сәһле сәңа.* (Г. Тук.) | *пр. д.* Терпеливый, выносливый, стойкий. |
| **Сабиранә** صابرانه *гф. р.* Түземлелек белән, чыдамлылык белән. | *ар.-п. н.* Терпеливо. |
| **Сабит** ثابت *сф.* 1) Үз уенда (үз сүзендә) нык торучы. 2) Кузгалмаучы. 3) Бер урында торучы, даими. *Әйлә шагыйрьлектә сабит, тәңрем, бәни.* (Г. Тук.) 4) Шиксез, ачык. *Анлардан гөнаһ сабит булса да... сиясәтне анларга рәва күрмиләр.* (Г. Фәез.) | *пр. д.* 1) Твердый, стойкий, непоколебимый. 2) Неподвижный. 3) Постоянный. 4) Очевидный, ясный. |
| **Сабих I** صبيح *с.* Гүзәл, матур чырайлы, матур йөзле. | *прил.* Красивый, прелестный. |
| **Сабих II** سابح *сф.* Суда йөри ала торган, суда батмый торган, йөзүче. | *пр. д.* Плавающий, плавучий. |
| **Сабиэ, сабиун** صابى، صابئون *ис.* 1) Кояш, ай, йолдызларга табынучылар. 2) Шуларның мәзһәбе. | *сущ.* 1) Поклоняющийся звездам. 2) Сабий (секта поклоняющихся солнцу, луне). |
| **Сабун** صابون *ис.* Сабын. | *сущ.* Мыло. |
| **Сабый** * صبى *ис.* Кечкенә ир бала. | *сущ.* Мальчик, младенец. |
| **Сабыя** صبيه *ис.* Сабый-ның *мнс.* | *сущ. жен.* от сабый. |

**Сабур** صبور *с.* Сабыр итүче, сабырлы. *Сабурдин яхшы юктыр пишә кылсам.* (Хорәз.) — *прил.* Терпеливый, стойкий.

**Сабух** صبوح *ис.* Иртән эчелә торган шәраб, макмырга эчелгән аракы. *Кил, әй сакый, китергел хуш сабухи.* (Хорәз.). — *сущ.* Утреннее питьё.

**Сабыр*** صبر *ис.* 1) Чыдамлык, түземлек. 2) Көтеп тору. 3) Бер төрле дару үләне исеме. — *сущ.* 1) Терпение, выносливость, стойкость. 2) Ожидание. 3) Название лекарственного растения.

**Саваб** صواب *ис.* 1) Турылык, дөреслек, хатасызлык; дөрес. *Бу кәлячы анларга савап кәлде...* (К. Гал.) 2) Туры фикер. — *сущ.* 1) Правильность. 2) Здравый смысл, благоразумие.

**Савым** صوم *ис.* Ураза. — *сущ.* Пост, соблюдение поста.

**Савын** صون *м. I.* Саклау. — *м. I.* Оберегание, сохранение, охрана.

**Сагаид** صعائد *ис. к.* Биек урыннар, тау түбәләре. — *сущ. мн.* Холмистая, гористая местность, возвышенности.

**Сагаир** صعائر Сагыйрь II-нең *к.* — *мн.* от сагыйрь II.

**Сагалик** صعالك *ис. к.* 1) Ярлылар, хәерчеләр. 2) Йолкышлар, сукбайлар. 3) Юлбасарлар, караклар. — *сущ. мн.* 1) Бедные, нищие. 2) Оборванцы, бродяги, босяки. 3) Разбойники, воры.

**Сагый** ساعی *сф.* **1.** Тырышучы. **2.** 1) Курьер, йомышка йөрүче. 2) Гайбәтче, әләкче. — *пр. д.* **1.** Старающийся. **2.** 1) Курьер, посланец. 2) Доносчик, сплетник.

**Сагыйд I** صاعد *сф.* Югары менүче, югары ашучы. — *пр. д.* Поднимающийся, восходящий.

**Сагыйд II** ساعد *ис.* Кулның терсәктән югары өлеше, беләк. *Ике сагыйдләре вә беләкләре очында сөякләре йомшак вә мөлаем бармаклары.* (К. Нас.) — *сущ.* Рука, предплечье.

**Сагыйка** صاعقة *ис.* 1) Яшен сугу. 2) Яшен, елдырым. 3) Үлем, үлем газабы. — *сущ.* 1) Удар грома. 2) Молния. 3) Смерть, предсмертная мука.

**Сагыйрь I** ساغر *ф. ис.* Эчә торган савыт, рюмка, бокал. — *п. сущ.* Чаша; рюмка; кубок для вина.

**Сагыйрь II** صغير *с.* Кече, кечкенә. *Кешенең гөнаһсы сагыйрә булса да,* — *прил.* 1) Маленький, малый, небольшой. 2) Мелкий.

*тәүбәне кичектерү сәбәпле, кәбирәгә әүрелер.* (К. Нас.)

**Сагыйрә** صغيره Сагыйрь II-нең *мнс.* — *жен.* от сагыйрь II.

**Сад** صاد *кара*: сат. — *см.* Сат.

**Сада*** صدا *ис.* Аваз, тавыш. *Назлы вә нәзек сада илә сорады.* (М. Ак.) — *сущ.* Эхо, отголосок. 2) Отклик, голос.

**Садака*** صدقه *ис.* Садака, әҗер өчен бирелгән ярдәм, хәер. — *сущ.* Милостыня, пожертвование (с религиозной целью).

**Садакаи җария** صدقه جاريه *гыйб. дини* Савабы дәвамлы садака. *Гыйлем өйрәнс', кое казыса, елга казып су йөртсә, савабы киселмәс, боларны садакаи җария диерләр.* (К. Нас.) — *фр. рел.* Добровольный вид пожертвования.

**Садат** سادات *ис.* Сәед-нең *к.* — *сущ. мн.* от сәед.

**Садир** صادر *сф.* 1) Башланучы, чыгучы. 2) Барлыкка килүче, булучы, барлыкка килгән. *Садир улды ушбу көн хактан әмере көн фәкян.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Выходящий, исходящий. 2) Рождающийся, осуществляющийся.

**Садис, садисә** سادس، سادسه *сан* Алтынчы. *Кичмәде шул хәлдә саль вә садисә.* (Г. Тук.) — *ч.* Шестой, шестая.

**Садисән** سادساً *р.* Алтынчыдан, алтынчылай, алтынчы булып. — *н.* Шестым, в-шестых.

**Сад чәндан** صدچندان *ф. р.* Йөз тапкыр, йөз кат артык. *Сине хөсен эчрә сад чәндан яратты.* (Хорэз.) — *п. н.* Во сто раз больше.

**Садыйк** صادق *сф.* Туры, дөрес, чын, эчкерсез. *Вә һәр әбхаре садыйк, гайре кязиб.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Правдивый, искренний. 2) Истинный.

**Садыйкана** صادقانه *гф. р.* Турылык белән, дөрес итеп, эчкерсез. — *ар.-п. н.* Верно, правдиво, искренне.

**Садыр** صدر *ис.* 1) Күкрәк, түш, йөрәк. 2) Түр. 3) Һәр нәрсәнең алды. — *сущ.* 1) Грудь; сердце. 2) Перёд; почётное место.

**Тәксир II** تكسير *м. II.* Сындыру, ваклау. *Җәһаләт вә надалык ардусыны идәлем тәксир.* (Г. Тук.) — *м. II.* Разбивание, разламывание.

**Тәксиф** تكثيف *м. II.* Куерту, тупасландыру; юанайту. — *м. II.* Сгущение, уплотнение; утолщение.

**Тәкфил** تكفيل *м. II.* Бирәү өчен җаваплылыкны өскә йөкләтү. — *м. II.* Возложение ответственности, отдача на поруки.

**Тәкфин** تكفين *м. II.* Кәфенләү, кәфен сару. — *м. II.* Обёртывание саваном.

**Тәкфир** تكفير *м. II. дини* 1) Динсез, дәһри санау. 2) Кяфер дип атау, кяфер ясау. *Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен күреп актык сүзем.* (Г. Тук.) — *м. II. рел.* 1) Обличение в ереси, в неверии в аллаха. 2) Превращение в неверующего.

**Тәкшиф** تكشيف *м. II.* Ачу, яшеренлектән чыгару, фаш итү, ачык итү. — *м. II.* Раскрытие, разоблачение, выявление.

**Тәкъбил** تقبيل *м. II.* Үбү; үпмәк. *Һәркайсы килеп Шаһзадәне тәкъбил иттеләр.* (К. Нас.) — *м. II.* Целование; поцелуй.

**Тәкъбих** تقبيح *м. II.* 1) Начар (кабахәт) санау. 2) Кабахәт итү. 3) Сүгү, кабахәт сүзләр әйтү. — *м. II.* от гл. قبح (каббәхә)—1) Делать безобразным. 2) Считать безобразным. 3) Ругать, оскорблять.

**Тәкъва*** تقوى *ис.* Дин кушканны гына эшләү, диндар булу. *„Гөлҗәмал түткәй, дигән, син булма аңкау, бул уяу! Зөлҗәлаләңнән сора төнлә торып тәкъва кияү.* (Ш. Баб.) — *сущ.* Благочестие, богобоязненность, религиозность.

**Тәкъвим** تقويم *м. II.* 1) Турылату, төзәйтү. 2) Географик координатларны, шулай ук йолдызларның хәрәкәт юлларын күрсәтә торган таблица. — *м. II.* 1) Поправка, исправление. 2) Таблица, показывающая географические координаты, а также пути движения небесных тел.

**Тәкъвис** تقويس *м. II.* Бөгү, ук җәясе кебек итү. — *м. II.* Сгибание.

**Тәкъвия** تقويه *м. II.* 1) Ныгыту, куәтләндерү. 2) Яклап куәтләү. — *м. II.* 1) Укрепление, усиление. 2) Поддержка, помощь.

**Тәкъвият** تقويت *кара*: тәкъвия. — *см.* Тәкъвия.

**Тәкъдим*** تقديم *м. II.* 1) Берәүнең алдына кую, сону. 2) Мәсьәлә кую. 3) Берәүне икенче бер кеше алдына китереп таныштыру, — *м. II.* 1) Предложение 2) Выдвижение (напр., вопроса). 3) Представление.

**Тәкъдир*** تقدير *м. II.* 1) Язмыш. *Ары барма, жаный, кил бире. Барча эшләр — ходай тәкъдире* (Жыр). 2) Берәүнең эшләгән эшен тану, бәя бирү. *Бездә мөхәррирләрнең хезмәте тәкъдир ителмәгәне һәркайсыбызга мәгълүм.* (Г. Газиз). 3) Очрак, ихтимал. *Бу тәкъдирдә мәсәлдәге миннән морад нәфестер.* (К. Нас.) 4) Бәя бирү, бәя билгеләү. *Нәрсәгә нәрех тәкъдир итүче улдыр.* (К. Нас.) — *м. II.* 1) Судьба (рок), предопределение. 2) Оценка. 3) Случай. 4) Установить цену.

**Тәкъдири** تقديرى *с.* Тәкъдир(гә бәйләнешле), тәкъдир(гә караган). — *прил.* от тәкъдир.

**Тәкъдирән** تقديرًا *р.* Танып, бәя бирәрәк, кадерен белеп. — *н.* Признавая, оценивая.

**Тәкъдис** تقديس *м. II.* 1) Мөкатдәс итү. 2) Изге дип ышану. — *м. II.* 1) Освящение, канонизация. 2) Посвящение. 3) Почитание.

**Тәкъйид** تقييد *м. II.* 1) Чикләү. 2) Беркетү. 3) Ныгыту. — *м. II.* 1) Ограничение. 2) Записывание, регистрирование. 3) Упрочение.

**Тәкълиб** تقليب *м. II.* 1) Эчен тышына әйләндерү, астын-өскә әйләндерү. 2) Әйбернең калыбын (формасын) үзгәртү. — *м. II.* 1) от гл. قلب (калләбә) — вертеть, ворошить, ворочать. 2) Изменение формы.

**Тәкълид** تقليد *м. II.* 1) Ияртү, башкалар эшләгәнне эшләү. *Дөньяда һәрнәрсә тәкълиддән гыйбарәттер дидем, хәтта тәкълид без „габед“ләргә гыйбадәттер, дидем.* (Ш. Баб.) 2) Охшатып эшләү. 3) Гореф-гадәт, традиция. — *м. II.* 1) Подражание. 2) Имитация, подделка, фабрикация. 3) Обычай; традиция.

**Тәкълиди** تقليدى *с.* Ияргән, ияртелгән, иярүгә бәйле. — *прил.* Традиционный, обычный.

**Тәкълидән** تقليدًا *р.* Охшатып, ияреп. *Искеләргә тәкълидән исмен „Китабеннас“ куеп.* (Ш. Баб.) — *н.* Как обычно, традиционно; подражая.

**Тәкълил** تقليل *м. II.* Азайту, киметү. — *м. II.* Уменьшение.

**Тәкъриб** تقريب *м. II.* Якынлаштыру, янәшәләштерү. — *м. II.* Приближение, сближение.

**Тәкърибн** تقريبى *с.* Якынча гына (чамалап кына) әйтелгән, алынган. — *прил.* Приблизительный.

**Тәкърибән** تقريبا *р.* Чамалап әйткәндә, якынча алганда, якынча. — *н.* Приблизительно.

**Тәкъриз I** تقريض *м. II.* 1) Язылган әсәр һәм хезмәткә мактап бәя бирү. 2) Китап азагында библиография. — *м. II.* 1) Похвальная рецензия, отзыв о книге. 2) Библиография (в конце книги).

**Тәкъриз II** تقريظ *кара:* тәкъриз I. — *см.* Тәкъриз I.

**Тәкърир** تقرير *м. II.* 1) Сөйләү, аңлатып сөйләү. *Залимә коллык фәкать тәкъриреңез, тәхриреңез.* (Г. Тук). 2) Урнаштыру, бер урында тора торган итү. — *м. II.* 1) Доклад; объяснение. 2) Определение, установление (места и т. п.)

**Тәкъсим** تقسيم *м. II.* 1) Бүлү, кисәкләргә аеру. 2) Агым суның тармаклану, бүленү урыны. 3) *мат.* Бүлү гамәле. — *м. II.* 1) Деление, разделение, распределение, раздел. 2) Дельта реки. 3) *мат.* Деление.

**Тәкъсыйр** تقصير *м. II.* 1) Кыскарту. *„Нур"да тәнвиренә тәкъсыйр итмәсен иде һәр заман.* (Г. Тук.) 2) Җиренә житкереп эшләмәү, игътибарсыз эшләү. 3) Гаеп. 4) Руханиларны олылап эндәшү. *Яхшы, тәкъсыйр, дип шәкерт юлына китмәкче булды* (Г. Газиз). — *м. II.* 1) Сокращение. 2) Упущение, небрежное выполнение. 3) Вина. 4) Вежливое обращение к духовным лицам.

**Тәкътир** تقتير *м. II.* 1) Үтә сакчыллыктан саранлану, чамадан тыш кысып тоту (акчаны, әйберне). 2) Фәкыйрьлек. — *м. II.* 1) Скопидомство, чрезмерная экономия, скупость. 2) Бедность, скудность.

**Тәкътыйг** تقطيع *м. II.* Кисәкләргә бүлү, бүлгәләү. — *м. II.* Разрезание, деление на части.

**Тәкътыйр** تقطير *м. II.* Тамчылап агызу, тамызу, кайнату юлы белән кудыру. — *м. II.* Перегонка, дистиллирование.

**Тәкъфил** تقفيل *м. II.* Йозаклау, йозаклап бикләү. — *м. II.* Запирание на замок.

**Тәкъфия** تقفيه *м. II.* Рифмалау, рифмалаштыру. — *м. II.* Рифмование.

**Тәкъшир** تقشير *м. II.* 1) Кабыгын төшерү. 2) Кабыгын әрчү. — *м. II.* 1) Шелушение (риса). 2) Очищение, снятие кожуры (с фруктов).

**Тәкый** تقى *с.* 1) Диндар. 2) Бозыклыктан сакланучы. — *прил.* 1) Богобоязненный; религиозный. 2) Праведный.

**Тәкябер** تكابر *м. VI.* Горурлык; масаю; тәкәбберлек, мин-минлек. — *м. VI.* Гордость, высокомерие, тщеславие.

**Тәкязеб** تكاذب *м. VI.* Бер-беренә ялган сөйләү, үзара ялганлашу. — *м. VI.* Взаимный обман.

**Тәкялиф** تكاليف Тәклиф-нең *к.* — *мн.* от тәклиф.

**Тәкямел** تكامل *м. VI.* 1) Житешү. 2) Тулылану, тәгәлләнү. *Куй, табигать хөкмен итсен! Шул тәкямел: шунда ямь!* (Дәрд.) 3) Үсеш. — *м. VI.* 1) Достижение полноты, совершенство. 2) Полнота, совершенство. 3) Развитие, рост.

**Тәкясел** تكاسل *м. VI.* Ялкаулык, иренчәклек. — *м. VI.* Леность, нерадение.

**Тәкясеф** تكاثف *м. VI.* 1) Куеру, куелану. 2) Юанаю, тупаслану. — *м. VI.* 1) Сгущение, уплотнение. 2) Огрубение, утолщение.

**Тәкясер** تكاثر *м. VI.* Үрчү; күбәю, арту́. — *м. VI.* Размножение; увеличение, количественный рост.

**Тәкятеб** تكاتب *м. VI.* Бер-беренә хат язышу. — *м. VI.* Переписка, корреспонденция.

**Тәкәббер*** تكبر *м. V.* Үз-үзен эре тоту, олылану, үзен зурга санау, һавалану, борын күтәрү. *Мин дә әрлим кәрлә көйгә бик тәкәбберләнмә дип.* (Ш. Баб.) — *м. V.* Высокомерие, наглость; заносчивость.

**Тәкәддер** تكدر *м. V.* Көенү, кайгыру, гамьләнү. — *м. V.* Расстройство, печаль, огорчение, досада.

**Тәкәллем** تكلم *м. V.* Сөйләү. *Моның сөкүте миңа тәкәллеменнән каты килде, дип тәәссеф итәр.* (К. Нас.) — *м. V.* Речь, говорение.

**Тәкәллеф*** تكلف *м. V.* Көнкүрештә, эштә табигыйлектән үтеп, күрсәтү өчен көчләнеп эшләү, ясалмалык, кылану, тартыну. *Ул бер дә тәкәллефсез генә үзенең хаж җөббәсе белән вокзал идәненә килеп утырды.* (М. Гал.) — *м. V.* Деланность, искусственность, натянутость, стеснение, церемония.

**Тәкәллефат** تكلفات Тәкәллеф-нең *к.* *Һәрмез гаҗәпләнеп: „кайда хәлифәнең хезмәтчеләре, кайда ишекчеләре?" дип сорады. „Хәлифәнең алай тәкәллефаты юктыр" дип җавап бирделәр.* (К. Нас.) — *мн.* от тәкәллеф.

**Тәкәммел** تكمل *м. V.* Камилләшү; үсеп җитешү. — *м. V.* Усовершенствование; созревание.

**Тәкәррер** تكرر *м. V.* Кат-кат булу, кабатлану. — *м. V.* Повторяемость; повторение.

**Тәкәссер I** تكثر *м. V.* 1) Күбәю, арту, ишәю. 2) Күп сөйләү, артык сөйләү. — *м. V.* 1) Увеличение. 2) Излишняя болтливость, разговорчивость.

**Тәкәссер II** تكسر *м. V.* Ваклану, сыну. — *м. V.* Дробление, мельчание, измельчание; поломка.

**Тәкәффел** تكفل *м. V.* Кәфил булу, бирәү өчен җаваплылыкны өскә алу. — *м. V.* Ручательство, поручительство.

**Тәкәүвен** تكون *м. V.* Бар булу, барлыкка килү, юктан бар булу. — *м. V.* Возникновение.

**Тәлбис** تلبيس *м. II.* 1) Киендерү. 2) Гаебен яшереп буташтыру, бутау. 3) Хәйлә белән алдау. *Бу турыда тәлбис кылучыларга илтифат итмәй, вакытында кайгыртып калырга тиеш иде.* (Ш. ж.) — *м. II.* 1) Одевание. 2) Введение в заблуждение с целью скрыть свою виновность. 3) Обман, надувательство.

**Тәлвин** تلوين *м. II.* Төс бирү, төс кертү, буяу. — *м. II.* Крашение, окрашивание, раскрашивание.

**Тәлвис** تلويث *м. II.* Пычрату, шакшыландыру әшәкеләндерү. *Бер җирдә кунак булып калмыш идем, төнлә хезмәтханәне таба алмагач, нагыйлаҗ такыяма тәлвис кыйлдым, — димеш.* (К. Нас.) — *м. II.* Загрязнение, пачкание.

**Тәлгыйн** تلعين *м. II.* Ләгънәт әйтү, каргау. — *м. II.* Проклятие, проклинание, заклинание.

**Тәлех** تلخ *ф. с.* Ачы. — *п. прил.* 1) Горький. 2) Горько.

**Тәлйин** تليين *м. II.* Йомшату, йомшаклык бирү. — *м. II.* Смягчение, размягчение.

**Тәлкыйб** تلقيب *м. II.* Кушамат кушу, кушамат тагу. — *м. II.* от гл. لقب (ләккабә) — давать прозвище, титуловать.

**Тәлкыйн** تلقين *м. II.* 1) Төшендереп сөйләү, аңлату. 2) Инандыру. 3) *Дини* Үлекне күмеп, озатучылар киткәч, руханиның үлекне исенә төшерү өчен иман укуы. 4) Әйтеп тору. — *м. II.* 1) Разъяснение; наставление, инструктирование. 2) Внушение. 3) *рел.* Чтение молитвы духовным лицом после погребения умершего. 4) Подсказывание, суфлирование.

**Тәлкыйх** تلقيح *м. II.* Серкәләндерү, аталандыру. *Ир җенес чәчәк тузаны хатын җенесе чәчәккә күчеп тәлкыйх ителенәдер.* (Г. Рәф.) — *м. II.* Опыление, оплодотворение, осеменение.

**Тәлтыйф** تلطيف *м. II.* 1) Хәтер (күңел) табу; яхшы, йомшак мөгамәлә. 2) Дәрәҗә яки орден белән бүләкләп — *м. II.* 1) Задабривание, ласковое обращение. 2) Присвоение звания

хөрмәт итү. *Хезмәтләре өчен „3 нче һәм 2 нче Анна“ ордены илә тәлтыйф иделмештер.* (Ш. ж.) — или награждение орденом, оказание почестей.

**Тәлхис** تلخيص *м. II.* Сүзне кыскарту, төп кирәклесен генә калдыру, озын язылганны кыскарту. — *м. II.* Краткое, сокращенное изложение, резюмирование; аннотация.

**Тәлягыб** تلاعب *м. VI.* Уйнашу, шаяру, мәсхәрәләшү, алдашу; уен. — *м. VI.* Шутка, насмешка, обман; игра, забава.

**Тәлякый** تلاقى *м. VI.* Очрашу, юлыгышу. — *м. VI.* Встреча.

**Тәлямиз** تلاميذ Тилмиз-нең *к.* — *мн.* от тилмиз.

**Тәлясим** طلاسم Тылсым-ның *к.* — *мн.* от тылсым.

**Тәляфи** تلافى *м. VI.* Эшләнгән (яки булган) кимчелекне төзәтү. — *м. VI.* Исправление, улаживание.

**Тәляхык** تلاحق *м. VI.* Бергә кушылу, тоташу, соңыннан килеп кушылу. — *м. VI.* Соединение, сближение, присоединение.

**Тәляш** تلاش *ис.* Сабырсызланып, ашкыну, борчылу. — *сущ.* Хлопоты; беспокойство, торопливость, спешка.

**Тәләббес** تلبس *м. V.* Киенү, өскә кием кию. — *м. V.* Одевание.

**Тәләззез** تلذذ *м. V.* Тәм табу, ләззәтләнү. *Иланһи бер тәләззездән беренче кәррә тамган яшь.* (Г. Тук.) — *м. V.* Удовольствие, наслаждение.

**Тәләкъкый** تلقى *м. V.* 1) Юлыгу, юлыгып алу, кабул итеп алу. 2) Алу, өскә алу. *Гомәр Хәйям хакында белдекләремне язмая бер вазифа улмак үзрә тәләкъкый идәрәк, түбәндәге юлларны караламая җәсарәт иттем.* (Ш. ж.) — *м. V.* 1) Встреча; принятие, получение, восприятие. 2) Взятие на себя (обязательств).

**Тәләттыф** تلطف *м. V.* Йомшак (яхшы) мөгамәлә итү, ягымлылык күрсәтү. *Сөальдә тәләттыф, ягъни кешедән хаҗәтеңне сорый белеп сорамак — сәнаигъ бәдигадәндер.* (К. Нас.) — *м. V.* Обходительность, благосклонность, ласка, любезность.

**Тәләф** تلف *ис.* 1) Әрәм-шәрәм итү, бетерү, бозу. *„Мин арслан!“ — ди, синең малны тәләф иткәндә ул...* (Г. Тук.) 2) Һәлак итү, үтерү. — *сущ.* 1) Ущерб, потеря, повреждение, порча. 2) Гибель, смерть.

**Тәләффыз** تلفظ *м. V.* Сүзне әйтү, сөйләү, әйтелеш. — *м. V.* Произношение.

**Тәләүвен** تلون *м. V.* Төрле төскә керү, төс үзгәртү. — *м. V.* Изменение цвета

**Тәләһһеб** تلهب *м. V.* Ялкынлану, ялкын күтәрелү. — *м. V.* Горение, воспламенение.

**Тәләһһеф** تلهف *м. V.* 1) Кайгыру, хәсрәтләнү. 2) Аһ-ваһ итү, аһ ору. 3) Борчылу. — *м. V.* 1) Вздыхание (по чем-либо, по ком-либо). 2) Скорбь. 3) Тревога, волнение.

**Тәмам*** تمام *ис.* **1.** Тулы, кимчелексез. **2.** Бөтенләй бетү, азагына ирешү. — *сущ.* **1.** Полный, совершенный. **2.** Окончание, завершение, конец.

**Тәмамиять** تماميت *ис.* Беткәнлек; бөтенлек, тулылык. — *сущ.* Полнота; законченность, завершённость.

**Тәмамән** تماما *р.* Бөтенләй, тулысынча. *Ләим кешенең хаҗәтен тәмамән әда кыйлсаң да, сиңа явызлыгын тидерер.* (К. Нас.) — *н.* Полностью, сполна.

**Тәмарыз** تمارض *м. VI.* Үзен авыру итеп күрсәтү. — *м. VI.* Симуляция болезни.

**Тәмасел** تماثل *м. VI.* Охшашлык, бертөслелек, тиңдәшлек. — *м. VI.* Сходство, подобие.

**Тәмасил** تماثيل *ис.* Тимсаль-ның *к.* — *сущ. мн.* от тимсаль.

**Тәмаша*** تماشا *ф. ис.* 1) Тамаша, күренеш. 2) Карап йөрү, карау. — *п. сущ.* 1) Зрелище, представление, спектакль. 2) Разглядывание зрелища.

**Тәмашагир** تماشاگیر *ф. ис.* Карап, күңел ачып йөрүче. — *п. сущ.* Посещающий зрелищные места, зритель.

**Тәмашагяһ** تماشاگاه *ф. ис.* Карап, күңел ачып йөрү урыны. — *п. сущ.* Зрелищное место.

**Тәмдид** تمدید *м. II.* 1) Озынайту, киңәйтү. 2) Озакка сузу. — *м. II.* 1) Вытягивание, растягивание. 2) Удлинение (срока).

**Тәмдих** تمدیح *м. II.* Мактап телгә алу. — *м. II.* Расхваливание.

**Тәмиз** تمیز *ф. с.* Чиста, пакь, ару, пөхтә. *Булмәгә керү белән җаның эри, ничектер табигый матурлык, зәвык, тәмиз хис кыласың..* (Г. Ибр.) — *п. прил.* Чистый, опрятный, аккуратный.

**Тәмйиз** تمییز *м. II.* Бер-берсеннән аеру, аерып белү, аралап алу. *Хәкаикъны идрakь итмәктән вә мәгъкулатны тәмйиз итмәктән гаҗиз булып...* (К. Нас.) — *м. II.* Выделение, предпочтение; различение.

**Тәмлик** تمليك *м. II.* 1) Бер нәрсәгә ия итү. 2) Власть бирү (берәүнең кулына). — *м. II.* 1) Передача в чью-либо собственность. 2) Облечение властью.

**Тәмлих** تمليح *м. II.* Тозлау. — *м. II.* Соление, засаливание.

**Тәмлия** تمليه *м. II.* Тулы итү, тутыру. — *м. II.* Наполнение.

**Тәммуз** تموز *ис.* Июль ае. *Ул кемсә сахрадагы сәрабтан тәммуздәге болыттан ялганчырак димәктер.* (К. Нас.) — *сущ.* Июль.

**Тәммә** تم *фиг.* Бетте, тәмам булды. — *гл.* Кончилось, закончилось.

**Тәммәт тәмам*** تمت تمام *ст.* Тәмам булды, бөтенләй бетте. — *сс.* Полностью (совсем) кончилось.

**Тәмрин** تمرين *м. II.* Күнектерү, күнегү. *Анда балаларны уйларга да сөйләргә, ә монда исә уйларга да язарга тәмрин мәкъсуддыр.* (Ә. Мөс.) — *м. II.* Упражнение, тренировка.

**Тәмсил** تمثيل *м. II.* 1) Охшату, чагыштыру. *Ничек дисәм дә аз тәмсилгезне.* (Г. Тук.) 2) Мисал итеп китерү. 3) Мәсәл. 4) Охшаштыру, үзедәй итеп ясау, йоту, ассимиляция. *Куманнар, Алтын Урданың иң күп әһалисын тәшкил итеп мангулларны тәмсил иттеләр* (Г. Газиз). — *м. II.* 1) Уподобление, сравнение; сходство. 2) Приведение в пример. 3) Басня. 4) Уподобление, ассимилирование.

**Тәмшия** تمشيه *м. II.* 1) Хәрәкәткә китерү. 2) Йөртү. — *м. II.* 1) Приведение в движение. 2) Двигание.

**Тәмәдден** تمدن *м. V.* Мәдәниятле булу, культуралы булу, культуралашу. — *м. V.* от гл. تمدن (тәмәддәнә) — цивилизоваться, становиться культурным.

**Тәмәддех** تمدح *м. V.* Үз-үзен мактау, мактану. *Буй белән вә кыяфәт белән тәмәддех кыйлганнар хакында әйтелер.* (К. Нас.) — *м. V.* Похвальба, хвастовство, самовосхваление.

**Тәмәйегъ** تميع *м. V.* Эрү, сыегаю, сыек хәлгә күчү. — *м. V.* Плавление, превращение в жидкость.

**Тәмәйез** تميز *м. V.* Аерылу, аралану. — *м. V.* Обособление, различение.

**Тәмәккен** تمكن *м. V.* 1) Урнашу, җирләшү, урын алып тору; урын тоту. 2) Мөмкинлек алу. 3) Көч, куәт. — *м. V.* 1) Расположение, размещение; занятие места. 2) Получение возможности. 3) Сила, мощь.

**Тәмәллек** تملك *м. V.* Ия булу, хуҗа булу, кулга кертү. — *м. V.* Владение, обладание, овладевание; господство; приобретение (чего-либо).

**Тәмәллык** تملق *м. V.* Ялыну, ялагайлану, ялынып йөрү. *Безәр Җәмһәр әйтте: „Карга кебек иртә тордым, эт кебек тәммәллыклы булдым, мәче кебек тәзәррыглы булдым, хинзир кебек хирыс булдым да гыйлем хасыйл иттем" димеш.* (К. Нас.) — *м. V.* Лесть, подобострастие, низкопоклонство.

**Тәмәнна** تمنا *м. V.* 1) Хәрәкәт белән сәлам бирү (мәсәлән, баш ию, честь бирү). 2) Үтенү, сорау, ялвару. — *м. V.* 1) Приветствие (поклоном, жестом). 2) Просьба, мольба.

**Тәмәнни** تمنى *м. V.* Теләү, өмет итү, үтенү, ялвару. *Кайчылар белән туралсачы дип тәмәнни кылыр имеш.* (К. Нас.) — *м. V.* Желание, выражение надежды; мольба.

**Тәмәр** تمر *ис.* Киптерелгән хөрмә җимеше. — *сущ. соб.* Сухие финики.

**Тәмәркәз** تمركز *ис.* Үзәкләшү, туплану, бер ноктага җыелу. *Шуның тирәсендә әйләнергә, шуңа тәмәркәз итәргә кирәк.* (Җ. Вәл.) — *сущ.* Централизация, концентрация, сосредоточение.

**Тәмәрред** تمرد *м. V.* Үзсүзлелек итү, буйсынмау, тыңламау, каршылык итү, каршы тору. *Изгелек кадрен белмәгәннәргә икрам кыйлсаң, тәмәрред кыйлырлар.* (К. Нас.) — *м. V.* Неповиновение, ослушание, упрямство; сопротивление.

**Тәмәррен** تمرن *м. V.* Гадәтләнү, гадәт итү. *Мөганид күркәм җиргә күзен салмай, мәкъбулатка тәмәррен гадәменнән.* (Ак.) — *м. V.* Привычка, навык.

**Тәмәссек** تمسك *м. V.* 1) Бурыч (әҗәт) алганга бирелгән расписка. 2) Бер нәрсәгә ябышу, тотыну. *Мәгълүм ула ки халыкның тәмәссек кылган дәлилләре* ... (К. Нас.) — *м. V.* 1) Вексель, письменное денежное обязательство, расписка. 2) от гл. تمسك (тәмәссәкә) — держаться, цепляться за что-либо.

**Тәмәссел** تمثل *м. V.* 1) Мәсәл (яки мәкаль) куллану. 2) Икенче бер сурәттә булып күренү, күренеш алмаштыру, билгеле бер сурәткә керү, ияру. — *м. V.* 1) Применение басни или пословицы. 2) Сходство, подобие, уподобление, подражание; перевоплощение.

**Тәмәттегат** تمتعات Тәмәттегъ-нын *к.* *Тәмәттегат вә ләззәт дөньявия ар-* — *мн.* от тәмәттегъ.

*тына төшеп, бушка мал җимагача алышма.* (К. Нас.)

**Тәмәттегъ** تمتع *ис.* 1) Файдаланырга хокук алу, патент. 2) Файдалану, үзенә файда итү. 3) Файда. *Канәгать кылып артык тәмәттегъ вә тәнәгъгым кәсебе өчен мәшәкатьне куйса...* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Право пользования, лицензия, патент. 2) Пользование, использование. 3) Польза, удовлетворение.

**Тәмәүвел** تمول *м. V.* Баю, маллы булу. *Тиҗарәт илә аз мөддәттә тәмәүвел итте.* (К. Нас.) — *м. V.* Обогащение.

**Тәмәүвеҗ** تموج *м. V.* Дулкынлану. *Сәраб су кебек тәмәүвеҗ итмәк белән суга биңзәр бер мәүһүм нәрсәдер.* (К. Нас.) — *м. V.* Волнение.

**Тәмҗид** تمجيد *м. II.* Олылау, хөрмәтләү, зурлау. *Бонларның гыйбадәтләре, шәйтан исеменә тәэсис иделмеш гыйбадәтханәгә җыелып, аны мадех итмәк, тәкъдис вә тәмҗид әйләмәктән гыйбарәттер.* (Ш. ж.) — *м. II.* Прославление, восхваление.

**Тән*** تن *ф. ис.* Тән, гәүдә. — *п. сущ.* Тело, корпус.

**Тәнавел** تناول *м. VI.* Авыз итү, татып карау, тату. *Бәс ул җәзирәнең ләззәтле җимешләреннән тәнавел кылып...* (К. Нас.) — *м. VI.* Проба, принятие (пищи, лекарства).

**Тәнавем** تناوم *м. VI.* Йоклаган булу, йоклаганга салышу. — *м. VI.* от гл. تناوم (тәнавәмә) — притворяться спящим.

**Тәназыг** تنازع *м. VI.* Бер-бере белән низаглашу, талашу, тартышу. — *м. VI.* Спор; ссора, скандал.

**Тәназыг бәка** تنازع بقا *ст.* Яшәү өчен көрәш. *Тәназыг бәка низамнарына күрә мәгыйшәт мөхарәбәләрендә мәгълүб улып, матди вә мәгънәви куәтләрене гаиб итәчәкләр.* (Ш. ж.) — *сс.* Борьба за существование.

**Тәнакех** تناكح *м. VI.* Никяхлану, өйләнешү. — *м. VI.* Женитьба, бракосочетание.

**Тәнакыз** تناقض *м. VI.* 1) Каршылык, бер-беренә каршы булу. *Бу таифә кәмаль җәһәтләре белән тәнакыз итүчеләрдер.* (К. Нас.) 2) Сүзләрнең бер-берен бозуы, ике сүзнең бер-беренә кире мәгънәдә булуы. — *м. VI.* 1) Противоречие, несогласие. 2) Контраст. 3) Слова с противоположным значением.

**Тәнакыс** تناقص *м. VI.* Кимү, азая бару. — *м. VI.* Постепенное уменьшение, убывание.

**Тәнакыш** تناقش *м. VI.* Бәхәс, диспут. *Тәнакыш юк мисалда, и мохатәб!* (Г. Тук.) — *м. VI.* Спор, обсуждение, диспут.

**Тәнасеб** تناسب *м. VI.* 1) Бер-беренә охшашу, туры килү. 2) Симметрия, пропорция. — *м. VI.* 1) Сходство, соответствие. 2) Симметрия, пропорция, равномерность.

**Тәнасел** تناسل *м. VI.* Нәсел арту, нәсел таралу, үрчү. — *м. VI.* Размножение, произведение потомства.

**Тәнасер** تناثر *м. VI.* Чәчелү, сибелү, таралу. — *м. VI.* от гл. تناثر (тәнасәрә) — рассыпаться, быть рассеянным, разбросанным (о семенах).

**Тәнасыр** تناصر *м. VI.* Бер-беренә ярдәм итү, яклау. — *м. VI.* Взаимопомощь, защита.

**Тәнафер** تنافر *м. VI.* 1) Каршылык. 2) Яратышмау, бер-береннән нәфрәтләнү, җирәнешү. — *м. VI.* 1) Разногласие, расхождение, взаимные противоречия. 2) Взаимное отвращение.

**Тәнафи** تنافى *м. VI.* Бер-беренә каршы булу. — *м. VI.* Противоречие, взаимное несогласие.

**Тәнбиһ** تنبه *м. II.* 1) Уяту. 2) Кисәтү, искәртү, зиһененә салу. *Бу мәсәл нәфес явызлыгыннан сакланмага тәнбиһдер.* (К. Нас.) — *м. II.* 1) Пробуждение. 2) Напоминание; предупреждение.

**Тәнбиһән** تنبهاً *р.* Кисәтеп, искәртеп. *Мөнәсәбәтсез сөаль кылганда, мөнәсәбәтсез булмакына тәнбиһән, секүт кылыныр.* (К. Нас.) — *н.* Предупредительно, предупреждая.

**Тәнбәл** تنبل *ф. с.* Ялкау; иренчәк; үшән. — *п. прил.* Ленивый; вялый.

**Тәнвигъ** تنويع *м. II.* Төрле-төрле итү, төрлеләндерү. — *м. II.* Делание разнообразным, разнородным.

**Тәнвин** تنوين *ис. грам.* Гарәп сүзләрендә соңгы аваздан соң ән, ин, өн иҗекләре кушып укырга тиешлекне күрсәтә торган диакритик билгеләр. — *сущ. грам.* Танвин — диактрические знаки.

**Тәнвим** تنويم *м. II.* Йоклату. — *м. II.* Укладывание спать, усыпление.

**Тәнвир** تنوير *м. II.* Яктырту; нурландыру, ялтырату. *„Нур“ да тәнвирендә тәкъсыйр итмәсен иде һәр заман.* (Г. Тук.) — *м. II.* 1) Освещение. 2) Излучение, облучение.

**Тәнг** تنگ *ф. с.* 1) Тар (киң түгел), кысан; җинел, зәгыйфь, нечкә, сирәк. 2) Изелгән, хәсрәтләнгән.

*п. прил.* 1) Узкий, тесный, слабый; редкий, недостаточный. 2) Угнетённый, удручённый.

**Тәнгдил** — тар күңел, тар күңелле; рухы төшкән, хәсрәтле.

Огорчённый, павший духом.

**Тәнгыйм** تنعيم *м. II.* 1) Нигъмәт бирү, нигъмәтләндерү, ашату. 2) Иркәләү, назлау; назлылыкка өйрәтү. 3) Төю, ваклап бетерү.

*м. II.* 1) Пропитание, кормление. 2) от гл. نعم (нәгъгәмә) —нежить, холить. 3) Дробление, измельчание.

**Тәндәрест** تندرست *ф. с.* Таза, сәламәт, сау (кеше).

*п. прил.* Здоровый, крепкий (о человеке).

**Тәнзил** تنزيل *м. II.* 1) Түбәнгә төшерү, индерү. 2) Ташлама, скидка.

*м. II.* 1) Снижение, спускание; понижение. 2) Вычет, скидка.

**Тәнзиә** تنزيه *м. II.* 1) Аклау, гаепсез дип тану. 2) Үзен начарлыктан ерак тоту.

*м. II.* 1) Оправдание. 2) Нравственная чистота, непорочность; порядочность.

**Тәнзыйм** تنظيم *м. II.* Тәртипкә салу, тәртипләндерү.

*м. II.* Приведение в порядок, упорядочение, устройство, организация.

**Тәнзыйф** تنضيف *м. II.* Тазарту, аруландыру, пакьләү.

*м. II.* Очищение, чистка.

**Тәнких** تنكيح *м. II.* Никяхлау.

*м. II.* Бракосочетание, женитьба.

**Тәнкыйл** تنقيل *м. II.* Күчерү, бер урыннан икенче урынга күчерү. *Китабәт әйләюбән тәнкыйл идеп.* (Ут. Им.)

*м. II.* Перенесение с места на место, передача, перемещение, перенос.

**Тәнкыйд*** تنقيد *ис.* Тәнкыйть, кимчелекләрне күрсәтү. *Бәгъзы хаска гам булыбрак төшмәгән тәнкыйдләрем.* (Ш. Баб.)

*сущ.* Критика.

**Тәнкыйди** تنقيدى *с.* Критик.

*прил.* Критический.

**Тәнкыйдән** تنقيداً *р.* Тәнкыйть йөзеннән. *Яңгыларны тәнкыйдән язмый чыдап булмас диеп.* (Ш. Баб.)

*н.* Критически, критикуя.

**Тәнкыйс** تنقيص *м. II.* 1) Киметү, азайту. 2) Түбәнәйтү, кимсетү, ким күрү. *Зали инең шәрреннән сакласын кебек догалар адәмне тәнкыйс вә тәгъйибдер.* (К. Нас.)

*м. II.* 1) Уменьшение, сокращение. 2) Унижение, пренебрежительное отношение.

**Тәнкыйт** تنقيط *м. II.* 1) Хәрефкә нокта (төртке) кую. 2) Тыныш билгеләре куллану.

*м. II.* 1) Употребление точек (диакритических знаков). 2) Употребление знаков препинания.

**Тәнкыйх** تنقيح *м. II.* 1) Яңадан карау, төзәтү. 2) Киметү, кыскарту.

*м. II.* 1) Пересмотр, исправление. 2) Сокращение.

**Тәнмия** تنميه *м. II.* Үстерү, күтәрү, арттыру. *Рәсем дәресендә балаларны ялыктырмыйча, тәмле бер сурәттә күзләрне дә кәсәби куәтендә тәнмия иттермәк.* (Ш. ж.)

*м. II.* Развитие.

**Тәннур** تنور *ф. ис.* Мич, учак (икмәк пешерү өчен).

*п. сущ.* Печь для выпечки хлебов; очаг.

**Тәнсиб** تنسيب *м. II.* Яраклы күрү, муафыйк күрү. *Намөнасиб шәйләре тәнсиб идәнләр сезсеңез.* (Г. Тук.)

*м. II.* Соответствие с чем-либо, пригодность.

**Тәнсыйк** تنسيق *м. II.* 1) Тәртипкә салу, билгеле бер тәртипкә кую. *Гамәл вә тәҗрибәнең кавагыйд гыйльмияне тәртип вә тәнсыйк һәрхәлдә әлек улулары лязимдер.* (Ш. ж.) 2) Штат кыскарту.

*м. II.* 1) Приведение в порядок, устройство, организация. 2) Сокращение (штатов).

**Тәнсыйр** تنصير *м. II. дини* 1) Чукындыру. 2) Христиан динен кабул иттерү.

*м. II* 1) *рел.* Крещение. 2) Обращение в христианство.

**Тәнсыйф** تنصيف *м. II.* Урталай бүлү.

*м. II.* Деление на две равные части.

**Тәнфиз** تنفيذ *м. II.* Өстенә йөкләнгән вазифаны үтәү. *Я бер шаһ хезмәтен тәнфиз итәргә.* (Һ. Сал.)

*м. II.* Исполнение своих обязанностей.

**Тәнфир** تنفير *м. II.* Җирәндерү, чиркандыру, нәфрәтләндерү.

*м. II.* Вызвать отвращение, антипатию.

**Тәншыйт** تنشيط *м. II.* 1) Сөендерү, куандыру, кәефләндерү, күңелен күтәрү. 2) Рухландыру.

*м. II.* 1) Приведение в хорошее расположение духа; оживление, ободрение, развлечение. 2) Поощрение, побуждение.

**Тәнәббет** تنبت *м. V.* Тишелеп чыгу, шыту.

*м. V.* Произрастание (растения).

**Тәнәббеһ** تنبه *м. V.* 1) Уяну. 2) Белемсезлектән котылу, зиһене ачылу.

*м. V.* 1) Пробуждение ото сна. 2) Прояснение, просветление мысли.

**Тәнәгъгым I** تنغم *м. V.* Җырлау, көйләү.

*м. V.* Пение, напев.

**Тәнәгъгым II** تنعم *м. V.* Нигъмәтләнү, нигъмәт эчендә яшәү, нигъмәттә булу. — *м. V.* Благоденствие, наслаждение, пребывание в довольстве.

**Тәнәззел** تنزل *м. V.* 1) Түбән төшү, түбәнәю. *Әмма татар газеталары укырга тәнәззел итми иде* (Г. Газиз). 2) Түбәнчелек итү, кече күңеллелек күрсәтү, үз-үзен кимсетү. *Юк! Кабул итмәс тәнәззелне боларга изге җан!* (З. Гыйф.) — *м. V.* 1) Схождение; снисхождение. 2) Самоунижение; преклонение.

**Тәнәззеһ** تنزه *м. V.* 1) Бозыклыктан саклану. 2) Күңел юату өчен йөрү, күңел ачу, күңел ачарга чыгу. *Шул паркка тәнәззеһгә чыгалар, шунда йөриләр икән.* (Г. Ибр.) — *м. V.* 1) Воздержание (от чего-либо). 2) Прогулка, гулянье.

**Тәнәззыф** تنظف *м. V.* Чиста булу, чисталык күрсәтү; арулану. — *м. V.* Чистота, опрятность.

**Тәнәссыр** تنصر *м. V.* 1) Христианнар динен кабул итү. 2) Чукыну. — *м. V.* 1) Принятие христианства. 2) Крещение.

**Тәнәффер** تنفر *м. V.* Нәфрәтләнү, җирәнү, чиркану. — *м. V.* Отвращение, омерзение.

**Тәнәффес*** تنفس *м. V.* 1) Сулау, тын алу. *Бакчачылар үләннәр, чәчәкләр арасында йөреп саф һава тәнәффес иттекләреннән сәламәт булалар.* (Г. Раф.) 2) Эшне (укуны) туктатып ял итү, хәл җыю. — *м. V.* 1) Дыхание. 2) Передышка, перерыв (во время занятий).

**Тәнәхнех** تنحنح *ис.* Тамак кыру, йөткерү. — *сущ.* Откашливание, прочищение горла.

**Тәнәүвыг** تنوع *м. V.* Төрле-төрле булу, төрлеләнү, төрлелек. — *м. V.* Разнородность, разнообразие.

**Тәнәүвем** تنوم *м. V.* 1) Йоклау, төш күрү. 2) Төшләнү. — *м. V.* 1) Сон, сновидение. 2) Ночные поллюции.

**Тәнәүвер** تنور *м. V.* Нурлану, яктыру, ялтырау. — *м. V.* Блеск, сияние.

**Тәнәҗҗес** تنجس *м. V.* Пычрану, нәҗесләнү. — *м. V.* Испачканность, загрязнённость.

**Тәнҗис** تنجيس *м. II.* Пычрату, нәҗесләү. *Шул сәбәптән итә алмыйдыр талак, гомерене тәнҗис итә, итә һәляк.* (Г. Тук.) — *м. II.* Пачкание, загрязнение.

**Тәнһа** تنها *ф. ис.* 1) Ялгыз, бер генә, бер үзе. 2) Ялгыз буларак. 3) Буш (урын, җир). *Булынып мәскәндә бер тәнһа мәкяни.* (Дәрд.) — *п. сущ.* 1) Один, одинокий, единственный. 2) Одиноко, в одиночестве. 3) Свободное (место).

**Тәравих*** تراويح *ис. к.* Уразада кич белән укыла торган намаз. *Дүртәр, бишәр сәгать дәвам иткән хәтем вә тәравихлар да аңа бу газапны китерми калмыйлар.* (Г. Ибр.) — *сущ. мн.* Дополнительная молитва у мусульман во время поста, совершаемая вечером.

**Тәрадеф** ترادف *м. VI.* 1) Бер-бере артыннан китү, бер эздән китү. 2) *грам.* Сүзләрнең бер мәгънәдә килүе. — *м. VI.* 1) Последовательность; следование друг за другом. 2) *грам.* Однозначность слов, синонимика.

**Тәраз** تراز *ф. ис.* Тигезләмә, үлчәгеч (уровень). *Остаза ит хезмәт гомер тәраз.* (Ут. Им.) — *п. сущ.* Уровень.

**Тәраз аби** — нивелир. — Нивелир.

**Тәраз һаваи** — ватерпас. — Ватерпас.

**Тәразу** ترازو *ф. ис.* Үлчәү, бизмән. — *п. сущ.* Весы, безмен.

**Тәразый** تراضى *м. VI.* Үзара ризалашу. — *м. VI.* Взаимное удовлетворение.

**Тәракеб** تراكب *м. VI.* 1) Берсе өстендә берсе булу, катлаулы булу. 2) Катлаулану. — *м. VI.* 1) от гл. تراكب (тәракәбә) — быть нагромождённым друг на друга. 2) Усложнение.

**Тәракем** تراكم *м. VI.* Берегү, туплану, җыелу, төркемләнү. — *м. VI.* Скопление, нагромождение, накопление, сгущение, концентрация.

**Тәракиб** تراكيب Тәркиб-нең *к.* — *мн.* от тәркиб.

**Тәранә** ترانه *ф. ис.* Моң, көй, аһәң. — *п. сущ.* Мотив, мелодия, напев, интонация.

**Тәрассыд** ترصد *м. V.* Көтеп тору, дикъкать белән карау (күзәтү); сагалап тору. — *м. V.* Наблюдение, высматривание, слежка.

**Тәрасел** تراسل *м. VI.* Хәбәрләшү, язышып тору. — *м. VI.* Переписка, обмен посланиями.

**Тәрафегъ** ترافع *м. VI.* Ике якның бер-беренә карата дәгъвасе; судка мөрәҗәгать итүе. — *м. VI.* 1) Тяжба, встречный иск. 2) Обращение в суд.

**Тәрафык** ترافق *м. VI.* Бер-беренә иптәш (юлдаш) булу. — *м. VI.* Сопутствие; сопровождение.

**Тәрахи** تراخى *м. VI.* 1) Йомшаклык күрсәтү. 2) Ашыкмау. 3) Ялкаулык. 4) Көчсезләнү, өшәнү. — *м. VI.* 1) Слабость; расслабленность, изнеможение. 2) Неторопливость. 3) Лень. 4) Усталость; бессилие, вялость.

**Тәраш** تراش *кара*: тараш. — *см.* Тараш.

**Тәраҗегъ** تراجع *м. VI.* Кире китү, кире кайту, чигенү. — *м. VI.* Возвращение; отступление, отход.

**Тәраҗим** تراجم *ис.* Тәрҗемә-нең *к.* — *сущ. мн.* от тәрҗемә.

**Тәрбигъ** تربيع *м. II.* 1) *мат.* Дүрт кат итү, дүрт өлеш итү; дүрт почмаклы итү. 2) Бер атналык, яки өч атналык ай, чирек ай. — *м. II.* 1) *мат.* Увеличение в четыре раза; возведение в квадрат, умножение на четыре. 2) Недельная или трёхнедельная луна, четверть луны.

**Тәрбия*** تربيه *ис.* Карау, карап үстерү. — *сущ.* Воспитание, образование.

**Тәрвия** ترويه *ис. дини* Бәйрәм исеме. *Тәрвия көнендә профессор Мөслимовның 42 сәнә моннан мөкаддәм вафат булган хәзрәтне тергезәчәге белдерелгән иде.* (Ф. Әмир.) — *сущ.* Название религиозного праздника.

**Тәрвиҗ** ترويج *м. II.* 1) Тарату, алга җибәрү. *Бу — тәрвиҗе бәлягать һәм фәсахәт.* (Г. Тук.) 2) Уңышка, игътибарга ирешү. — *м. II.* 1) Распространение. 2) Достижение успеха.

**Тәргыйб** ترغيب *м. II.* Кызыктыру, кызыксындыру, кызыксын ырып өндәү. *Хәзергә мал сарыф кыйлмага тәргыйб мәкамендә әйтелер.* (К. Нас.) — *м. II.* Возбуждение желания, побуждение, соблазн.

**Тәрзил** ترذيل *м. II.* 1) Орышу, шелтәләү. 2) Хур итү. — *м. II.* 1) Порицание, брань. 2) Позор, бесчестье.

**Тәрзыйк** ترزيق *м. II.* Ашату-эчертү, ризык бирү. — *м. II.* Питание, кормление.

**Тәрзыйя** ترضيه *м. II.* Ризалату, риза итү. — *м. II.* Удовлетворение.

**Тәрикә** تركه *ис.* Үлгән кешедән калган мал, мирас. — *сущ.* Наследство.

**Тәрк** ترك *м. I.* 1) Ташлау, кую. *Атам аз гына вакыт авырып тәрке дөнья итмештер.* (Г. Тук.) 2) Эш (яки хәлнен) дәвамын туктату. — *м. I.* 1) Оставление, покидание, бросание. 2) Приостановка.

**Тәркиб** تركيب *м. II.* 1) Кушу, җыйнау. 2) *грам.* Сүз тезмәсе. *Максадың гәр хәзер исә, куй, тимә тел тәркибенә.* (Дәрд.) 3) Кушымта, состав. — *м. II.* 1) Составление, соединение. 2) *грам.* Словосочетание, сложное предложение. 3) Смесь, состав.

**Тәркыйг** ترقيع *м. II.* Ямау, ямау салу. — *м. II.* Починка, латание.

**Тәркыйк** ترقيق *м. II.* 1) Йомшарту. 2) Нечкәртү, нечкәләндерү. *Ма бәгъдендә булучы хәрефнең мәхрәҗенә карап тәркыйк тәләффыз кыйлыныр.* (К. Нас.) — *м. II.* 1) Смягчение. 2) Утончение, прокатывание.

**Тәркыйм** ترقيم *м. II.* 1) Нокталаркую. 2) Цифр язу, цифрлау. — *м. II.* 1) Пунктуация. 2) Нумерация, исчисление.

**Тәркыйс** ترقيص *м. II.* Биетү. — *м. II.* от гл. رقص (рәкъкасә) — заставить танцевать, плясать.

**Тәрмим** ترميم *м. II.* Төзәтү, сипләү, янарту. *Бер вакыт сәд зәгыйфьләнде, тәрмим итәргә тиешле булды.* (Ш. ж.) — *м. II.* Исправление, починка, ремонт.

**Тәррар** طرار *ис.* 1) Кесә карагы, басып алучы, талаучы. 2) Алдакчы; хәйләкәр. — *сущ.* 1) Карманный вор, жулик; грабитель. 2) Обманщик; мошенник.

**Тәрса** ترسا *ф. ис.* Христиан. *Сине күрсә, кичәр тәрса санәмдин.* (Хорәз.) — *п. сущ.* Христианин.

**Тәрсан, тәрсу** ترسان *ф. ис.* Куркак, куркуга төшкән, куркучы. — *п. сущ.* 1) Боязливый, трусливый. 2) Трус.

**Тәрсим** ترسيم *м. II.* Рәсемен (сурәтен, формасын) ясау; сызу. *Хыялның шулардагы тормышны үзендә тәрсим иттереп...* (Ф. Әмир.) — *м. II.* Рисование, черчение, изображение.

**Тәрсыйн** ترصين *м. II.* Ныгыту, тазарту. — *м. II.* Укрепление, упрочение.

**Тәрсыйг** ترصيع *м. II.* Алтын-көмеш һәм кыйммәтле ташлар белән бизәү, зиннәтләү. — *м. II.* Украшение золотом, серебром и драгоценными камнями.

**Тәрсыйс** ترصيص *м. II.* Кургашын йөгертү. — *м. II.* Покрытие свинцом.

**Тәртиб*** ترتيب *м. II.* 1) Рәтләү, рәткә салу. 2) Тәртип, дисциплина. — *м. II.* 1) Упорядочение. 2) Порядок, расположение, дисциплина.

**Тәртыйб** ترطيب *м. II.* Юешләү, дымландыру. — *м. II.* Увлажнение.

**Тәрфигъ** ترفيع *м. II.* Күтәрү, дәрәҗәсен үстерү. — *м. II.* Повышение (в чине); возвышение, возвеличивание.

**Тәрфиган** ترفيعاً *р.* Күтәреп, дәрәҗәсен үстереп. — *н.* Повышая, возвеличивая.

**Тәрфикъ** ترفيق *м. II.* Юлдаш итү; озату. — *м. II.* Сопровождение.

**Тәрфиһ** ترفيه *м. II.* 1) Тормышта җайлы шартлар тудыру. 2) Тынычлык. 3) Тормыш шартларын җиңеләйтү. — *м. II.* 1) Предоставление удобств. 2) Покой, спокойствие. 3) Облегчение, улучшение условий жизни.

**Тәрхиб** ترحيب *м. II.* Хуш килдегез, мәрхаба! дип әйтү, сәламләп шатлык белдерү. *Талибел гыйлемнәрне күрсә „мәрхаба наданлык караңгылыгының якты кандилләре“ дип тәрхиб кылыр иде.* (К. Нас.) — *м. II.* 1) Приветствие. 2) Радушие.

**Тәрхим I** ترحيم *м. II.* 1) Рәхмәт әйтү. 2) Кайгысына, хәленә керү, кайгысын уртаклашу; кызгану, аяу. — *м. II.* 1) Благодарение. 2) Сострадание, сочувствие, соболезнование.

**Тәрхим II** ترخيم *м. II.* 1) Сүзне кыскартып җиңеләйтү. 2) Тавышны йомшарту. — *м. II.* 1) Сокращение (слова). 2) Смягчение (голоса).

**Тәрхыйс** ترخيص *м. II.* Рөхсәт биру. — *м. II.* Разрешение, позволение.

**Тәршиш** ترشيش *ис.* Тапас (асылташ). *Тапас бик кадимнән мәгълүм бер җәүһәрдер, тәршиш һәм тәсмия кылыныр.* (К. Нас.) — *сущ.* Топаз (драгоценный камень).

**Тәрәддед** تردد *м. V.* Икеләнү, бер карарга килми тору. — *м. V.* Колебание, сомнение, нерешительность.

**Тәрәккеб** تركب *м. V.* Җыелу, кушылу, берничә нәрсәнең берегүе. — *м. V.* Составление, нагромождение.

**Тәрәккебат** تركبات *ис. к.* 1) Җыела (кушыла) торган аерым кисәкләр. 2) Төзелеш, кушылыш. — *сущ. мн.* 1) Сборные части, детали. 2) Строение, сложение, конструкция.

**Тәрәкъкый*** ترقى *м. V.* Алга китү, югарыга ашу, прогресс. *Тәрәкъкый вә тәгали юлларына улалым кадим.* (Г. Тук.) — *м. V.* Движение вперёд, прогресс.

**Тәрәкъкый пәрвәр** ترقى پرور *гф. ст.* Алга китү яклы, прогресс яклы кеше. *Тәрәкъкый пәрвәрләнеп хатынын ирләрдән качырмады* (Г. Газиз). — *ар.-п. сс.* Сторонник прогресса, прогрессивный деятель.

**Тәрәкъкыят** ترقيات *ис.* Тәрәкъкыйның *к.* — *сущ. мн.* от тәрәкъкый.

**Тәрәннем** ترنم *м. V.* 1) Көйләү, әкрен тавыш белән көйләү. *Ишектән колак салып тыңлап торды, нәгъмә вә тәрәнчем авазы ишеткәнгә күрә,* — *м. V.* 1) Пение, напев. 2) Трель.

*огрыйләр түгеллеген белде.* (К. Нас.) 2) Сайрау.

**Тәрәссеб** ترسب *м. V.* Юшкын, утырма. *Бу тәхәллел вә тәрәссеб дәвере тавышсыз, тынсыз гына үтмәде.* (Җ. Вәл.) — *м. V.* Осадок, отстой (на дне сосуда).

**Тәрәссел** ترسل *м. V.* Ашыкмый гына, әкрен-әкрен эшләү. — *м. V.* Осторожное, спокойное действие.

**Тәрәттеб** ترتب *м. V.* Рәтләнү, рәткә керү, тәртипләнү. — *м. V.* Порядок; упорядочение.

**Тәрәффыг** ترفع *м. V.* Олылану, эреләнү, югарыга күтәрелү, тәкәбберләнү. — *м. V.* 1) Высокомерие, заносчивость. 2) Пренебрежение.

**Тәрәх** ترح *ис.* Кайгы, көенеч, хәсрәт. — *сущ.* Печаль, скорбь.

**Тәрәххем** ترحم *м. V.* 1) Ачыну, аяу, кызгану. 2) Мәрхәмәт итү. *Бу кыйссамне ишеткәннәрдән миңа тәрәххем итмәкләре рәҗа кылыныр.* (К. Нас.) — *м. V.* 1) Страдание, жалость; сожаление. 2) Снисхождение.

**Тәрәххемән** ترحماً *р.* Мәрхәмәт йөзеннән, аяп, кызганып. — *н.* Жалостливо; милосердно; снисходительно.

**Тәрәҗҗи** ترجی *м. V.* 1) Үтенү, ялвару. 2) Өмет итү. — *м. V.* 1) Просьба, мольба (о чем-либо). 2) Надежда.

**Тәрҗеман** ترجمان *ис.* Тәрҗемәче, тылмач. — *сущ.* Переводчик, драгоман.

**Тәрҗемә*** ترجمه *ис.* Бер телдән икенче телгә күчерү. — *сущ.* Перевод с одного языка на другой.

**Тәрҗемәи халь*** ترجمهٔ حال *гыйб.* Биография. — *фр.* Биография.

**Тәрҗигъ** ترجیع *м. II.* 1) Кире кайтару, кире дүндерү. 2) Кире кайтып ишетелгән тавыш, кайтаваз. — *м. II.* 1) Возвращение. 2) Эхо.

**Тәрҗих** ترجیح *м. II.* Өстен күрү, башкадан артык күрү. *Итмә тәрҗих бән кеби мәфтүнеңә бер җаһили.* (Г. Тук.) — *м. II.* Предпочтение, отличие.

**Тәрҗия** ترجیه *кара:* тәрәҗҗи. — *см.* Тәрәҗҗи.

**Тәрһиб** ترهیب *м. II.* Куркыту, күңелгә курку салу. — *м. II.* Запугивание, устрашение.

**Тәрһибән** ترهیباً *р.* Куркытып, курку салып. *Игътизары кабул булмаган нәрсәдән тәрһибән зикер кылыныр.* (К. Нас.) — *н.* Устрашая, запугивая.

**Тәсаббер** تصبر *м. V.* Сабыр итү, чыдамлык (түземлек) күрсәтү. — *м. V.* Проявление терпения, терпеливость.

**Тәсави** تساوى *м. VI.* Тигезләнү, бертигез булу, бәрабәр һәм бер дәрәҗәдә булу. — *м. VI.* Равенство, одинаковость; подравнивание.

**Тәсавиэ ләйл вә нәһар** — көн һәм төн озынлыгы бертигез булу. — Равноденствие.

**Тәсавир** تصاوير Тасвир-ның *к.* — *мн.* от тасвир.

**Тәсаггыб** تصعب *м. V.* Читенәю, авыраю. — *м. V.* Затруднение, трудность.

**Тәсаггыд** تصعد *м. V.* Калку, күтәрелү (җирдән чыгып күтәрелү), пар булып күтәрелү. — *м. V.* Подъём; испарение.

**Тәсадди** تصدى *м. V.* 1) Башлау, эшкә керешү, инициатива. 2) Кешенекенә кул салу. *Бер галимнән бераү бер мәсьәлә сораса, син никадәр галим булсаң да, ул галим тарафыннан җавапка тәсадди кылма.* (К. Нас.) — *м. V.* 1) Начинание, инициатива. 2) Посягание.

**Тәсаддык** تصدق *м. V.* Садака бирү, хәер бирү. *Биреп даим тәсаддык, әйлә ихсан.* (М. Кол.) — *м. V.* Подаяние, пожертвование.

**Тәсаддыр** تصدر *м. V.* 1) Башта тору, баш булу. 2) Алдынгы булу. — *м. V.* 1) Председательствование. 2) Первенство.

**Тәсадем** تصادم *м. VI.* Бәрелешү, бер-берсенә бәрелү. — *м. VI.* Столкновение.

**Тәсадеф** تصادف *м. VI.* 1) Очрашу. 2) Туры килү, көтмәгәндә очрау. *„Шәкерт яхут бер тәсадеф“.* (Г. Тук.) 3) Бәрелү (кара-каршы). 4) Авария. — *м. VI.* 1) Встреча. 2) Совпадение. 3) Столкновение. 4) Авария.

**Тәсадефи** تصادفى *с.* Очраклы, туры килеп кенә булган. — *прил.* 1) Встречный. 2) Случайный.

**Тәсадефән** تصادفاً *р.* Очраклы рәвештә; көтмәгәндә; кинәт кенә. *Симез ләкин авыруга мөбтәля кешеләрнең, төрмәгә ябылып күп ашаудан мәхрүм ителгәч, тәсадефән тазардыклары күрелмешдер.* (Ш. ж.) — *н.* Случайно; внезапно; сразу.

**Тәсайеф** تصيف *м. V.* Җәй фасылы. — *м. V.* Летний сезон.

**Тәсаллеб** تصلب *м. V.* Кату, катылану, каты булу. — *м. V.* Отвердение, затвердение.

**Тәсамех** تسامح *м. VI.* 1) Бер-бере- — *м. VI.* 1) Взаимная снисходительность, про-

нең кимчелеклəрен күрмəү. 2) Игътибар итмəү, əһəмият бирмəү. — шение. 2) Небрежность, беспечность, попустительство, пренебрежение.

**Тəсаниф** تصانيف *ис. к.* Китаплар; (əдəби, фəнни һ. б.) əсəрлəр. *Тəсанифе ачык борһан, бəсыйрəтне ачык кылган.* (Ак.) — *сущ. мн.* Книги; научные, художественные произведения.

**Тəсанныг** تصنع *м. V.* Ясалмалану, көчлəнеп кылану, риялану. *Анда тəсанныгның əсəре дə юк, — диде.* (К. Нас.) — *м. V.* Искусственность, деланность.

**Тəсаррыф** تصرف *м. V.* 1) Ия, хуҗа булу. 2) Кулга керү, кулда тоту. 3) Эшне идарə итү. *Риза, рəнҗеш, гафу биззат калеб тəсаррыфында булганга, һич үз ирадəм белəн калебдəн төшерə алмам.* (Г. Ибр.) — *м. V.* 1) Хозяйничание, обладание. 2) Руководство, управление делами.

**Тəсаувыр** تصور *м. V.* Сурəтлəп күз алдына китерү, гəүдəлəндерү. *Телемə бер сүз вə күңелемə башка бер тəсаувыр килмəйдер иде.* (Г. Габ.) — *м. V.* Предположение, воображение, представление.

**Тəсаувыф** تصوف *м. V.* 1) Дин өйрəтмəлəрен серле һəм үзлəренə генə билгеле бер рəвештə аңлау. 2) Дини бер юнəлеш, суфилык, ишанлык. *Хəсəн Сəүри əйтте: „Тəсаувыф элгəре халь иде, аннан соң каль булды, хəзер каль дə китте, халь дə китте, хəйлə калды“, — диде.* (К. Нас.) — *м. V.* 1) Мистицизм, суфизм, суфийство. 2) Религиозность; религиозное течение.

**Тəсбигъ** تسبيع *м. II.* Җиделəштерү, җидегə җиткерү. — *м. II.* Усемерение.

**Тəсбих*** تسبيح *м. II. дини* Дисбе, тəсбих. *Тəсбихын шылтыратып аргач...* (З. Һади). — *м. II. рел.* Чётки.

**Тəсбит** تثبيت *м. II.* Нык тоту, ныгыту, селкендермəү. — *м. II.* Стабилизация, упрочение, укрепление, утверждение.

**Тəсвиб** تصويب *м. II.* Турылау, дөреслəү, төзəтү, дөрес дип санау. — *м. II.* Исправление; подтверждение, одобрение.

**Тəсвид** تسويد *м. II.* 1) Каралау, карага буяу. 2) Каралама язу. — *м. II.* 1) Зачернение. 2) Писание начерно.

**Тəсвил** تسويل *м. II.* 1) Ышандыру. 2) Кызыктырып алдалау. 3) Ялгыш юлга кертү, саташтыру. — *м. II.* 1) Внушение. 2) Искушение, соблазнение. 3) Введение в заблуждение.

**Тәсвия** تسويه *м. II.* Тигезләү, бердәй итү. — *м. II.* 1) Уравнение. 2) Сглаживание, улаживание.

**Тәсвиф** تسويف *м. II.* Кичектерү, соңга калдыру. *Бурычны әда кылмага кадир икән, тәсвиф хәрам бәлки гөнаһдыр.* (К. Нас.) — *м. II.* Откладывание; отсрочивание; отсрочка.

**Тәсгыйр** تسعير *м. II.* Бәһа кую, бәя билгеләү; такса, тариф. *Имам Малик исә кыйхыт елында тәсгыйр важиб димештер.* (К. Нас.) — *м. II.* Назначение цены; тариф, расценка, такса.

**Тәсдид** تسديد *м. II.* 1) Турайту, турылыкка, дөреслеккә юнәлтү. 2) Түләү. — *м. II.* 1) Нацеливание, направление на правильный путь. 2) Уплата, погашение.

**Тәсдис** تسديس *м. II.* 1) Алтылаштыру, алтыга бүлү, алты почмаклы итү. 2) Шигырьнең аерым бәетләреннән соң алты юллы кушымта бирү. — *м. II.* 1) Ушестерение. 2) Шестистрочные дополнения к стихам.

**Тәсйир** تسيير *м. II.* Йөртү, җибәрү, ходка җибәрү. — *м. II.* Пуск в ход, приведение в движение.

**Тәскит** تسكيت *м. II.* Туктату, сүздән туктату, дәштермәү. — *м. II.* Принуждение (кого-либо) к молчанию.

**Тәскин** تسكين *м. II.* 1) Тындыру, тынычландыру. *Сусамыш кеше белән тәскин хәрарәт итмәенчә мөшавәрәт итмә.* (К. Нас.) 2) *грам.* Сүзнең хәрефен сәкен белән (кисеп) уку. — *м. II.* 1) Успокоение. 2) *грам.* Постановка сукуна над согласной.

**Тәскыйя** تسقيه *м. II.* Су бирү, сугару. — *м. II.* Орошение, напоение.

**Тәскыйл** تثقيل *м. II.* Авырлаштыру, авырайту, авырлыкны арттыру. — *м. II.* Отяжеление, отягчение, обременение.

**Тәслим** تسليم *м. II.* 1) Кулдан кулга тапшыру, бирү. *Әлен алып Зөләйхая тәслим кылды.* (К. Гал.) 2) Бирелү, тапшырылу. 3) Тану, каршылыксыз тану, игътираф итү. 4) Сәламләү. — *м. II.* 1) Вручение; передача. 2) Сдача, капитуляция, уступка. 3) Признание. 4) Приветствие.

**Тәслимият** تسليميت *ис.* Тапшырылу, бирелү. — *сущ.* Сдача, капитуляция.

**Тәслих** تسليح *м. II.* Кораллaндыру, корал бирү. — *м. II.* Вооружение (кого-либо).

**Тәслитъ** تسليط *м. II.* Берәүгә власть, хакимлек бирү. — *м. II.* Предоставление власти, облечение властью.

**Тәслия** تسليه *м. II.* Кайгылы кешене юату. *Мәгъсыятькә грифтар булган кемсәнәләргә тәслия мәкамында әйтеләр.* (К. Нас.) — *м. II.* Успокаивание (кого-либо).

**Тәслиять** تسليت *кара:* тәслия. *Чиккән зәхмәтләрем бәрабәренә тәслиять таба алдым.* (З. Биг.) — *см.* Тәслия.

**Тәсмим** تسميم *м. II.* Агулау, зәһәрләү, агу бирү. *Үз-үзен тәсмим итмеш.* (Х. Чис.) — *м. II.* Отравление.

**Тәсмин I** تسمين *м. II.* Симертү, көрәйтү. — *м. II.* Откармливание.

**Тәсмин II** تثمين *м. II.* 1) Сигез тапкыр арттыру. 2) Сигезгә бүлү. — *м. II.* 1) Увеличение в восемь раз. 2) Деление на восемь.

**Тәсмия** تسميه *м. II.* Ат кушу, исем бирү, исемләү, атау. *„Кырык бакча" тәсмия кыйлынмыш рисаләм.* (К. Нас.) — *м. II.* Наименование, называние.

**Тәсния** تثنيه *м. II.* *грам.* Сүзнең икелек санында килүе, икелек саны. — *м. II. грам.* Двойственное число, постановка в двойственном числе.

**Тәсриб** تسريب *м. II.* Юллау, күндерү, җибәрү. — *м. II.* Посылание, отпускание; направление.

**Тәсригъ** تسريع *м. II.* Ашыктыру. — *м. II.* Ускорение, форсирование.

**Тәсрир** تسرير *м. II.* Сөендерү, шатландыру. — *м. II.* Радование, доставление удовольствия.

**Тәсрих** تسريح *м. II.* 1) Бушату, коткару. 2) Аеру. *Кыз аңа: никях беләң миңа малик булдың, лотыф вә кәрәм беләң мине тот яки тәсрих кыл, ихтыярың, диде.* (К. Нас.) — *м. II.* 1) Увольнение; освобождение. 2) Отделение, разведение, развод.

**Тәстир** تستير *м. II.* Пәрдәләндерү; бөркәндерү; каплау. — *м. II.* 1) Занавешивание. 2) Покрытие, закрытие, прикрытие.

**Тәстыйх** تسطيح *м. II.* Яссылау, яссыландыру; төзәйтү, тигезләү (өстен). — *м. II.* Уравнивание (улицы, дороги, площади); нивелировка.

**Тәсхин** تسخين *м. II.* Кыздыру, эсселәндерү, кайнар итү. — *м. II.* Нагревание, согревание.

**Тәсхир I** تسحير *м. II.* Сихырлау, сихырлаган кебек башын-күзен әйләндерү. — *м. II.* Колдовство, очарование.

**Тәсхир II** تسخير *м. II.* Яулап алу, биләү. *Сәгъдинең сүзләре гайре ихтыяри уларак күңелләрне тәсхир вә мәелләрче җәзеб әйләр.* (Р. Фах.) — *м. II.* Завоевание, завладение, покорение.

**Тәсәббәт** تثبت *м. V.* Нык тору, селкенмәү. — *м. V.* Стабилизация, упрочение, укрепление.

**Тәсәлла** تسلی *м. V.* Юату; күңел юану. *Хисаметдин эчендә бер тәсәлла тапты.* (М. Ак.) — *м. V.* Утешение, успокоение.

**Тәсәллем** تسلم *м. V.* Алу, бирелә торган әйберне алу, кабул итү. — *м. V.* Получение, принятие.

**Тәсәллыт** تسلط *м. V.* Берәүне үз биләвенә алып, аның өстеннән үзе теләгәнчә хөкем йөртү. — *м. V.* Господство, властвование; самоуправство.

**Тәсәлсел** تسلسل *м. V.* Чылбырланып бер-берсенә тоташып китү, бер-бер артлы тезелеш. — *м. V.* Сцепление, связь.

**Тәсәммем** تسمم *м. V.* Агулану. — *м. V.* Отравление.

**Тәсәттер** تستر *м. V.* Пәрдәләнү, бөркәнү, ябыну, каплану. — *м. V.* 1) Скрывание. 2) Скрытность.

**Тәсәэел** تسأل *м. V.* Теләнү, хәер сорашу. — *м. V.* Попрошайничество, нищенство.

**Тәсҗигъ** تسجيع *м. II.* 1) Тезмә сүз сөйләү. 2) Рифмалаштыру. 3) Үлчәүгә салынган (рифмалы) сүз. — *м. II.* 1) от гл. سجع (сәҗҗәга) — говорить рифмованной прозой. 2) Рифмование. 3) Рифмованное слово.

**Тәсҗил** تسجيل *м. II.* Дәгъваны рәсмиләштерү өчен хөкем дәфтәренә беркетү, рәсмилек бирү өчен регистрация ясау. — *м. II.* Введение, занесение в реестр, регистрация.

**Тәсһил** تسهيل *м. II.* Җиңеләйтү, асатлаштыру, уңайлаштыру, җиңел итү. *Хруфатымызны җиңеләйтү мәгарифнең тәсһил интишаренә сәбәб улачактыр* (М. Бөдәйли). — *м. II.* Облегчение, упрощение, льгота.

**Тәтаббеб** تطبب *м. V.* 1) Дәвалау эшен үтәү, врачлык эше белән шөгыльләнү. 2) Дәвалану. — *м. V.* 1) Занятие врачеванием. 2) Лечение, прохождение курса лечения.

**Тәтабегъ** تتابع *м. VI.* Бер-беренә ияреп килү, бер-бер артлы килү, тоташ булу. — *м. VI.* Следование (друг за другом); последовательность, непрерывность.

**Тәтабыкъ** تطابق *м. VI.* Бер-беренә туры килү, араларында аерымлык булмау, ярашканлык. — *м. VI.* Совпадение, соответствие, согласованность.

**Тәтавел** تطاول *м. VI.* 1) Озынаю, озаю. 2) Явыз ният белән куллану. — *м. VI.* 1) Удлинение. 2) Злоупотребление.

**Тәтаер** تطاير *м. VI.* 1) Очышу, очу. 2) Каты һәм сыек җисемнәрнең газ хәленә күчүе. — *м. VI.* 1) Летание. 2) Улетучивание, превращение в газообразное состояние.

**Тәтайеб** تطيب *м. V.* Үзенә ислемай сөртү, хушбуй сөртенү. — *м. V.* от гл تطيب (тәтайябә)—душиться (духами).

**Тәтайер** تطير *м. V.* Шомлану, начарлыкка юрау. — *м. V.* Принятие за плохое предзнаменование.

**Тәтарек** تارك *м. VI.* Ташлану. — *м. VI.* Бросание (самого себя).

**Тәтаффел** تطفل *м. V.* 1) Чакырылмый кунакка килү. 2) Комсызлык. 3) Түбәнләнү, тәлинкә ялау. — *м. V.* 1) Неожиданный приход (без приглашения). 2) Алчность. 3) Назойливость, самоунижение.

**Тәтаһһер** تطهر *м. V.* Тазару, пакьләнү, сафлану, арулану. — *м. V.* Очищение, обмывание, дезинфицирование.

**Тәтвиҗ** تتويج *м. II.* Таҗ кидерү. — *м. II.* Коронование.

**Тәтиммә** تتمه *ис.* 1) Тәмамлау өчен кушылган нәрсә, кушымта. 2) Тулылау өчен кирәк булган нәрсә. *Инде моның тәтиммәсен „Чәмәнлек вә чәчәклек" рисаләсеннән кара.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Завершение; окончание. 2) Дополнение, продолжение.

**Тәтмим** تتميم *м. II.* Тәмамлау, бетерү, тулыландыру. — *м. II.* Окончание, довершение.

**Тәтәббыг** تتبع *м. V.* 1) Тикшерү, эзләү, казыну. *Адәмнәрнең гаебенә тәтәббыг кылган кеше олуглыкка ирешмәде.* (К. Нас.) 2) Өйрәнү, эзләнү. — *м. V.* 1) Прослеживание. 2) Исследование, изучение.

**Тәтәүвеҗ** تتوج *м. V.* Таҗ кию, үз башына таҗ кую. — *м. V.* Коронование, надевание короны.

**Тәәүвеһ** تأوه *м. V.* Аһ итү, аһ ору. *Сырхау булса, я бәла-каза килсә, аслан тәәүвеһ кылмас иде.* (К. Нас.) — *м. V.* Охание, вздыхание.

**Тәфавет** تفاوت *м. VI.* Аерма, төрле-төрле булу; аерымлык. — *м. VI.* Различие, отличие, расхождение; разность.

**Тәфагыйл** تفاعيل *ис. к.* 1) Шигырь үлчәве. 2) Шигырьнең һәр юлы мәфагыйл үлчәве белән билгеләнүе. — *сущ. мн.* 1) Стихотворный размер. 2) Стихосложение размером „мәфагыйл".

**Тәфазыл** تفاضل *м. VI.* Өстенлек итү; өстенлек дәгъвасы кылу. — *м. VI.* Превосходство, преимущество.

**Тәфарикъ** تفاريق Тәфрикъ-нең *к.* — *мн.* от тәфрикъ.

**Тәфарык** تفارق *м. VI.* Бер-береннән аерылу, аерылышу. — *м. VI.* Расхождение, разлучение, разъединение.

**Тәфасир** تفاسير Тәфсир-нең *к.* — *мн.* от тәфсир.

**Халь I*** حال *ис.* 1) Хәл, торыш. 2) Көч, куәт. *Кәндем халь кадәре матурландым.* (М. Гаф.) 3) *грам.* Хәзерге заман. — *сущ.* 1) Обстоятельство, случай. 2) Положение, состояние, сила, мощь. 3) *грам.* Настоящее время.

**Халь II** خال *ф. ис.* Мин. — *п. сущ.* Родинка.

**Хальбуки*** — Шулай булуга карамастан. — Тогда как.

**Халят** حالات Халь I-нен *к.* — *мн.* от халь I.

**Халә** خاله *ис.* Ананың кыз туганы (олы апай). — *сущ.* Тётка (со стороны матери).

**Халән** حالاً *р.* 1) Хәзердә, хәзерге көндә, бу вакытта. 2) Хәзер үк. *Фәйруз шаһ: „Әфәндем, халән сәфәр мәшакатьледер, яз вакытында барырсыз, сабыр итмәк әүлядыр,— диде.* (К. Нас.) — *н.* 1) Теперь, в настоящее время. 2) Сейчас, немедленно.

**Халән вә истикъбалән** — хәзер дә, киләчәктә дә. — И теперь, и в будущем.

**Халәнки** حالاًكه *ф. ст.* Хальбуки, чынлыкта. — *п. сс.* Дело в том, что..., тогда как, между тем... .

**Халәт*** حالت *ис.* Хәл, рәвеш, күренеш, торыш. *Һәр кеше яшен алдындагы минутка охшаш бер халәт хис итә.* (Г. Ибр.) — *сущ.* Положение, состояние, ситуация.

**Халәте икраһ** حالت اكراه *ст.* Көчләү хәле, көчләнү хәле. *Фәтхулла хәзрәт: „Халәте икраһ, халәте икраһ“,— диде.* (Ф. Әмир.) — *сс.* 1) Принуждение. 2) Вынужденное положение.

**Халәте нәзыг** حالت نزع *ст.* Үлә башлау, җан биру вакыты. *Халәте назыгда рахәт табар.* (К. Нас.) — *сс.* Состояние агонии, предсмертный час.

**Халәте рухия** حالت روحيه *ст.* Рух халәте, кәеф. — *сс.* Душевное состояние, настроение.

**Халәте хәсәнә** حالت حسنه *ст.* Гүзәл, яхшы хәл. *Болгарның халәте хәсәнәсен Казан варис улды.* (Ш. Мәр.) — *сс.* Хорошее положение.

**Хам I** خام *ф. с.* 1) Чи, пешмәгән, өлгермәгән, эшкәртелмәгән. 2) Тупас. *Сине б°р хам тимер зан кылган ул хам.* (Дәрд.)

*п. прил.* 1) Сырой, недоваренный, незрелый; неопытный. 2) Грубый.

**Хам II** حام *ис. миф.* Нух пигамбәр балаларыннан берсенең исеме. *Борын заман һәлак булган хамнар батып туфанга.* (Г. Кан.)

*сущ. миф.* Имя одного из сыновей Ноя.

**Хами** حامى *сф.* Яклаучы.

*пр. д.* Защитник, покровитель.

**Хамид I** حامد *сф.* 1) Мактаучы. 2) Шөкер итүче.

*пр. д.* 1) Хвалящий, 2) Благодарящий.

**Хамид II** خامد *сф.* Хәрәкәтсез торучы, кузгалмаучы. *Хәсиснең һиммәте хамид, кулы җамиддыр, диде.* (К. Нас.)

*пр. д.* Находящийся без движения.

**Хамиз** حامض *ис.* 1) Әче. 2) *хим.* Кислота.

*сущ.* 1) Кислый. 2) *хим.* Кислота.

**Хамиз карбун** — кислород.

Кислород.

**Хамиз кибрит** — күкерт әчесе.

Серная кислота.

**Хамиз хәдид** — тимер әчесе.

Окись железа.

**Хамил** حامل *сф.* 1) Кулында тотучы, ия. 2) Күтәрүче, өстенә йөкләүче. *Әдвия хамил булмас бәгъзы мәризъ.* (Ак.)

*пр. д.* 1) Владеющий, имеющий на руках. 2) Носящий, переносящий, несущий.

**Хамил вәрәка** حامل ورق *ст.* 1) Кәгазь (язу) илтүче. 2) Хат тапшыручы. *Бу хамиле вәрәкалә өч сум акча җибәрдем.* (З. Биг.) 3) Гариза бирүче.

*сс.* 1) Несущий записку (бумагу, пакет). 2) Почтальон. 3) Податель (прошения, жалобы и т. п.).

**Хамилә** حامله *с.* Йөкле (корсаклы) хатын. *Бер мәшәкатьнең бер рәхәте булыр, нәфсеңне хуш тот, кичә хамиләдер, шаят таңда бәхет тудырыр.* (К. Нас.)

*прил.* Беременная.

**Хамилән** حاملاً *р.* Күтәреп, күтәргән хәлдә.

*н.* Подняв, неся.

**Хамис** خامس *сан* Бишенче.

*ч.* Пятый.

**Хамисән** خامساً *р.* Бишенчеләп, бишенчедән.

*н.* В-пятых.

**Хамуш** خاموش *ф. с.* 1) Дәшмәүче. 2) Тик торучы, селкенмәүче. *Тәрәннем кылып хамуш булдылар.* (К. Нас.)

*п. прил.* 1) Молчаливый; молчащий. 2) Притихший, застывший.

**Хамуши** خاموشى *ф. ис.* Сүзсезлек, тавыш-тынсызлык. — *п. сущ.* Безмолвие, молчание.

**Хамә** خامه *ф. ис.* Каләм. — *п. сущ.* Перо.

**Хамәрән** — Каләм уйнатучы. — Борзописец, писака.

**Хан I** خوان *ф. ис.* 1) Укучы. 2) Ашъяулык, табын. — *п. сущ.* 1) Читающий; ученик. 2) Накрытая скатерть с кушаньями, сервированный стол.

**Хан II** خان *ф. ис.* Юлчылар төшә торган бина, кәрван сарай. *Каһирәдә нәсарага мәхсус бер олуг хан бар иде, аны яндырдылар.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Постоялый двор.

**Ханадан, ханәдан** خاندان *ф. ис.* 1) Семья, династия, дәрәҗәле бер фамилия астындагы кешеләр. 2) Кунакчыл, кунак сөюче. — *п. сущ.* 1) Семейство, семья, династия, род. 2) Гостеприимный, хлебосольный.

**Ханис** خانث *сф.* Антын бозучы. *Сату турында ялган сөйләшәсез, ант итәсез, ханис буласыз, диде.* (К. Нас.) — *пр. д.* Клятвопреступник, нарушитель клятвы.

**Ханә** خانه *ф. ис.* [1) Өй, йорт. 2) *грам.* Сүз ясаучы кушымча. *Гыйбадәтханә** — гыйбадәт йорты. *Кярханә* — завод, фабрика. *Әҗзаханә* — аптека. — *п. сущ.* 1) Дом, жилище, помещение. 2) *грам.* Словообразующий элемент (аффикс).

**Ханәка** خانقا *гф. ис.* Суфиларның, дәрвишләрнең тора торган урыны. — *ар.-п. сущ.* Келья дервишей.

**Ханәман** خانمان *ф. ис.* 1) Өй җәмәгате; бала-чага, хатын һәм башкалар. 2) Өй һәм өй кирәк-яраклары. — *п. сущ.* 1) Домашние; семья. 2) Дом и домашняя утварь, достояние, имущество.

**Хар** خار *ф. ис.* 1) Чәнечке, кылчык, тикән, тигәнәк. 2) Кара бөрлегән. — *п. сущ.* 1) Шип, колючка. 2) Ежевика.

**Хар вә хәс(с)** خاروخس *ф. ис.* Чүпчар, чәнечкеле чытыр-чатыр. *Былбыл телендә хар вә хәс(с) булса, вафаи васләт итмәс гөл.* (Дәрд.) — *п. сущ.* Комочки, колючие кусты.

**Харика I** حارقه *ис.* Янган ут. — *сущ.* Огонь.

**Харика II** خارقه *ис.* Гадәттән тыш әйбер; вакыйга. *Хәсән агайның игътикад вә фикере алмашуына гаҗәп идеп бер харика дия хөкем итмәктә идем.* (Г. Габ.) — *сущ.* (Что-либо) необычное, чудесное, чудо; необычное явление (событие).

**Харикъ I** خارق *сф.* Ертучы, яручы. — *пр. д.* Прорезывающий, разрывающий.

**Харикъ II** حارق *сф.* 1) Яндыручы, ягучы. 2) Ут төртүче. — *пр. д.* 1) Поджигающий. 2) Поджигатель.

**Харикылгадә** خارق العاده *гыйб.* Гадәттән тыш. *Скрипкәнең тавышларында бер харикылгадә елаумы, сөенүме, нәрсәдер бар иде* (Г. Газиз). — *фр.* Необычайный, чрезвычайный.

**Харис I** حارس *сф.* Саклаучы, яклаучы, сакчы. — *пр. д.* Стража, часовой, сторож.

**Харис II** حارث *сф.* Игенче. — *пр. д.* Землепашец, пахарь.

**Харидж** خارج *сф.* 1) Чыгучы, әйбер яки эшнең тышында булучы. 2) Тыш, тышкы. *Гадәттән харидж бер яңа хәбәр булса...* (М. Ак.) — *пр. д.* 1) Выходящий. 2) Выступающий. 3) Внешний, наружный.

**Хариджи, хариджия** خارجى، خارجيه *с.* Тышкы, тышкы эшкә (яки хәлгә) караган (яки бәйләнешле). — *прил.* 1) Внешний, наружный. 2) Иностранный.

**Хариджия назараты** خارجيه نظارتى *ст.* Тышкы эшләр министрлыгы. — *сс.* Министерство иностранных дел.

**Харидж кыйсмәт** خارج قسمت *ст.* Санны бүлгәннән соң чыккан өлеш. — *сс. мат.* Частное (от деления).

**Хариджән** خارجاً *р.* Тышкы яктан, тыштан. — *н.* Вне, снаружи.

**Хариджән вә дахилән** خارجاً و داخلاً *гыйб.* Тыштан һәм эчтән. — *фр.* Снаружи и изнутри.

**Харрә** حاره *с.* Әссе, кызу. — *прил.* Горячий, жаркий.

**Харчин** خارچين *ф. ис.* Борын заманда күзге ясый торган таш, минерал. — *п. сущ.* Минерал, из которого в древние времена изготовляли зеркала.

**Хасбә** حصبه *ис. мед.* Кызамык. — *сущ. мед.* Корь.

**Хасиб** حاسب *сф.* Хисапчы, хисаплаучы. — *пр. д.* 1) Считающий, счётчик. 2) Счетовод.

**Хасид** حاسد *сф.* Көнче, көнләшүче. *Хасидләр мәхсүднең кайгысына сөенер, шатлыгына кайгырыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Завистник; завидующий.

**Хасләт** خصلت *ис.* Үзендә булган холык, табигать; үзенчәлек, сыйфат. *Ай, кеше тыштан үзендә изге хасләт күрсәтә.* (Г. Тук.) — *сущ.* Качество, свойство; особенность.

**Хасс I** حاس *сф.* Сизүче, тоючы, тойгылы. — *пр. д.* Чувствующий, ощущающий.

**Хасс (хас) II** خاص *с.* 1) Бер нәрсәгә (бер генә әшкә) билгеләнгән. 2) Җәмгыятьнең югары катлавы. *Хасс белән гамләр арасын аера торган синмени?* (Ш. Баб.)
*прил.* 1) Особый, особенный, специальный. 2) „Верхние“ слои общества.

**Хасса** خاصه *ис.* Үзенчәлек (берәр әйбер яки кешенең үзендә генә табыла торган сыйфат).
*сущ.* Характерная черта, особенность, свойство.

**Хасселхас** خاص الخاص *гыйб.* 1) Артык аерылучы. 2) Җәмгыятьнең иң югары катлавы. *Галәм эчрә хасселхас улсын имде.* (К. Гал.)
*фр.* Самый привелигированный (слой населения, отдельный человек).

**Хассиять I** خاصيت *кара:* хасыять.
*см.* Хасыять.

**Хассиять II** حاسيت *ис.* Сизүчәнлек, тоючанлык.
*сущ.* Чувствительность, восприимчивость.

**Хассә** حاسه *ис.* Тойгы, сизү, тою куәте.
*сущ.* Чувство, ощущение.

**Хассәи бәсар** حاسهٔ بصر *ст.* Күрү куәсе. *Әгъма күрмәктә хассәи бәсарның куәтеннән хариҗ бер нокта...* (К. Нас.)
*сс.* Зрение.

**Хассәи зәвык** حاسهٔ ذوق *ст.* Тәм сизү куәсе, тату тойгысы.
*сс.* Вкус.

**Хассәи ләмес** حاسهٔ لمس *ст.* Тотып сизү куәсе.
*сс.* Осязание.

**Хассәи шәм** حاسهٔ شم *ст.* Ис сизү.
*сс.* Обоняние.

**Хассәтән** خاصةً *р.* Хаслап, аерып, аеруча төбәп.
*н.* В частности, в особенности.

**Хасыйл** حاصل *сф.* 1) Нәтиҗә. 2) Керем, табыш, файда. 3) Барлыкка килү, хасил булу. *Хасыйлем гәрчә ничә гыйсьян икәндер белмәдем.* (Һ. Сал.)
*пр. д.* 1) Результат, следствие. 2) Поступление, польза. 3) Образующийся, появляющийся.

**Хасыйлат** حاصلات Хасыйл-ның *к.*
*мн.* от хасыйл.

**Хасыйл зарб** حاصل ضرب *ст. мат.* Тапкырлангаппан соң чыккан сан.
*сс. мат.* Произведение (результат умножения).

**Хасыйле кәлям** حاصل كلام *ст.* 1) Сүзнең кыскасы, нәтиҗәсе. 2) Кыска гына әйткәндә. *Хасыйле кәлям, ризалык телдән генә риза, риза дип әйтүдән генә гыйбарәт булса, мин дә риза, риза диячәкмен.* (Г. Ибр.)
*сс.* 1) Результат, резюме. 2) Короче говоря, одним словом.

**Хасыйле җәмегъ** حاصل جمع *ст.* 1) Җыеп әйткәндә. 2) Саннарны җыйгач килеп чыккан нәтиҗә.
*сс.* 1) Говоря в целом. 2) Сумма.

**Хасыять** خاصيت *ис.* Үзлек, үзенчәлек; үзенә генә караган сыйфат. *Бу чәй кеби дәва юктыр, гаҗәп хасыяте чуктыр* (Чәй бәете). — *сущ.* Характерная черта, особенность; особое качество, свойство.

**Хат* (хатты, хәтты)** خط *ис.* 1) Сызык. 2) Язу-сызу. 3) Хат. — *сущ.* 1) Линия. 2) Полоса. 3) Почерк, каллиграфия. 4) Письмо.

**Хат гомуди** — вертикаль сызык. — Вертикальная линия.

**Хат мөтавази** — янәшә сызык. — Параллельная линия.

**Хат офыкый** — ятма сызык. — Горизонтальная линия.

**Хата *** خطا *ис.* Ялгыш, ялгышлык. — *сущ.* Ошибка, погрешность, промах.

**Хатаи фахиш** خطاًفاحش *кара:* хәтаи фахиш. — *см.* Хәтаи фахиш.

**Хата пуш** خطاپوش *кара:* хәта пуш. — *см.* Хәта пуш.

**Хатаән** خطاً *р.* Ялгышып, ялгыш кына, ялгышлык белән. *Шома тормыш юлында гизләгәндә ялгышып тайсаң, йөзеңнең дәфтәренә син хатаән кер вә тап салсаң.* (Г. Тук.) — *н.* По ошибке, невзначай.

**Хатбар** خاطبار *гф. ис.* Яучы җибәрүче, кодалаучы. *Хатын әйтте: „Хатбарым ике булды, икесе дә ханәмә килсеннәр, күрәем“,— диде.* (К. Нас.) — *ар.-п. сущ.* Посылающий сватов, сватающийся.

**Хатбә** خطبه *ис.* Яучылау. *Фәлән кеше кызымызны хатбә кылды, бирәекме,— диде.* (К. Нас.) — *сущ.* Сватовство.

**Хатиб I** خطيب *ис.* 1) Вәгазьләүче, вәгазь сөйләүче. 2) *дини* Мәчеттә хотбә укуга хаклы мулла. 3) Яхшы оратор. — *сущ.* 1) Читающий проповедь. 2) Увещевающий; проповедник в мечети, читающий „хутбу“. 3) Хороший оратор.

**Хатиб II** خاطب *сф.* 1) Сөйләшүче, эндәшүче. 2) Вәгазь сөйләүче. 3) Яучы. *Өйләнмәк касды белән хатыйбына, ягъни яучыга әйтте...* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Говорящий, выступающий. 2) Проповедующий. 3) Сватающий.

**Хатибанә** خطيبانه *р.* Сүз сөйләгән рәвештә, сөйләнгәнчә, ораторларча. — *н.* Ораторствуя, выступая с речью.

**Хатим** خاتم *сф.* 1) Мөһер, печать. 2) Мөһерле йөзек. *Тәрәзәдән бер кош кереп, хатим шәрифне шаһзадә Асылның бармагыннан алып китте.* (К. Нас.) 3) Мөһер басучы. 4) Коръәнне баштан ахырынача укып чыгучы. — *пр. д.* 1) Печать. 2) Перстень с печатью. 3) Ставящий печать, запечатывающий. 4) Прочитывающий весь Коран.

**Хатимә** خاتمه *ис.* 1) Хатим-нең *мнс.* 2) Азак, ахыр; эпилог. *Очланып беткән кибәнне эшкә охшар эш итеп, башына какмак булам бу хатимәмне шеш итеп.* (Ш. Баб.) — 1) *жен.* от хатим. 2) Заключение, окончание, конец, заключительная часть речи; эпилог.

**Хатир** خاطر *ис.* 1) Хәтер. 2) Күңелгә (зиһенгә) ала алу, истә тота алу. — *сущ.* 1) Память. 2) Способность к запоминанию.

**Хатират** خاطرات *ис. к.* Хатирәләр, күңелгә килгән, искә төшкән нәрсәләр, күңелдә сакланган эшләр, вакыйгалар, истәлекләр. *Итәм дәрхал тәвәкъкыф мин сабыйлык хатиратендә.* (Г. Тук.) — *сущ. мн.* Памятные события, то, что хранится в памяти, незабываемое.

**Хатирмандә** خاطرمانده *гф. с.* Хәтере калган, үпкәләгән; күңеле калган. — *ар.-п. прил.* Обиженный; обидевшийся.

**Хатир шинас** خاطرشناس *гф. ст.* Хәтер саклаучы, кеше күңелен табучы. — *ар.-п. сс.* Корректный, воспитанный, вежливый.

**Хатирә*** خاطره *ис.* 1) Уй, фикер. 2) Күңелгә килгән, искә төшкән нәрсә, күңелдә калган эш, вакыйга. *Хыялым гарше көрси тирәсендә түгел, җирдә, җирнең дә үткән хатирәләре арасында иде.* (Г. Ибр.) 3) Истәлек, ядкяр. — *сущ.* 1) Мысль, идея. 2) Воспоминание, памятное событие. 3) То, что заставляет вспоминать, памятный подарок, сувенир.

**Хаттат** خطاط *кара:* хәттат. — *см.* Хәттат.

**Хатты фарикъ** خطفارق Аеручы сызык. *Тел милләтләр арасында кискен хатты фарикъ.* (Җ. Вәл.) — Отделяющая черта.

**Хатәменнәбиин** خاتم النبين *гыйб. дини* Иң соңгы пигамбәр (Мөхәммәт пигамбәр). — *фр. рел.* Последний пророк (эпитет Мухаммеда).

**Хафа*** خفا *кара:* хәфа. — *см.* Хәфа.

**Хафи** خافى *сф.* 1) Яшерүче. 2) Яшерүле. — *пр. д.* 1) Прячущий. 2) Тайный, скрытый, невидимый.

**Хафид, хәфид** حافد،حفيد *ис.* Берәүнең баласының баласы, онык. — *сущ.* Внук.

**Хафиз** حافظ *сф.* 1) Саклаучы. 2) Күңелдән ятлаучы. 3) *дини* Коръәнне күңелдән белүче. *Мә, печән базарында Тимерша хафизның үз кулына бирерсең.* (Ф. Әмир.) — *пр. д.* 1) Оберегающий, хранящий. 2) Помнящий наизусть. 3) *Рел.* Лицо, знающее наизусть Коран.

**Хафизә** حافظه *сф.* 1) Хафиз-ның *мнс.* 2) Зиһен; хәтер, хәтердә сакланганнар. *Фәтхулла хәзрәт хафизәсендә „очканда укый торган дога“ дигән нәрсә таба алмады.* (Ф. Әмир.) — *пр. д.* 1) *жен.* от хафиз. 2) Память; воспоминания.

**Хач** خاچ *ф. ис.* Тәре. *Безгә хач сугышларының тарихын сөйли* (Г. Газиз). — *п. сущ.* Крест.

**Хаша** حاشا *ис.* 1) Һич, беркайчан да. 2) Ризасызлыкны һәм инкарьне аңлатучы ымлык. — *сущ.* 1) Никоим образом, никогда. 2) Отказ, отрицание.

**Хаша вә хаша** — Һич-һич, беркайчан да. *Шаһзадә: хаша вә хаша, миннән сезгә һичбер җәһәттән зарар ирешмәс,— диде.* (К. Нас.) — Нет-нет, никогда.

**Хашиган** خاشعا *р.* Түбәнчелек белән. — *н.* Благоговейно.

**Хашигъ** خاشع *сф.* 1) Хурлыкта булучы. *Мәгез, гашиятегезне алыгыз, аның өчен йөзем хашигъ булмасын!— дип атып чыгып китмеш.* (К. Нас.) 2) Түбәнчелек күрсәтүче. — *пр. д.* 1) Униженный; опозоренный. 2) Покорный, смирный.

**Хашир** حاشر *сф.* Җыючы; туплаучы. — *пр. д.* Собирающий; соединяющий.

**Хашия** حاشيه *ис.* 1) Чит, кырый. 2) Китап яки хат читендәге язма. 3) Бер китапның эчтәлеген ачыклаучы икенче бер китап, әсәр. — *сущ.* 1) Край, конец. 2) Примечание; приписка (на полях книги, в письме). 3) Глоссы, комментарий, толкование.

**Хаҗ I** حاج *кара:* хаҗи. — *см.* **хаҗи.**

**Хаҗ II** حج *ис.* Елның билгеле бер вакытында гыйбадәт кылыр өчен Мәккә шәһәренә барып кайту. — *сущ.* Паломничество, посещение в определённое время года святых мест (Мекки и Медины).

**Хаҗат** حاجات Хаҗәт-нең *к.* — *мн.* от Хаҗәт.

**Хаҗи *** حاجى *сф.* Мәккәгә барып хаҗ кылып кайткан кеше. — *пр. д.* Паломник, хаджи (человек, совершивший паломничество в г. Мекку).

**Хаҗиб** حاجب *сф.* Капкачы; хан (патша) сарайларындагы хөрмәтле дәрәҗә исеме, чин. — *пр. д.* Привратник, швейцар, камергер, придворный служитель.

**Хаҗә** خواجه *ф. ис,* 1) Хуҗа; ия. 2) Белемле; өйрәтүче, укытучы. 3) Затлы нәселдән. — *п. сущ.* 1) Господин; хозяин, начальство. 2) Знающий; обучающий. 3) Благородного происхождения.

**Хаҗәт *** حاجت *ис.* 1) Кирәк, кирәклек, хәҗәт, йомыш, эш. 2) Кирәк нәрсә, әйбер. — *сущ.* 1) Нужда, потребность, желание, дело, надобность. 2) Необходимый предмет, вещь.

**Хажәтмәнд** حاجتمند *гф. ис.* Мохтаж кеше (кирәкле әйберләре булмаган фәкыйрь). *Әйдер: „Санәм, хажәтмәнд улдым сәңа“.* (К. Гал.) — *ар.-п. сущ.* Нуждающийся, бедный, бедняк.

**Хажәтханә*** حاجتخانه *гф. ис.* Бәдрәф, әҗәтханә. — *ар.-п. сущ.* Уборная, отхожее место, ватерклозет.

**Хаһ** خواه *ф. с.* 1) Теләүче; эстәүче. 2) Кирәксә, теләсә. *Хаһ ниндәен гүзәлләр булсын, аның янында күземә чиркин күренерләр.* (К. Нас.) — *п. прил.* 1) Желающий; хотящий. 2) Любой, какой угодно.

**Хаһиш** خواهش *ф. ис.* Теләк, морад, максат. — *п. сущ.* Желание, цель, воля.

**Хаһ-нахаһ** خواهناخواه *ф. ст.* Теләсәтеләмәсә, теләр-теләмәс. *Җыйган малларын хаһ-нахаһ монда калдырып, гайреләр тәсаррыф кылырлар.* (К. Нас.) — *п. сс.* Волей-неволей.

**Хаһәр** خواهر *ф. ис.* Кыз туган, кыз кардәш. — *п. сущ.* Родная сестра.

**Хедмәткяр*** خدمتكار *гф. ис.* Хезмәткәр, хезмәт итүче. — *ар.-п. сущ.* Служащий; работник умственного труда.

**Хиббалә** حباله *ис.* (Җептән ясалган) тозак. *Дошманнар хиббаләне салып карый, тургайның тозагына лачын төшмәс.* (Ак.) — *сущ.* Силки.

**Хиддәт** حدت *ис.* 1) Ачулану, чәпчеп китү, кабарыну. *Нәдән бу хиддәт, и шагыйрь.* (Дәрд.) 2) Катылык, кискенлек. 3) Дәртлелек. — *сущ.* 1) Горячность, вспыльчивость, гнев. 2) Острота, грубость. 3) Рвение, пыл.

**Хидмат** خدمات *ис.* Хидмәт-нең *к.* — *мн.* от хидмәт.

**Хидмәт** خدمت *ис.* Эш, хезмәт, йомыш. *Мин сезә бер олуг хидмәт илә кәлдем.* (З. Биг.) — *сущ.* 1) Служба. 2) Услужение. 3) Работа, должность. 4) Услуга.

**Хидью** خديو *ф. ис.* Патша, әмир (Мисыр мәмләкәтенең хакиме, дәүләт башындагы кешесе, хәдиф). — *п. сущ.* Государь, владыка, повелитель, хедив (правитель Египта).

**Хизеб** حزب *ис.* 1) Партия (политик). 2) Бер группа, бүлек. 3) Коръәннең алтмыштан бер өлеше. *Бу шәйтан коралын уйнап утырганчы „хизбеләгъзам укысаң, җәннәткә керермең“ дип курка торгансың“,— диде* (Г. Газиз). — *сущ.* 1) Партия (политическая). 2) Группа людей. 3) Шестидесятая часть Корана.

**Хизлан** خذلان *ис.* 1) Хурлыкка төшү, көлкегә калу. *Тәүбәсез китмәк каты* — *сущ.* 1) Позор, бесчестье. 2) Оставление без помощи.

*хизлан икәндер белмәдем.* (Һ. Сал.) 2) Ярдәмчесез калдыру.

**Хизыр** خضر *кара:* хозыр.
*см.* Хозыр.

**Хикая, хикаять*** حكايه، حكاية *кара:* хикәя.
*см.* Хикәя.

**Хикмият** حكميات Хикмәт-нең *к.*
*мн.* от хикмәт.

**Хикмәт*** حكمت *ис.* 1) Хикмәт; фәлсәфә. 2) Мәкаль. 3) Сәер, әкәмәт! *Шулай дисәң генә, юкса шундый хикмәтләр була, мин сиңа әйтим.* (Ш. Кам.) 4) Сер. 5) Белем.
*сущ.* 1) Мудрость; философия. 2) Мудрое изречение, поговорка, пословица. 3) Странно! Чудно! 4) Тайна, секрет. 5) Знание; просвещение.

**Хикмәте гамәлия** حكمت عمليه *ст.* Практик белем.
*сс.* Практическое знание.

**Хикмәте гыйльмия** حكمت علميه *ст.* Фәнни белем.
*сс.* Научное знание.

**Хикмәте назарыя** حكمت نظريه *ст.* Теоретик белем.
*сс.* Теоретическое знание.

**Хикмәте табигыя** حكمت طبيعيه *ст.* Физика, гомумән табигать белеме.
*сс.* Физика, вообще естественные науки.

**Хикмәт шинас** حكمت شناس *ст.* Белемле, гыйлемле кеше, хикмәт белүче.
*сс.* Знающий, мудрец, учёный.

**Хикыд** حقد *ис.* Яшерен ачу тоту, кинә, тыштан дус булып, эчтән дошманлык. *Хикыд, ягъни заһирән дус күрсәтеп эчтән дошманлык белән интикам күзәтеп тормактыр.* (К. Нас.)
*сущ.* Злоба, ненависть, вражда, скрытое чувство неприязни.

**Хикәм** حكم Хикмәт-нең *к.*
*мн.* от хикмәт.

**Хикәя*** حكايه، حكاية *ис.* 1) Сөйләп бирү, хикәя. 2) *грам.* Туры сөйләм.
*сущ.* 1) Рассказ, повесть. 2) *грам.* Прямая речь.

**Хикәят** حكايات Хикәя-нең *к.*
*мн.* от хикәя.

**Хилаф** خلاف *ис.* Каршы, ярамаган эш, кире, тискәре. *Бер адәмдә үзенә хилафлык күрсә, ул кешегә ачулана.* (З. Һад.)
*сущ.* Противоречие, разногласие, конфликт, расхождение.

**Хилафе гадәт** خلاف عادت *ст.* Гадәткә каршы. *Йосыф хилафе гадәт озын тегелгән тужуркасының кесәсенә кулын тыгып килеп керде* (Г. Газиз).
*сс.* Против обычая.

**Хилафе заһир** خلاف ظاهر *ст.* Ачык, билгеле булган күренешкә каршы. *Элек*
*сс.* Явное расхождение, разногласие.

*мактаулы булып та соңра хилафе заһир булды.* (З. Биг.)

**Хилафе канун** خلافقانون *ст.* Законга (тәртипкә) каршы. — *сс.* Противозаконный.

**Хилафе кыяс** خلافقیاس *ст.* Кагыйдәгә каршы; туры килми торган (берәр кагыйдәгә). *Зөләйханың әнисени хилафе кыяс тапмадыгыннан.* (З. Биг.) — *сс.* Несоразмерность, несоответствие (какому-либо) правилу.

**Хилафе фараз** خلاف فرض *ст.* Уйлаганның киресе; уйлаганга каршы. — *сс.* Не то, что предполагалось.

**Хилафе шәрыг** خلاف شرع *ст. дини* Шәригатькә каршы. *Камилә белән „Урыс Пәкри" дигән бер егетнең уйнаш кылу, хилафе шәргъ мөнәсәбәттә булуда төһмәт итеп* ... (Г. Ибр.) — *сс. рел.* Антизаконный (несоответствующий законам шариата).

**Хилафән** خلافاً *р.* Карышып, каршылык итеп, киресенчә буларак. — *н.* Вопреки тому, что..., в отличие от ..., в противоположность...

**Хилафәт** خلافت *ис.* 1) Хәлифәлек; хәлифә исемен алу. 2) Хәлифә кул астындагы ил. 3) Хәлифәлек заманы. 4) Урынбасарлык. — *сущ.* 1) Звание халифа. 2) Халифат. 3) Эпоха правления халифа. 4) Заместительство.

**Хилгать** خلعت *ис.* Югары дәрәҗәле кешеләр тарафыннан бүләк ителгән („кидерелгән") кыйммәтле өс киеме. *Өстенә ятмыш хилгать кидерде.* (К. Нас.) — *сущ.* Жалованная одежда, награда („шуба со своего плеча").

**Хилем** حلم *ис.* 1) Йомшаклык, юашлык, ачусызлык. *Бер кеше сине явыз холкы белән ачуландырса, син хилмең белән аңа вәгазь кыл.* (К. Нас.) 2) Акыллылык. — *сущ.* 1) Кротость, мягкость, доброта. 2) Благоразумие.

**Хили, хәйли** خیلی *р.* Байтак, яхшы ук күп. *Хатыны яныннан чыкканына хили заманнар үтте.* (Г. Фәез.) — *н.* Много, часто.

**Хилка** حلقه *ис.* 1) Балдак, божра, алка. 2) Түгәрәк; утырган кешеләр түгәрәге. *Нәкъ эче азгын мөрит, мәҗнүн ишаннар хилкасы.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Кольцо, серьга. 2) Круг (людей).

**Хилкать** خلقت *ис.* 1) Табигать. 2) Яратылыш. 3) Тышкы күренеш; буйсын. *Хилкате кебек холкы да гүзәл имеш.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Природа; естество. 2) Сотворение, создание. 3) Внешний вид, наружность; сложение, форма.

**Хилкате галәм** خلقتعالم *ст.* Дөнья яратылышы. — *сс.* Сотворение мира.

**Хилкый** خلقى *с.* Тумыштан булган, табигый. — *прил.* Естественный, природный, врождённый.

**Химар** حمار *ис.* Ишәк. *Син химар дип хурлаганың заты тулпар улмасын.* (Ак.) — *сущ.* Осёл.

**Химая, химаять** حمايه،حماية *ис.* 1) Яклау, саклау. *Химаять әйләдең пивнойда динне.* (Г. Тук.) 2) Берәүнең кулы астында булып саклану. — *сущ.* 1) Защита, покровительство. 2) Иметь чье-либо покровительство.

**Хин** حين *ис.* Вакыт, заман, чак. *Кара, ямьсез болытлар булдылар пәйда шул ук хиндә.* (Г. Тук.) — *сущ.* Время, пора; момент.

**Хина, хинаэ** حنا *ис.* Кына; үләннән ясалган кызыл буяу. — *сущ.* Хенна, хна; растительная краска красного цвета.

**Хинзир** خنزير *ис.* Дуңгыз, чучка. *Тәгали ит, дисәм сезгә әрәм сүз: Сәмагәр кинәле хинзиргә каршы.* (Г. Тук.) — *сущ.* Свинья.

**Хинсыйр** خنصر *ис.* Чәнчә бармак. — *сущ.* Мизинец.

**Хинта** حنط *ис.* Бодай. — *сущ.* Пшеница.

**Хирасәт I** حراثت *ис.* Игенчелек. *Хирасәт әһеленнән береңең киемен алып кидем.* (К. Нас.) — *сущ.* Земледелие; хлебопашество.

**Хирасәт II** حراست *ис.* Саклау, саклык. *Этең бик яхшы хирасәт кыладыр, өрмәке белән бөтен шәһәрне яңгыратадыр,— диде.* (К. Нас.) — *сущ.* Охрана, охранение

**Хираҗ (хәраҗ)** خراج *ис. тар.* Налог (кайбер ислам дәүләтләрендә мөселман булмаганнарга салына торган салым). *Хираҗ бирмәсәләр, елгалар ташып, хираҗ бирмәгәннәрне гарык итәр иде.* (К. Нас.) — *сущ. ист.* Подать, налагавшаяся на иноверцев в некоторых мусульманских странах.

**Хирз** حرز *ис.* 1) Төрле куркынычтан саклаучы урын. 2) Бөти, тылсым. — *сущ.* 1) Крепость, твердыня. 2) Талисман, амулет.

**Хирзе җан** حرزجان *гф. ст. дини* Җан саклый торган тылсым, бөти. *Итәрләр хирзе җан күмгәч сүзеңне.* (Дәрд.) — *ар.-п. сс.* Душеспасительный талисман.

**Хирка** خرقه *ис.* Дәрвишләрнең өс киеме. — *сущ.* Рубище, отрепье, обычная одежда дервишей.

**Хирка пуш** خرقه‌پوش *гф. ис.* Дәрвиш, хирка киюче. *Вакыт эчендә бер дәрвиш бар иде, хирка пуш ирде* (Мәхмуд бине Гали). — *ар.-п. сущ.* Дервиш.

**Хирман** حرمان *ис.* Мәхрумлек, мәхрум булу. *Дөньями, гокбами ектым яэс вә хирманылә бән.* (Г. Тук.) — *сущ.* Лишение, запрещение.

**Хирфәт** حرفت *ис.* Яшәү чыганагы булган һөнәр, кәсеп. — *сущ.* Источник существования, занятие, ремесло, профессия.

**Хирыс** * حرص *ис.* 1) Комагайлык, комсызлык. *Вә дәхи бере, нәфсеңең хирыслыгы сәбәпле, гайре кешегә изгүлек ирешмәкен эстәмәячәктер.* (К. Нас.) 2) Бик артык кызыгу, теләү. 3) Саклык. — *сущ.* 1) Алчность, жадность. 2) Сильное желание. 3) Осторожность.

**Хирәд** خرد *ф. ис.* Акыл, зиһен, хәтер. — *п. сущ.* Ум, разум, память.

**Хирәдмәнд** خردمند *ф. с.* Акыл иясе, акыллы. — *п. прил.* Умный, разумный; учёный, мудрец.

**Хирәф** حرف Хирфәт-нең *к.* — *мн.* от хирфәт.

**Хис** *, **хисс** حس *ис.* Хис, сизү, тою, сизем, тойгы. — *сущ.* Ощущение, восприятие; чувство.

**Хисаб** حساب *ис.* 1) Исәпләп чыгу. 2) Хисап, исәп. — *сущ.* 1) Исчисление. 2) Счёт, расчёт.

**Хисабият** حسابيات *ис.* Хисап гыйльме. *Мөхәммәт бине Фазилнең хисабияттан хәбәре юк иде.* (К. Нас.) — *сущ.* Арифметика.

**Хисабдан** حسابدان *гф. ис.* 1) Хисап гыйльмен белүче. 2) Счетовод, бухгалтер. — *ар.-п. сущ.* 1) Знающий арифметику. 2) Счетовод, бухгалтер.

**Хисабәт** حسابة *ис.* 1) Хисаплау, санау, хисапка алу. 2) Хисап бирү. — *сущ.* 1) Считание, счёт. 2) Отчитывание (перед кем-либо).

**Хисал** خصال *ис.* Хаслэт-нең *к.* *Хисалең җөмләсидин яхшыракый.* (Ут. Им.) — *сущ. мн.* от хаслэт.

**Хисар** حصار *ис.* Курган, ур, ныгытылган җир, ныгытма. — *сущ.* Укрепление, форт, ограждение, крепость.

**Хисас** حصاص *ис.* Өлешләп тарату, өлеш чыгару. — *сущ.* Раздача, делёж, выделение доли.

**Хисне хәсыйн** حصن حصين *ст.* Һөҗүмне кире кайтара торган ныгытма, янына барырга да мөмкин булмаган ны- — *сс.* Неприступная крепость.

гытма. *Бу өлфәтлек куәте бер хисне хәсыйндыр ки, аның белән залимнәрнең золымы дәфгы кылыныр.* (К. Нас.)

**Хисса** حصه *ис.* Өлеш, үзенә тиешле күләм, пай. *Бу тереклектә аз хисса белән калган зәгыйфьләргә каршы син үзеңнең йөрәгеңдә шәфкать, мәрхәмәт тоясың.* (Ф. Әмир.) — *сущ.* Часть, доля, пай; квота.

**Хиссагир** حصه گير *гф. ис.* Өлеш алучы. — *ар.-п. сущ.* Получающий свою долю.

**Хиссадар** حصه دار *гф. с.* Өлеш иясе, өлешләнүче, файдаланучы, өлешкә катнашучы. *Мәҗлестәге адәмнәр һәммәсе сүзеңнән хиссадар булсыннар.* (К. Нас.) — *ар.-п. прил.* Участник, пайщик, пользующийся своей долей (чего-нибудь).

**Хиссе батыйни** حس باطنى *ст.* Эчке сизү, күңел сизүе, эчке тойгы. — *сс.* Внутреннее чувство.

**Хиссе заһири** حس ظاهرى *ст.* Тышкы сизү, физик сизү, тышкы тойгы. — *сс.* Физическое ощущение.

**Хисси** حسى *с.* Сизү(гә), тою(га караган). — *прил.* Чувственный, ощутимый.

**Хиссият** حسيات Хисс-нең *к. Әлкадиринең ... гаклына, фәһменә истибдадлы хиссият мөдир.* (Ш. Баб.) — *мн.* от хисс.

**Хиссияте кальбия** حسيات قلبيه *ст.* Күңел хисләре. *Шигырьләрнең күбрәге хиссияте кальбиягә караган.* (М. Гаф.) — *сс.* Душевное восприятие, чувственность.

**Хиссәт** خست *ис.* 1) Саранлык, катылык. 2) Хәсислек, түбәнлек, әшәкелек. — *сущ.* 1) Скупость, скаредность. 2) Низость, подлость.

**Хисын** حصن *ис.* Крепость, курган, ныгытма. — *сущ.* Крепость, цитадель, твердыня.

**Хитаб** خطاب *м. III.* Эндәшү, сүзне берәүгә юнәлтеп сөйләү; сүз, мөрәҗәгать. — *м. III.* 1) Обращение (к кому-либо). 2) Речь.

**Хитабән** خطابًا *р.* Эндәшеп, сүзне юнәлтеп. — *н.* Говоря, обращаясь (кому-либо).

**Хитабәт** خطابت *м. III.* Ораторлык, сүз сөйләүчелек. — *м. III.* Ораторское искусство.

**Хитам I** ختام *ис.* Бетү, тәмам булу, азагына ирешү, соң, азак. *Кушмый юләр моназәрәгә хитам буларак...* (Ф. Әмир.) — *сущ.* Конец, заключение, окончание.

**Хитам II (хитем)** خطم، ختام *ис.* Нукта, тезген. — *сущ.* Недоуздок, повод.

**Хитан** ختان *ис.* Сөннәткә утырту, кистерү. — *сущ.* Обряд обрезания.

**Хифзыссыйхәт** حفظالصحت *гыйб.* Сәламәтлекне саклау һәм аның юллары. — *фр.* Сохранение здоровья, гигиена.

**Хифыз** حفظ *ис.* 1) Саклау, күзәтү. *Дус дус булмас, таки дусын өч турыда хифыз вә ригая кылмаса,— диде.* (К. Нас.) 2) Күңелдән белү, хәтердә тоту. — *сущ.* 1) Сохранение, хранение, защита. 2) Запоминание.

**Хиффәт** خفت *ис.* 1) Җиңеллек. 2) Акыл җиңеллеге. *Ул, кеше сүзен бетермәс борын, сүз башлар, бу аның хиффәте гакылына вә мөрәввәтенең юклыгына дәлаләт кылыр.* (К. Нас.) 3) Җитезлек. — *сущ.* 1) Лёгкость, легковесность. 2) Легкомыслие. 3) Живость, проворство.

**Хиш** خويش *ф. ис.* 1. Якын, туган, кардәш. *Күреп хиш вә тәбарым дусты ярым.* (Ут. Им.) 2. Үз, үзенеке. — *п. сущ.* 1. Близкий, родной, родственник. 2. Свой, собственный.

**Хишем** خشم *ф. ис.* Ачу, ачулану. — *п. сущ.* Гнев, ярость.

**Хишман** خشمان *ф. ис.* Ачулы кеше, ачучан. — *п. сущ.* Сердитый, гневливый.

**Хишемняк** خشمناك *ф. с.* Ачулы, бик ачуланган, ачуы кабарган, ачуы чыккан. *Падишазадә бу сүзне ишетте, хишемняк булып ... вәзирне чакырды* (Мәҗмәгыл хикәять). — *п. прил.* Гневный, разгневанный, рассерженный, разъярённый.

**Хишт** خشت *ф. ис.* Кирпеч. *Бу төрбәнең кайбер хиштләре йирә төшмеш булса да, мәнзарәсе гүзәлдер.* (Ш. ж.) — *п. сущ.* Кирпич.

**Хиям** خيام Хәймә-нең *к.* — *мн.* от хәймә.

**Хиянәт*** خيانت *ис.* Алдау, сатылу, хыянәт итү, хаинлек. — *сущ.* Предательство, вероломство, измена, коварство.

**Хиянәткяр** خيانتكار *гф. ис.* Хыянәт эшләүче, хыянәтче, җансатар. — *ар.-п. сущ.* Изменник, предатель.

**Хияр** خيار *ис.* 1. Кыяр. 2. Ике нәрсәдән яхшысын сайлау. — *сущ.* 1. Огурец. 2. Отбор, самое лучшее.

**Хиҗаб** حجاب *ис.* 1) Пәрдә, йөз өрткеч. *Зөһрә кыз ап-ачык хиҗабсыз күренә иде.* (М. Гаф.) 2) Оялу, тартыну. 3) Чаршау. — *сущ.* 2) Покрывало. 2) Стыдливость, скромность. 3) Занавес, ширма.

**Хиҗаз** حجاز *ис.* Гарәбстанның көнбатышында Кызыл диңгез буендагы бер өлкә (башкаласы Мәккә шәһәре). — *сущ.* Хиджаз — область в Саудовской Аравии.

**Хиҗаләт** حجالت *ис. кара:* хәҗаләт. *Сезгә бурычлы булганлыктан, каршыгызга килергә хиҗаләт кыйлалар, — диде.* (К. Нас.) — *сущ. см.* Хәҗаләт.

**Хиҗарә** حجاره Хәҗәр-нең *к.* — *мн.* от хәҗәр.

**Хой** خوى *ф. ис.* Табигать, холык. *Мин сине хуш хой итим.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Характер, нрав, привычка, наклонность.

**Хода*** خدا *ф. ис.* Алла, тәңре, ходай. — *п. сущ.* Бог, господь.

**Ходавәнд, ходавәндә** خداوند،خداونده *кара:* хода. — *см.* Хода.

**Ходаи** خدائى *ф. с.* 1) Аллалык, ходалык. 2) Алла(га бәйләнешле). 3) Алла бәндәсе (юаш, мескен кеше). — *п. прил.* 1) Божественность. 2) Божественный. 3) Божий человек (смиренный, убогий).

**Ходбин** خودبين *ф. ис.* Үз-үзен өстен куючы, үзен сөюче. *Ходбин вә гоҗеп ниясе булган риялыларга тәгъриз мәкамендә әйтелер.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Эгоист, себялюбец.

**Ходга** خدعه *ис.* Алдау, хәйлә. — *сущ.* Обман, трюк.

**Ходдам** خدام Хадим-нең *к.* — *мн.* от хадим.

**Ходфруш** خود فروش *ф. ис.* 1) Үз-үзен мактаучы, мактанчык. 2) Сатлык. *Ходфруш булган риякярларга тәгъриз.* (К. Нас.) — *п. сущ.* 1) Хвастливый, тщеславный. 2) Продажный.

**Хозрәт** خضرت *ис.* 2) Яшеллек, үсемлек. 2) Яшел төс. — *сущ.* 1) Зелень, растительность. 2) Зелёный цвет.

**Хозугъ** خضوع *ис.* 1) Түбәнчелек, буйсыну. 2) Мөстәкыйль түгеллек, бәйлелек. — *сущ.* 1) Покорность, смирение, подчинение. 2) Зависимость.

**Хозузат** حضوظات *ис. к.* 1) Өлешләр. 2) Күңелгә ошаган нәрсәләр, тәм табулар, рәхәтлек, ләззәт. — *сущ. мн.* 1) Доля, удел, счастье, удача. 2) Удовольствие, радость, наслаждение, блаженство.

**Хозур*** حضور *ис.* 1) Күз алды, ал, ян. *Дәгъва кылган хатынны алып солтан хозурына китте.* (К. Нас.) 2) Килү. 3) Рәхәт, кәеф, күңеллелек, шатлык, күңел ачу. *Бик хозур! Рәт-рәт тора гаскәр кеби чыршы, нарат.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Присутствие. 2) Приход, появление. 3) Развлечение; веселье, забава, удовольствие. 4) Весело.

**Хозыр (хизыр)** خضر *ис.* Исеме бар, гәүдәсе юк бер пигамбәр исеме (дини экиятләрдә ул хәзерге көндә дә исән, авырлыкка төшүчеләргә ярдәм итүчән, кешеләрне сынау өчен ак сакаллы карт кыяфәтенә кергән образ итеп бирелә). *Булса бир, булмас исә, җайлап сөйлә булмаслыгын,— сизми калма ак сакаллы карт Хозыр Ильяслыгын!* (Г. Тук.) — *сущ.* Хозыр (Хизыр) — собственное имя мифического пророка (в религиозных сказках он появляется перед людьми в образе белобородого старика).

**Хокук*** حقوق 1) Хак-ның *к.* 2) Юридик хокук, политик хокук. — 1) *мн.* от хак. 2) Юридическое, политическое право.

**Хокукшинас** حقوقشناس *ст.* Юрист. *Ул әхлякың фәкыйрьлек киеме астында мәстүр имеш, хокукшинаслык итмәдең димәктер.* (К. Нас.) — *сс.* Юрист, правовед.

**Холд** خلد *ис.* 1) Дәвамлылык, мәңгелек. 2) Җәннәт. *Йөзендин гизләнеп торыр холдара хур.* (Хорәз.) — *сущ.* 1) Вечность, бессмертие. 2) Рай.

**Холкум** حلقوم *ис.* Бугаз; үңәч, жен. — *сущ.* Горло, пищевод.

**Холык*** خلق *ис.* 1) Кешенең табигый үзенчәлеге, кешенең табигате. 2) Кәеф, рухи хәл. — *сущ.* 1) Характер, натура, нрав. 2) Настроение, расположение духа.

**Холкан** خلقاً *р.* Холкы буенча. — *н.* Характером, по характеру.

**Холәфа** خلفا Хәлифә-нең *к.* — *мн.* от хәлифә.

**Холүл** حلول *ис.* 1) Керү. 2) Килеп житү (вакыт). — *сущ.* 1) Вход, вхождение. 2) Наступление (времени); прибытие.

**Холүс** خلوص *ис.* *кара:* хөлус. — *сущ.* *см.* Хөлус.

**Холүсан** خلوصا *р.* *кара:* хөлусан. — *н.* *см.* Хөлусан.

**Хомар** خمار *ис.* Исереп айныганнан соң баш авырту, макмыр. — *сущ.* Болезненное состояние после выпивки, похмелье.

**Хомаси** خماسى *с.* 1) Бишле. 2) *грам.* Биш хәрефтән тора торган сүз. — *прил.* 1) Пятерной. 2) *грам.* Слово, состоящее из пяти букв.

**Хомес** خمس *сан* Биштән бер. — *ч.* Одна пятая.

**Хомрә, хомрәт** حمره،حمرة *ис.* Кызыллык. — *сущ.* Краснота.

**Хомур** خمور Хәмер-нең *к.* — *мн.* от хәмер.

**Хомык** حمق *ис.* Ахмаклык, акылсызлык, тинтәклек, сантыйлык. — *сущ.* Глупость, безрассудство.

**Хомуд** خمود *ис.* 1) Басылу, тынычлану. 2) Утның ялкыны басылу. — *сущ.* 1) Успокоение. 2) Затихание, угасание (огня).

**Хонса* (хонәса)** خنثى *ис.* Кыз-тәкә (ике җенесле, ирлек һәм хатынлык билгеләре булган кеше). — *сущ.* Гермафродит.

**Хорафат*** خرافات *ис. к.* 1) Юк-барга ышану; искелек калдыклары. 2) Нигезсез әкиятләр, легендалар, телдән телгә күчеп йөри торган ялганнар. — *сущ. мн.* 1) Суеверие, предрассудок. 2) Сказка, басня, легенды, небылицы.

**Хордә** خرده *ф. ис.* Вак нәрсә, кечкенә нәрсә, кисәк, ватык. — *п. сущ.* Мелочь, крошки, обломки.

**Хордәбин** خردهبين *ф. ис.* 1) Микроскоп. *Хордәбин аркылы карап та көч белән күренә торган хайваннар бар.* (К. Нас.) 2) Вакчыл; нечкәләүче, җентекләүче, төпченүче. — *п. сущ.* 1) Микроскоп. 2) Мелочный; разборчивый, педантичный.

**Хоркат** حرقة *ис.* 1) Янгын, яну. 2) Кызу, ачулану. — *сущ.* 1) Горение, жар. 2) Сильный гнев, досада.

**Хортум** خرطوم *ис.* Фил борыны. — *сущ.* Хобот.

**Хорурәт** حرورت *ис.* 1) Эсселек, кызулык. 2) Җылылык бирәмлеге, калория. — *сущ.* 1) Жара, высокая температура, зной. 2) Единица измерения количества тепла, калория.

**Хорус (хоруз)** خروس،خروز *ф. ис.* Әтәч. — *п. сущ.* Петух.

**Хоруф, хоруфат** حروف، حروفات Хәреф -нең *к.* — *мн.* от хәреф.

**Хоруфы шәмсия** حروف شمسيه *ст.* Гарәб әлифбасында: ت، ث، د، ذ، ر، ز، س، ش، ص، ض، ط، ظ، ل، ن (т, с, д, з, р, ш, л, н) хәрефләре; болар алдында килгән „әл“ артикленең „л“се йотыла. Болардан башка хәрефләр хоруфы камәрия дип атала. Алар алдында килгән „әл“ артикле йотылмый. — *сс.* „Солнечные буквы“ арабского алфавита, которые ассимилируют „л“ артикля. Остальные буквы арабского алфавита называются лунными, которые „л“ артикля не ассимилируют.

**Хоруфы мөнфәсыйлә** حروف منفصله *ст.* Үзеннән соңгы хәрефләр белән тоташмый торган хәрефләр. — *сс.* Буквы, которые на письме не соединяются с последующими буквами.

**Хоруфы һиҗа** حروف هجا *ст.* Әлифба, азбука. — *сс.* Азбука, арабский алфавит.

**Хоруж** خروج *м. I.* Эчтән тышка таба чыгу. *Өеннән хоружы бәгъдендә...* (З. Биг.) — *м. I.* Выход, выхождение.

**Хоршид** خورشيد *ф. ис.* Кояш, көн. — *п. сущ.* Солнце, день.

**Хосия** خصيه *ис. анат.* Йомырка. — *сущ. анат.* Яичко.

**Хосран** خسران *ис.* 1) Үкенеч, үкенечле. 2) Югалту, зыянга очрау. 3) Саташу; адашу. *Үтте гомерем, барчасы хосран икәндер белмәдем.* (Һ. Сал.) — *сущ.* 1) Раскаяние. 2) Потеря, повреждение. 3) Бред; заблуждение.

**Хосрау** خسرو *ф. ис.* 1) Патша, хан, солтан. 2) Иран шаһларының титулы. — *п. сущ.* 1) Государь, повелитель, султан. 2) Титул персидского царя.

**Хосул** حصول *м. I.* Керем, файда, кулга керү; казаныш. *Сүзлә файда хосулә кәлмәз, эш кирәк.* (М. Ак.) — *м. I.* Доход, польза, достижение, получение, приобретение.

**Хосум** خصوم *ис. к.* Дошманлашучылар, талашучылар, низаглашучы яклар. — *сущ. мн.* Враждебная сторона, противники, оппозиционеры.

**Хосумәт** خصومت *ис.* Дошманлык, талашу. *Берәү берәүгә: „Мине хосумәткә өйрәтсәнә", — диде. Ул кеше әйтте: „Юкны дәгъва, бирәчәкне инкяр кыл, хосумәткә өйрәнерсең, — диде.* (К. Нас.) — *сущ.* Вражда, тяжба, ссора.

**Хосус** خصوص *ис.* 1) Әйбердә булган үзенчәлек. 2) Очрак, мөнәсәбәт. *Хәзрәт бу хосуста Җиһанша берлә киңәште.* (З. Һад.) — *сущ.* 1) Особенность, частность. 2) Отношение, связь.

**Хосусый*** خصوصى *с.* 1) Аерым, үзенә генә караган, бер нәрсәгә генә бәйләнешле; махсус. 2) Шәхси. — *прил.* 1) Особенный, специальный. 2) Частный, личный.

**Хосусыять** خصوصيت *ис.* Үзенчәлелек, аерымлылык. — *сущ.* Частность, особенность.

**Хосусән*** خصوصاً *р.* Бигрәк тә, аеруча. *Хосусән һич ярамас ушбу заман.* (М. Гаф.) — *н.* В особенности, особенно.

**Хотабаэ** خطباء Хатыйб-ның *к.* — *мн.* от хатыйб.

**Хотам** حطام *ис.* 1) Кисәк, ватык. 2) Калдык. 3) Фани дөнья малы. *Гараз шулдыр, җәмгы иткәй хотами.* (Ут. Им.) — *сущ.* 1) Осколки, обломки. 2) Остатки. 3) Бренное имущество.

**Хотбә** خطبه *ис.* 1) Речь, нотык, сөйләнгән сүз. *Җирсезлек-динсезлек җөмләсе белән хотбәсен тәмам итте.* (Г. Ибр.) 2) Вәгазь. — *сущ.* 1) Речь. 2) Проповедь.

**Хотур** خطور *м. I.* Хэтергэ килү, искэ төшү, зиһенгэ китерү. — *м. I.* Приходить в голову, на ум.

**Хотут** خطوط Хат -ның *к.* — *мн.* от хат.

**Хофия** خفيه *ис.* 1) Яшеренлек. 2) Серлелек. — *сущ.* 1) Скрытность. 2) Секретность.

**Хофиятэн** خفيةً *р.* Яшерен рэвештэ. *Итмэде тээсир, чалыштым хофиятэн, җэһрэн дэ бэн.* (Г. Тук). — *н.* Скрытно, тайно, секретно.

**Хоффаз** حفاظ Хафиз-ның *к.* — *мн.* от хафиз.

**Хоффаш** خفاش *ис.* Ярканат. *Нигэ булды зыя сөйгэн азат баш монафикълар караңгысында хоффаш.* (Г. Тук.) — *сущ.* Летучая мышь.

**Хофэр** حفر Хофрэ -нең *к.* — *мн.* от хофрэ.

**Хофрэ** حفره *ис.* Казылган чокыр. — *сущ.* Яма, рытвина.

**Хошек** خشك *ф. с.* 1) Коры, кипкэн, уңыш бирми торган. *Мэхэббэт багына хошек сале иреште.* (Ут. Им.) 2) Каткан, туңган. 3) Кырыс, каты, тупас (характер). — *прил.* 1) Сухой, высохший, бесплодный, неурожайный. 2) Замёрзший. 3) Суровый, жёсткий.

**Хошнуд** خشنود *ф. с.* Разый, шат, канэгать, риза. *Заманның дуслыгына мин хошнуд түгел идем, елар идем, лэкин үтеп киткэч, фиракы өчен еладым.* (К. Нас.) — *п. прил.* Довольный, радостный, весёлый, удовлетворённый.

**Хошуг** خشوع *ис.* Түбэнчелек, күнел, белэн түбэнчелек итү. — *сущ.* Покорность, смирение, почтительность, благоговение.

**Хошунэт** خشونت *ис.* Катылык, кансызлык, тупаслык. — *сущ.* Грубость, жестокость.

**Хоют** خيوط Хэйт-ның *к.* — *мн.* от хэйт.

**Хожэстэ** خجسته *ф. с.* Бэхетле, уңышлы, имин, шат. *Кеше таш орса башэ и хожэстэ* (Аллаһъяр). — *п. прил.* Счастливый, благополучный благословенный.

**Хруф** حروف *кара:* хоруф. — *см.* Хоруф.

**Хруфат** حروفات *кара:* хоруфат. — *см.* Хоруфат.

**Хруфһижа** حروفهجا *кара:* хоруфы һижа. — *см.* Хоруфы һижа.

**Хуб*** خوب *ф. с.* Гүзэл, яхшы; күркэм. *Хаклы дип, безнең телэкне хуб табып, вэгъдэ биргэн иде тэңре күптэн үк.* (Ш. Баб.) — *п. прил.* Хороший, добрый; красивый.

**Хубан** خوبان Хуб-ның *к. Фарси шагыйрьләренең болгар хубаннары дия мәдех әйләмеш кызлары ушбу кәнизәкләрдер.* (Г. Габ.) — *мн.* от хуб.

**Хубру** خوبرو *ф. с.* Гүзәл йөзле, матур, чибәр. — *п. прил.* Красивый (лицом).

**Хукь** خوك *ф. ис.* Дуңгыз. *Сыйфаты охшар аның нәҗес хука.* (М. Кол.) — *п. сущ.* Свинья.

**Хун** خون *ф. ис.* Кан. — *сущ.* Кровь.

**Хунаб, хунабә** خوناب *ф. ис.* Канлы су, күз яше. *Таләп юлына кердем янарым юк, ничә хунабә эчсәм канарым юк.* (Ш. ж.) — *п. сущ. букв.* Кровавая вода, т. е. слёзы.

**Хунриз** خونريز *ф. ис.* Кан коючы, кеше үтерүче. — *п. сущ.* 1) Проливающий кровь. 2) Убийца.

**Хунхор** خونخور *ф. ис.* 1) Канечкеч, кан эчүче. 2) Изүче, җәберләүче. — *п. сущ.* 1) Кровожадный, лютый. 2) Кровопийца, тиран.

**Хур (хар) I** خوار *ф. с.* 1) Ашаучы. *Риба хур* — процент ашаучы. 2) Хур, кадерсез, түбән, игътибарсыз. — *п. прил.* 1) Живущий ростовщичеством. 2) Презренный, низкий, ничтожный.

**Хур II** حور *ис.* 1) Кара күзле, матур күзле гүзәл кыз. 2) Җәннәт кызы, хур кызы (ислам дине буенча җәннәткә кергән кешеләргә вәгъдә ителгән кыз). — *сущ.* 1) Черноглазая красавица. 2) Гурия, райская дева (обещанная по исламу тем, кто попадёт в рай).

**Хури** حورى *ис.* 1) Җәннәт кызы. *Болар, әлбәттә, җир хатыны булмас, болар я пәриләр, я хуриләр булыр.* (Г. Ибр.) 2) Гүзәл кыз. — *сущ.* 1) Гурия, райская дева. 2) Красавица.

**Хурелгаен** حورالعين *гыйб.* Кара күзле, матур күзле. *Күбәләк күк хурылгаеннар хөрләшеп, йөрделәр абзаңны мактап ерлашып.* (Ш. Баб.) — *фр.* Черноглазая, черноокая.

**Хут** حوت *ис.* 1) Диңгездәге бик зур балык. 2) Кит балыгы. 3) Зодиак тамгалары буенча 22 февральдән 22 нче март арасында була торган вакыт. — *сущ.* 1) Большая рыба. 2) Кит. 3) По знаку зодиака время от 22 февраля до 22 марта.

**Хуш*** **(хош)** خوش *ф. с.* 1) Гүзәл, яхшы, күркәм, шат. *Тау башында дөп-дөп алкышлар куба, хуш киләсез... мәрхаба! Ура... ура!..* (Ш. Баб.) 2) Сау бул. — *п. прил.* 1) Красивый, приятный, весёлый, радостный, милый. 2) Будь здоров.

**Хушаб** خوشاب *ф. ис.* 1) Татлы су. 2) Җимеш суы, компот. — *п. сущ.* 1) Сладкая вода. 2) Компот.

**Хушамәд** خوش آمد *ф. ст.* 1) Хуш килдегез. *Вакытында хушамәд орып йөргән иптәшләре, хатыны да ташлап киткән иде.* (Ш. ж.) 2) Мактау сүзе. — *п. сс.* 1) Добро пожаловать. 2) Лесть, комплимент.

**Хушбуй* (хушбу)** خوشبوی *ф. с.* Яхшы (хуш) исле, ислемай. — *п. прил.* Ароматный, благоуханный, благовонный, духи.

**Хушдил** خوشدل *ф. с.* Яхшы күңелле, шат. — *п. прил.* Весёлый, довольный, радостный.

**Хушмәзә** خوشمزه *ф. с.* Татлы, тәмле, ләззәтле. — *п. прил.* Сладкий, вкусный.

**Хушнуд** خوشنود *кара:* хошнуд. — *см.* Хошнуд.

**Хушхой** خوش خوی *ф. с.* Яхшы табигатьле, гүзәл холыклы. *Бән сәне хушхой итим.* (Г. Тук.) — *п. прил.* Добронравный, с хорошим характером, весёлого нрава.

**Хуҗа** خواجه *кара:* хаҗә. — *см.* Хаҗә.

**Хый** خى *ис.* Гарәп әлифбасында җиденче хәреф; калын, нокталы „х" хәрефенең татарча исеме. — *сущ.* Татаризованное название седьмой буквы арабского алфавита (х с точкой).

**Хыял*** خيال *ис.* 1) Хыял, буш уй, нигезсез омтылыш. *Хыял — безнең өчен чит бер нәрсә, һәрбер теләк якын киләчәк.* (Һ. Так.) 2) Шәүлә, өрәк. — *сущ.* 1) Воображение, фантазия, химера, мечта, утопия. 2) Тень, отражение; призрак, привидение.

**Хыяле хам** خيال خام *ст.* Буш хыял. *Хыяле хамга бирелеп үзен онытыр.* (Г. Фәез.) — *сс.* Пустая фантазия.

**Хыялый*** خيالى *ис.* 1) Хыял(га бәйләнешле). 2) Һәрвакыт хыял белән шөгыльләнүче. 3) Күп уй, сагыш сәбәпле акылдан язган кеше. — *прил.* 1) Фантастический, воображаемый. 2) Фантазёр, утопист. 3) Помешанный, сумасшедший.

**Хыялят** خيالات Хыял-ның *к. Тәгърифе мөмкин булмаган хыялят мәмлүә иде.* (К. Нас.) — *мн.* от хыял.

**Хәб** حب *ис.* 1) Орлык, төш. 2) Пилюля. — *сущ.* 1) Зёрна, семена. 2) Пилюли.

**Хәбаис** خبائث Хәбисә-нең *к. Өммелхәбаис* — пычраклыклар, бозыклыклар анасы (күбрәк аракы турында әйтелә.) — *мн.* от хәбисә. *Өммелхәбаис — букв.* „Мать нечистоплотности, грязи", в значении верх нечистоплотности, разврата (чаще всего употребляется в разговоре о водке).

**Хәбасәт** خباثت *ис.* Пычраклык, бозыклык, шакшылык. *Үзенең табигатендә булган хәбасәт вә хыянәт икътизасынча вәгъдәсенә хилаф итеп.* (К. Нас.) — *сущ.* Порочность, нечистоплотность, распущенность.

**Хәбб, хәббә** حب ، حبه *ис.* 1) Орлык, төш. *Әһле әүлады күп фәкыйрь адәм иде, мәдаре мөгашыннан бер хәббәгә малик түгел иде.* (К. Нас.) 2) Бик кечкенә кисәк. — *сущ.* 1) Семя, зерно. 2) Малость, немножко.

**Хәббаз** خباز *ис.* 1) Икмәк пешерүче. 2) Икмәк сатучы. *Хәббаз илә сакыйны антлаштырды.* (К. Гал.) — *сущ.* 1) Пекарь. 2) Булочник.

**Хәбел** حبل *ис.* 1) Бау, аркан, канат. 2) Элемтә. — *сущ.* 1) Верёвка, канат. 2) Связь.

**Хәбелелмәдид** حبل المديد *ст.* Озын бау. *Бу журналның намы „Гасрелҗәдиддер“. Ябышканнарга һәм хәбелелмәдиддер.* (Г. Тук.) — *сс.* Длинная верёвка, нить.

**Хәбелелмәтин** حبل المتين *ст.* Ныклы, ышанычлы җеп; элемтә, ныклы бәйләнеш (сәламәтлек белән.) — *сс.* Прочная верёвка; связь; крепкие узы.

**Хәбес, хибес** حبس *ис.* Кулга алу, бикләп тоту, ябу. *Хәбес, төрмә, богаулар һәм богаулар; кылыч, мылтык, револьверлы кагаулар* (тилгәннәр). (Н. Дум.) — *сущ.* Арест, заключение, заточение.

**Хәбесханә** حبسخانه *гф. ис.* Төрмә, зиндан. — *ар.-п. сущ.* Тюрьма, место заключения.

**Хәбиб** حبيب *с.* 1) Сөекле, сөелгән. 2) Дус. — *прил.* 1) Любимый, возлюбленный. 2) Приятель.

**Хәбир** خبير *с.* Белекле, белүче, хәбәрдар. — *прил.* Сведущий; знающий.

**Хәбис** خبيث *с.* Пычрак, шакшы, начар, эшәке. *Тау башына җыелышып барсы да, килделәр иблис хәбиснең каршына.* (Ш. Баб.) — *прил.* Дурной, скверный, мерзкий.

**Хәбисә** خبيثه Хәбис-нең *мнс.* — *жен.* от хәбис.

**Хәбәр*** خبر *ис.* 1) Бер нәрсә турында башка кешеләргә белдерү. 2) Сөйләнгән, ишетелгән сүз. 3) *грам.* Җөмләдә баш кисәкләрнең икенчесе. — *сущ.* 1) Известие, весть, сообщение. 2) Новость, слух. 3) *грам.* Сказуемое.

**Хәбәрдар*** خبردار *гф. с.* Белүче, берәр эш (вакыйга) турында ишеткән кеше. *Качан бер көнне Мәҗнүн дил-* — *ар.-п. прил.* Извещённый, осведомлённый, знающий.

*фикяр ителде фәүте Ләйләдән хәбәрдар.* (Дәрд.)

**Хәбәш** حبش *ис.* Хәбәшстан (Абиссиния, Эфиопия). — *сущ.* Эфиопия, Абиссиния.

**Хәбәши** حبشی *ис.* Хәбәшстан (Эфиопия) кешесе. — *сущ.* Эфиоп, абиссинец

**Хәвадис** حوادث Хадисә-нең *к.* *Бөтен мәмләкәтемездә вакыйг булган бәла вә хәвадисне бәян кылып, хәлифәдән барча халыкка ихсан эстәр идем, — диде.* (К. Нас.) — *мн.* от хадисә.

**Хәваиҗ** حوائج Хаҗәт-нең *к.* — *мн.* от хаҗәт.

**Хәвали** حوالی *ис.* 1) Тирә-як, әйләнә-тирә. 2) Чама белән. — *сущ.* 1) Окрестности, округа. 2) Около, приблизительно.

**Хәвалә** حواله *ис.* Бер эшне икенче берәүгә йөкләү, тапшыру. *...Һәрбер эшне хәвалә кыйлган вакытымда хыянәт итмәскә гаһед кылдырырмын.* (К. Нас.) — *сущ.* Поручение, передача (на чью-либо ответственность).

**Хәванин** خوانين *ис. к.* Ханнар. *Сәлятыйн вә хәванин әһле дөнья.* (Ут. Им.) — *сущ. мн.* Ханы.

**Хәвари** حواری *ис.* Ярдәмче, булышучы. — *сущ.* Помогающий, помощник.

**Хәварикъ** خوارق *ис. к.* Гадәттән тыш эшләр. — *сущ. мн.* Необычное явление, (что-либо) необычное, чудесное, чудо.

**Хәвариюн** حواريون *ис. к. дини* Хәварилар (Гайса пигамбәрнең унике ярдәмчесе.) — *сущ. мн. рел.* 12 апостолов (учеников Иисуса).

**Хәвариҗ** خوارج 1) Хариҗи-нең *к.* 2) Аерылып чыгучылар. 3) Сепаратистлар (аерылып торучылар). — 1) *мн.* от хариҗи. 2) Еретики, раскольники. 3) Сепаратисты.

**Хәвас I** خواص *ис.* 1) Хасс-ның *к.* *Телебезнең хәвасыннандыр ки, бер шигырьне ун-унбиш төрле итеп тәрәннем кылмак мөмкин.* (К. Нас.) 2) Аксөякләр, аристократлар, югары сыйныф. *Тубчыбашов атты элек ташларга аш, ашларга таш. Булды баш, күз өстендә каш, хаслар өстендә хәвас.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) *мн.* от хасс. 2) Аристократия, знать, „голубая кровь“.

**Хәвас II** حواس Хис-нең *к.* — *мн.* от хис.

**Хәвасе хәмсә** حواس خمسه *ст.* Биш тойгы (күрү, ишетү, ис сизү, тәм тату, тотып белү). — *сс.* Пять органов чувств (зрение, слух, осязание, обоняние, вкус).

**Хәватин** حواتين *ис.* Хатыннар. *Коры тел белән ярамаз, хәватиннар кеби гайрәт кылмаенча...* (З. Биг.) — *сущ.* Женщины.

**Хәватир** خواطر Хатир-ның *к.* — *мн.* от хатир.

**Хәваши** حواشى *ис.* Хашия-нең *к.* — *сущ. мн.* от хашия.

**Хәваһиш** حواهيش *кара:* хаһиш. — *см.* Хаһиш.

**Хәваһәр** خواهر *кара:* хаһәр. — *см.* Хаһәр.

**Хәвел** حول *ис.* 1) Көч, кодрәт. 2) Бер хәлдән икенче хәлгә күчү. 3) Тирә-юнь. 4) Ел. — *сущ.* 1) Сила, могущество. 2) Перемена, изменение. 3) Вокруг, около. 4) Год.

**Хәвыз** حوض *ис.* Ясалма күл, су жыяр өчен ясалган чокыр. *Түгәрәк бер хәвыз, буе-аркылысы унбиш зираг иде.* (К. Нас.) — *сущ.* Водоём, бассейн.

**Хәвеф*** خوف *кара:* хәүф. — *см.* Хәүф.

**Хәд, хәдд I** حد *ис.* 1) Чыбык белән сугу жәзасы. *Хәмер эчкәне өчен хәдкә мөстәхикъ иде.* (К. Нас.) 2) Чик, кырый. 3) Үтмәскә тиешле нокта, чик. *Талавыңда белә алмыйсың хәд, чикләрне.* (Г. Тук.) 4) Кешенең дәрәжәсе, кадере, тоткан урыны. — *сущ.* 1) Избиение прутьями — мера наказания. 2) Предел, край, конец. 3) Граница, рубеж. 4) Достоинство, заслуга, занимаемое положение.

**Хәд II** خد *ис.* Яңак. — *сущ.* Щека.

**Хәдаикъ** حدائق Хәдика-нең *к.* — *мн.* от хәдика.

**Хәддаг** خداع *ис. кара:* хөддаг. — *сущ. см.* Хөддаг.

**Хәддад** حداد *ис.* Тимерче. — *сущ.* Кузнец.

**Хәдде белуг** حدبلوغ *ст.* Үсеп житү (үсеп өлгерү) чиге, балигъ булу. *Бәгъзе бер кешенең хәдде белугга ирешү белән тавышы юанаеп китә* (Г. Газиз). — *сс.* Предел возмужалости.

**Хәдд зат** حدذات *ст.* Яратылышы, заты, табигате. — *сс.* Происхождение; природное свойство.

**Хәдига** خديعه *ис.* Алдашу, хәйлә, хәйләкәрлек. — *сущ.* Обман, хитрость, плутовство.

**Хәдид** حديد *ис.* **1.** Тимер. **2.** Кискен, үткен; ачучан, кабынучан, кызучан. — *сущ.* **1.** Железо. **2.** Острый; вспыльчивый, горячий.

**Хәдиди** حديدى *с.* Тимердән ясалган. — *прил.* Железный.

**Хәдидә** حديده *ис.* Тимер кисәге, тимер корал. — *сущ.* Железное изделие, кусок железа.

**Хәдика** حديقه *ис.* Өйтүр бакча, агач бакчасы. — *сущ.* Сад, палисадник.

**Хәдис** حديث *ис.* 1) Имеш Мөхәммәт пигамбәр сөйләгән сүзләр, сөйләмнәр. 2) Сөйләшү, әңгәмә. 3) Яңа чыккан, яңа барлыкка килгән. — *сущ.* 1) Рассказ, предание, хадис (слова, приписываемые пророку Мухаммеду). 2) Разговор, беседа. 3) Новый, новейший, недавний.

**Хәдәка** حدقه *ис.* Күз карасы, бәбәк. — *сущ.* Зрачок.

**Хәдәмә** خدمه Хадим-нең *к.* — *мн.* от хадим.

**Хәдәс** حدث *ис.* 1) Яңалык, вакыйга. 2) Тизәк. — *сущ.* 1) Событие, новость. 2) Экскременты (испражнения).

**Хәез** حيض *ис.* Күрем. *Думага хәзрәтләр бармасын, анда хәез турында фәтва сорамаслар, дип сөйләде.* (Г. Ибр.) — *сущ.* Менструация.

**Әфшан** افشان *ф. с.* Чәчүче, сибүче. *Чәмән фәррашы, ягъни таң нәсиме, гөл әфшанлык кылыр бөстан эчендә.* (Хорәз.) — Распространяющий.

**Әх** اخ *ис.* Бертуган ир кардәш (ага, эне). — *сущ.* Брат.

**Әхадис** احادث Хәдис-нең *к.* — *мн.* от хәдис.

**Әхак** احق *с.* Хаклырак. *Хокукка мөстәхикъ, бәлки әхаксыз.* (Г. Тук.) — *пр. ст.* от хак — право, правый.

**Әхас** احص *с.* 1) Иң хас, иң үзенчәлекле, хасрак. 2) Берәр нәрсәгә караган, хасланган, аерып алынган. — *пр. ст.* от хас — 1) Особый, особенный, специальный. 2) Касающийся (чего-либо).

**Әхбаб** احباب Хәбиб-нең *к.* — *мн.* от хәбиб.

**Әхбар** اخبار Хәбәр-нең *к.* — *мн.* от хәбәр.

**Әхбаре дахилия** — эчке хәбәрләр. — Сообщения о положении внутри страны.

**Әхбаре харижия** — чит ил хәбәрләре. — Сообщения из-за границы.

**Әхбаре сәхихә** — дөрес хәбәрләр. — Правильные новости.

**Әхбаре садыйк** — чын, дөрес хәбәрләр. *Вә һәр әхбаре садыйк, гайре кязиб.* (Г. Тук.) — Достоверные сообщения.

**Әхбаре җәдидә** — яңа хәбәрләр. — Новости, новые сообщения.

**Әхвале рухия** احوال روحيه *ст.* Психик хәлләр, эчке кичерешләр, рухи торышлар. — *сс.* Моральное, психическое состояние.

**Әхвале сәясия** احوال سیاسیه *ст.* Политик хәлләр. — *сс.* Политическое положение.

**Әхваль** احوال Халь-нең *к.* — *мн.* от халь.

**Әхвалят** احوالات Әхваль-нең *к.* — *мн.* от әхваль.

**Әхез** اخذ *м. I.* Алу, кулга алу, кабул итү. *Дөньяда гыйлем күптер, яхшырагын, файдалырагын әхез кыйл, диде.* (К. Нас.) — *м. I.* Взятие, получение, принятие.

**Әхзан** احزان Хөзен-нең *к.* *Дулу сәбгы сәмават һәп сәнең атәшле әхзаның.* (Г. Тук.) — *мн.* от хөзен.

**Әхзар** احضر *с.* Яшел. — *прил.* Зелёный.

**Әхзәм** احزم *с.* Иң акыллы, иң төпле, алдан күреп эш итүче. *Гакыйл әхзәм бәлане төшмәстән борын тоеп дәфгынә һиммәт сарыф кылыр.* (К. Нас.) — *пр. ст. прил.* Самый благоразумный, предусмотрительный.

**Әхи** اخی *ис.* Кардәшем, энем, абыем. — *сущ.* Мой брат.

**Әхибба** احبا Хәбиб-нең *к.* *Хәбәр вирсен бераз хәле әхиббадан вә әгъдаэдан.* (Г. Тук.). — *мн.* от хәбиб.

**Әхилля** اخلا Хәлил I-нең *к.* — *мн.* от хәлил I.

**Әхир** اخیر *ис.* Соң, актык, азак, ахыр. — *сущ.* Конец; окончание.

**Әхирә** اخیره *ис.* Әхир-нең *мнс.* — *жен.* от әхир.

**Әхирән** اخیراً *р.* 1) Соныннан, иң азакта. 2) Ахыр чиктә. — *н.* 1) В самом конце 2) Наконец.

**Әхкар** احقر *с.* Бик түбән урын тоткан, хуррак, эшәкерәк. — *пр. ст.* от хәкыйрь — низкий, низменный, презренный, ничтожный.

**Әхкям** احکام *ис. к.* Хөкемнәр, карарлар, законнар. — *сущ. мн.* Решения, постановления, веления шариата.

**Әхля** احلی *с.* Бик татлы, татлырак, гәмлерәк. *Сөям кәүсәрдән әхля иренеңне.* (Г. Тук.) — *пр. ст.* от хөлү — сладкий, приятный.

**Әхлякъ*** اخلاق *ис.* 1) Холык-нын *к.* 2) Әхлак, кешелек сыйфатлары, мораль. *Әхлякъ, вөҗдан, инсафларны сөреп чыгардык истән дә...* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) *мн.* от холык. 2) Нравственные качества, мораль.

**Әхлякый*** اخلاقی *с.* Холык(ка), әхлак(ка бәйләнешле). — *прил.* Моральный, нравственный, этический.

**Әхлякыят** اخلاقیات *ис.* Әдәп-әхлак турындагы белемнәр, әдәп-әхлакка караган нәрсәләр. — *сущ.* 1) Мораль, моральные ценности. 2) Учение о морали.

**Әхлякыюн** اخلاقيون *ис. к.* Әдәп-әхлак белгечләре; әдәп-әхлак белеме белән шөгыльләнүчеләр. — *сущ. мн.* Моралисты; люди, занимающиеся учением о морали.

**Әхлям** احلام *ис. к.* Бәйләнешсез төшләр; хыяллар. *Әмма төштә күрелгән һәрбер әхлям безгә татлы тоела.* (Ж. Вәл.) — *сущ. мн.* Спутанные, бессвязные сны.

**Әхлят** اخلاط *ис. к.* Катнашмалар, катнашкан элементлар. — *сущ. мн.* Смеси.

**Әхляты әрбәга** اخلاط اربعه *ст.* Борынгы медицина карашында тере организмны тәшкил иткән дүрт элемент: кан; үт; кара үт; төкерек-селәгәй. — *сс.* Четыре главных элемента, которые, по представлениям древней медицины, входили в состав живого организма: кровь, жёлчь, чёрная жёлчь и слизь.

**Әхләф** اخلف Хәләф-нең *к.* — *мн.* от хәләф.

**Әхмак*** احمق *с.* Ахмак, тинтәк, тиле, сантый. — *прил.* Глупый, дурак.

**Әхмәр** احمر *с.* Кызыл (төс). — *прил.* Красный.

**Әхрар** احرار *с. к.* 1) Азатлар, ирек сөючеләр, ирекleләр. *Барча әхраре мәхәббәт миннән уңда зан итәм.* (Г. Тук.) 2) Аксөяк, аристократлар. — *прил. мн.* 1) Свободные, независимые, вольные. 2) Свободолюбивые. 3) Благородные, аристократы.

**Әхсән** احسن *с.* Бик күркәм, бик гүзәл, бик матур. — *пр. ст.* от хәсән—хороший, красивый.

**Әхтар** اخطار Хәтәр-нең *к.* — *мн.* от хәтәр.

**Әхтәр** اختر *ф. ис.* 1) Йолдыз; йолдызлар төркеме. 2) Йолдызлар буенча язмышны билгеләү. — *п. сущ.* 1) Звезда, созвездие. 2) Гадание по звёздам, предзнаменование.

**Әхтәри** اختری *ис.* 1) „Әхтәри кәбир" дип йөртелә торган гарәпчә-төркичә сүзлек. 2) Татар телендә уен картасы мәгънәсендә дә кулланыла. — *сущ.* 1) „Ахтари кебир"- название арабско-тюркского словаря. 2) В татарском языке употребляется и в значении игральной карты.

**Әхфад** احفاد Хәфид-нең *к. Синең зиярәтең әхфадең каршында мәҗһүл.* (М. Гаф.) — *мн.* от хәфид.

**Әхшаб** احشاب Хәшәб-нең *к.* — *мн.* от хәшәб.

**Әхъян** احيان Хин-нең *к.* — *мн.* от хин.

**Əхъянəн** احياناً *р.* Вакыт-вакыт, аратирə, кайбер вакыт. — *н.* Временами, время от времени, иногда.

**Əхъяр** احيار *ис. к.* Яхшы кешелəр, яхшылык (изгелек) кылучылар. *Янə Болгарда күп əхъяр карап торганда егълап зар.* (Г. Чок.) — *сущ. мн.* Добрые люди, доброжелатели, благодетели.

**Əхəб** احب *с.* Бик сөекле, сөеклерəк. — *пр. ст. прил.* Самый любимый, любимейший.

**Əхəват** اخوات *ис. к.* Бертуган кыз кардəшлəр; апалар, сеңеллəр. — *сущ. мн.* от өхт (өхет)—сестра.

**Əхəд** احد *сан* Бер, ялгыз, берəү. — *ч.* Один; единица.

**Əхəдиять** احديت *ис.* 1) Берлек, ялгызлык. 2) Үзе генə булучылык. — *сущ.* 1) Единичность. 2) Одиночество.

**Əхəдə гашрə** احدعشر *сан* Унбер. — *ч.* Одиннадцать.

**Əхəф** احف *с.* Җиңелрəк, җитезрəк, иң җиңел. — *пр. ст.* от хəфиф—лёгкий; прыткий.

**Əхҗар** احجار Хəҗəр-нең *к.* — *мн.* от хəҗəр.

**Əшбаһ** اشباه Шибеһ-нең *к.* — *мн.* от шибеһ.

**Əшбəһ** اشبه *с.* Бик охшашлы, иң охшаган. *Вə ма əшбəһ залик* — моңа охшаганнар, моңа охшашлылар. — *прил.* Похожий, схожий.

**Əшвак** اشواق Шəүкъ-нең *к.* — *мн.* от шəүкъ.

**Əшгал** اشغال Шөгыль-нең *к.* — *мн.* от шөгыль.

**Əшгар** اشعار Шигырь-нең *к.* *Əл Иманкулый Садыйк əшгар язарга башламыш.* (Ш. Баб.) — *мн.* от шигырь.

**Əшкар** اشقر *с.* 1) Җирəн чəчле. 2) Сары чəчле. — *прил.* 1) Белокурый; русый; рыжий. 2) Блондин.

**Əшкбар** اشكبار *ф. с.* Елаучы, күз яше түгүче. — *п. прил.* Плачущий, проливающий слёзы.

**Əшкыя** اشقيا Шəкый-нең *к.* — *мн.* от шəкый.

**Əшкял** اشكال Шəкел-нең *к.* — *мн.* от шəкел.

**Əшкярə** اشكاره *ф. с.* 1) Ачык, ачыктан-ачык, яшермəстəн, күз алдында. 2) Кычкырып. *Əшкярə укымая башлады.* (М. Ак.) — *п. прил.* 1) Ясно, открыто, публично. 2) Громко.

**Əшнагъ** اشنع *с.* Бик җирəнгеч, бик шакшы, хурлыклы, түбəн. — *прил. пр. ст.* Гадкий, позорный, низменный, отвратительный.

**Əшрар** اشرار Шəрр-нең *к.* — *мн.* от шəрр.

**Әшраф** اشراف Шәриф-нең *к. Бу юл илә җитешмеш җөмлә әшраф.* (Г. Тук.) — *мн.* от шәриф.

**Әшрибә** اشربه Шәраб-нең *к.* — *мн.* от шәраб.

**Әшрәф** اشرف *с.* 1) Кадерлерәк, бик хөрмәтле. 2) Зур дәрәҗәле, затлы, намуслы. — *пр. ст.* от шәриф — 1) Знатный. 2) Благородный, честный.

**Әшфак** اشفاق Шәфәкъ-нең *к.* — *мн.* от шәфәкъ.

**Әшфәкъ** اشفق *с.* Бик шәфкатьле, бик рәхимле. — *пр. ст.* от шәфикъ — сострадательный, милосердный.

**Әшхас** اشخاص Шәхыс-ның *к.* — *мн.* от шәхыс (шәхс).

**Әшшәригателгарраэ** الشريعه العرا *гыйб. дини* Хөрмәтле шәригать. *Шәригателгарраэ Мөхәммәдия бервакытта да качарга кушмый* (Г. Газиз). — *фр. рел.* Высокочтимый шариат.

**Әшья** اشيا Шәй-нең *к. Әл-Харис Фәйзи дигәч тә, төште искә „әшья" сы, „әшья" лар чәнчелсен инде, әшьясыз да баш яши.* (Ш. Баб.) *Гыйльме әшья* — физика. — *мн.* от шәй.

**Әшәд** اشد *с.* 1) Бик каты, катырак. 2) Бик көчле, бик куәтле, бик нык. 3) Кыенрак, яманрак. *Бәнчә үлмәктән әшәд мәнса вә мәтрукиятем.* (Г. Тук.) — *пр. ст.* от шәдид — 1) Жестокий, строгий. 2) Сильный, мощный. 3) Трудный.

**Әшәрр** اشر *с.* Бик усал, бик явыз, иң усал, иң явыз. — *пр. ст.* от шәрр — плохой, злой.

**Әшҗар** اشجار Шәҗәр-нең *к.* — *мн.* от шәҗәр.

**Әшҗәгъ** اشجع *с.* Батыррак. — *пр. ст.* от шәҗигъ — храбрый, отважный, смелый.

**Әшһәде** اشهد *фиг.* Шәһадәт бирәм, таныклыйм. *Гуаһлыклар бирәсәң син, „әшһәде" дип.* (Г. Тук.) — *гл.* Свидетельствую.

**Әшһәр** اشهر *с.* Бик атаклы, бик данлы. — *пр. ст.* от шәһир — известный, славный.

**Әя** ايا *ым.* И, әй. — *межд.* О!

**Әяди** ايادى *ис.* 1) Ядь-нең *к.* 2) Яклаучылар. — *сущ.* 1) *мн.* от ядь. 2) Покровители.

**Әялят** ايالات Әяләт-нең *к.* — *мн.* от әяләт.

**Әяләт** ايالت *ис.* Өлкә, губерна. — *сущ.* Провинция, область.

**Әүвәл*** اول *сан* 1) Беренче. 2) Башта, элек. — *ч.* 1) Первый. 2) Сначала, сперва.

**Әүвәлин** اولين *ис. к.* Ата-бабалар, әүвәлгеләр, электә булганнар. — *сущ. мн.* Предки, древние люди.

**Әүвәлият** اوليات *ис. к.* 1) Башлангычлар. 2) Төп матдә. 3) Вакыйганың барлыкка киләчәген белдерүче билгеләр. — *сущ. мн.* 1) Начала (чего-либо). 2) Основной элемент. 3) Первые признаки (какого-либо события).

**Әүвәлән** اوّلاً *р.* Иң элек, иң башта, беренче булып, башлап. *Әүвәлән гадәтчә самовар мәйданга чыкты.* (М. Ак.) — *н.* Во-первых, сперва, сначала.

**Әүдия** اوديه Вади-нең к. — *мн.* от вади.

**Әүзаг** اوضاع Вазгы-ның *к.* — *мн.* от вазгы.

**Әүзан** اوزان Вәзен-нең *к.* — *мн.* от вәзен.

**Әүзах** اوضح *с.* Бик ачык; шикләнүгә, башкача уйларга һич урын калдырмаслык ачык. — *пр. ст.* от вазыйх — 1) Ясный, очевидный. 2) Чёткий, отчётливый.

**Әүкат** اوقات *ис.* 1) Вакыт-ның *к.* 2) Аш, ризык, мал. *Әүкаты бар кеше теләгән вакытында ашар.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) *мн.* от вакыт. 2) Пища, пропитание; продукты питания.

**Әүлия*** اوليا *ис. дини* Изге кеше. — *сущ. рел.* Святой угодник.

**Әүля** اولى ،اولا *с.* Артыграк, өстенрәк, алдынгырак, яхшырак. *Болай сайрау кавышканнан соң булыр әүля.* (М. Гаф.) — *прил.* Лучше, удобнее.

**Әүляд** اولاد Вәләд-нең *к.* *Иң сөекле эшче әүлядым быел ач калды дип, изге шәфкатьле анамыз, мәрхәмәтле җир җылый.* (Г. Тук.) — *мн.* от вәләд.

**Әүләвиять** اولويت *ис.* Алдынгылык, артыграк булу, өстен тору, артыграк, яхшырак булу. — *сущ.* Первенство, превосходство, преимущество.

**Әүрак** اوراق Вәрәкъ-нең *к.* *Сезгә тәслим әйләмеш милләт бөтен әүракыны.* (Г. Тук.) — *мн.* от вәрәкъ.

**Әүрам** اورام *ис. к.* Шешләр. — *сущ. мн.* Вздутие, опухоль.

**Әүридә** اورده *ис. к.* Вена (канны йөрәккә китерә торган кан тамырлары). — *сущ. мн.* Вена.

**Әүсан** اوثان Вәсән I-нең *к.* — *мн.* от вәсән I.

**Әүсат I** اوساط Вәсат-ның *к.* — *мн.* от вәсат (вәсәт).

**Әүсат II** اوسط *с.* Урта, урталагы. — *прил.* Средний, срединный.

**Әүсаф** اوصاف Васыф-ның *к.* *Әүсафы вә әхлакы күркәм булган кешегә якынлык яхшы эштер.* (К. Нас.)
*мн.* от васыф.

**Әүтад** اوتاد *ис. к.* Казыклар.
*сущ. мн.* Колья, столбы.

**Әүтан** اوطن Ватан-ның *к.*
*мн.* от ватан.

**Әүҗ** اوج *ис.* Бер әйбернең иң югары ноктасы, биек урыны, түбәсе.
*сущ.* Высшая точка, вершина, апогей.

**Әүҗгир** اوجگیر *ф. с.* Иң югары дәрәҗәгә ирешкән, иң югары чыккан; күтәрелүче.
*пр. прил.* Набравший высоту, поднявшийся на большую высоту; поднимающийся, возвышающийся.

**Әүҗә** اوجه *р.* Урынлы, иң уңышлы. *Бу фән китабын рауза дип атамак әүҗәдер.* (К. Нас.)
*н.* Уместно, более подходяще.

**Әүһам** اوهام Вәһем-нең *к.*
*мн.* от вәһем.

**Әҗаниб** اجانب Әҗнәби-нең *к.*
*мн.* от әҗнәби.

**Әҗвибә** اجوبه Җаваб-ның *к.*
*мн.* от җаваб.

**Әҗвәф** اجوف *с.* 1) Эче буш, буш эчле. 2) *грам.* Буш фигыль (тамырында икенче хәрефе „و“ яки „ی“ булган фигыль). 3) *күч.* Буш башлы, белемсез, надан; ахмак кеше.
*прил.* 1) Пустой, полый. 2) Пустой глагол. 3) *перен.* Пустой, тупой, невежественный; глупый.

**Әҗдад** اجداد Җәд-нең *к*
*мн.* от җәд.

**Әҗер*** اجر *ис.* 1) Бер эш өчен бирелгән нәрсә. 2) *дини* Савап. *Унөч яшьлек кызга тисәң, хаҗның әҗере җуела.* (Г. Тук.)
*сущ.* 1) Награда, вознаграждение, плата. 2) *рел.* Благодеяние.

**Әҗза** اجزا *ис.* 1) Җөзә-нең *к.* *Бу үләннең һәр әҗзасы дарудыр.* (К. Нас.) 2) Дарулар, медикаментлар.
*сущ.* 1) *мн.* от җөзә. 2) Медикаменты, лекарства.

**Әҗзаи мапя** — су элементы.
Элемент воды.

**Әҗзаи төрабия** — җир, туфрак элементы. *Алтынның әҗзаи маиясенең, әҗзаи торабиясенә шиддәт ихтилатына бинаән әҗзасын тәфрикъ итмәккә утның куәте җитмәс.* (К. Нас.)
Элемент почвы.

**Әҗзаханә** اجزاخانه *ис.* Аптека
*сущ.* Аптека.

**Әҗиннә** اجنه Җәнин-нең *к.*
*мн.* от җәнин.

**Әҗир** اجیر *ис.* Көнлекче, көнлек эштә эшләүче. 2) Хезмәтче.
*сущ.* 1) Подёнщик. 2) Слуга.

**Әҗляф** اجلاف *ис. к.* Ахмаклар, тупаслар, түбәннәр, әшәкеләр. — *сущ. мн.* Грубые, неотёсанные; невежественные; невоспитанные (люди).

**Әҗмәгыйн** اجمعين *ис. к.* Барысы бергә, барысы да, һәммәсе. — *сущ. мн.* Все.

**Әҗмәл** اجمل *с.* Бик матур, бик күркәм, матуррак, күркәмрәк, гүзәлрәк. — *пр. ст.* от **җәмил** — красивый, прекрасный.

**Әҗнас** اجناس Женес-нең *к.* — *мн.* от женес.

**Әҗнихә** اجنحه Җәнах-ның *к.* — *мн.* от **җәнах**

**Әҗнәби** اجنبى *с.* 1) Чит кеше, ят кеше, башка женес кешесе. 2) Чит ил кешесе. — *прил.* 1) Чужеземец, иностранец. 2) Чужой, посторонний.

**Әҗнәбиять** اجنبيت *ис.* Чит илнеке булучылык, башка женес кешесе булучылык. — *сущ.* Относящийся к чужеземному, иностранному.

**Әҗрам** اجرام *ис.* 1) Җансыз җисемнәр. 2) Күк җисемнәре (ай, кояш, йолдызлар). *Шул мәләкләрнең күзләрен йолдыз дибез, белмәенчә сез шуны әҗрам дисез.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Неорганические тела. 2) Небесные тела.

**Әҗраме голүвия** اجرام علويه
**Әҗраме сәмавия** اجرام سماويه
*гыйб.* Күк йөзендәге барлык җисемнәр (ай, кояш, йолдыз) һ. б. — *фр.* Небесные тела.

**Әҗсад** اجساد Җәсәд-нең к. — *мн.* от җәсәд.

**Әҗсам** اجسام Җисем-нең *к.* — *мн.* от җисем.

**Әҗфан** اجفان Җәфен-нең *к.* — *мн.* от җәфен.

**Әҗәл*** اجل *ис.* Үлем, үлем вакыты. *Дәрдемә дәрман бәнем вар: я әҗәлдер, я висаль.* (Г. Тук.) — *сущ.* Смерть, кончина.

**Әҗәлл** اجل *с.* Иң югары, иң югары дәрәҗәле; иң кадерле, хөрмәтле. — *пр. ст.* от **җәлил** — 1) Большой. 2) Великий, славный, великолепный, важный. 3) Знатный, почтенный, уважаемый.

**Әҗһәл** اجهل *с.* Иң надан, иң белемсез, бик надан, — *пр. ст.* от **җаһил** — невежда, неграмотный.

**Әһали** اهالى Әһел-нең *к. Зыясыннан әһали улды пөрнур.* (Г. Тук.) — *мн.* от әһел.

**Әһва** اهوا Һава II-нең *к.* — *мн.* от һава II.

**Әһваль** اهوال Һәүл-нең *к.* — *мн.* от һәүл.

**Әһвән** اهون *с.* 1) Җиңелрәк, уңайрак, зарарсызрак. 2) Очсыз, арзан. — *пр. ст.* от һәүн — 1) Лёгкий, меньший; безвредный. 2) Дешёвый.

**Әһвәнияте** اهونيت *ис.* Очсызлык, арзанлык. — *сущ.* Дешевизна.

**Әһда** اهدا *ис кара:* иһда. *Табигыйдер ки йөгмәз бу санәмнәр раһ әһдадән.* (Г. Тук.) — *см.* Иһда.

**Әһел*** اهل *ис.* 1) Кеше, ия; хужа. 2) Бер җирнең торучысы, халкы. 3) Бер эшкә карата яраклылык, аны башкара алучылык. *Юк, син сөяк кимерә; гә әһел түгел.* (К. Нас.) 4) Ирнең хатыны, хатынның ире. — *сущ.* 1) Человек, люди; хозяин. 2) Население, жители. 3) Способный (к чему-либо) человек. 4) Родственники, супруги.

**Әһле вафа** اهل وفا *ст.* Ышаныч иясе, ышанычлы, яхшы кеше. *Гаделлек кыйл, ул имде әһле вафа.* (Ут. Им.) — *сс.* Надёжный человек.

**Әһле вөждан** اهل وجدان *ст.* Вөждан ияләре, вөждан белән эш итүчеләр. — *сс. букв.* „Люди совести", совестливые, честные люди.

**Әһле гокул** اهل عقول *ст.* Гакыл ияләре. — *сс. букв.* „Люди ума", умные.

**Әһле гыйлем** اهل علم *ст.* Гыйлем ияләре, укымышлылар. *Сез әһле гыйлемсез, сезгә ярдәм итәргә тиешбез.* (Г. Ибр.) — *сс.* Образованные, люди науки.

**Әһле гыяль** اهل عيال ст. Өй җәмәгате, гаилә, семья. *Бу атлас туннары төшәр тәнендин, киеп чүпрәк китәр әһле гыяльдин.* (Ут. Им.) — *сс.* Семья, члены семьи, домашние.

**Әһле зирагать** اهل زراعت *ст.* Игенчеләр. — *сс.* Хлеборобы, землепашцы.

**Әһле ислам** اهل اسلام *ст.* Мөселманнар. — *сс.* Мусульмане.

**Әһле каләм** اهل قلم *ст.* Каләм ияләре, язучылар. *Һәртөрле сүз язды бу көн әһле каләм.* (М. Гаф.) — *сс. букв.* „Люди пера", писатели, литераторы.

**Әһле карья** اهل قريه *ст.* Авыл кешеләре. — *сс.* Деревенские люди.

**Әһле китап** اهل كتاب *ст.* Дини китапларның берсенә (Тәүрат, Инҗил, Коръәнгә) ияреп дин тотучылар. — *сс. букв.* „Люди писания", т. е. следующие учению, изложенному в Талмуде, Евангелии или Коране.

**Әһле кәмаләт** اهل كمالت *ст.* Камил кешеләр. — *сс.* Эрудиты.

**Әһле салиб** اهل صليب *ст.* 1) Христиан динендәге халык. 2) Урта гасырда барган тәре сугышында катнашучылар. — *сс.* 1) Христиане. 2) Крестоносцы, участники крестовых походов в Палестину.

**Әһле сәрвәт** اهل ثروت *ст.* Мал ияләре, бай кешеләр. — *сс.* Богачи, богатые, состоятельные люди.

**Әһле тәкфир** اهل تكفير *ст.* Кяфергә чыгаручылар, кяфер диючеләр. *Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен күреп актык сүзем.* (Г. Тук.) — *сс.* Считающие (кого-либо) неверным, гяуром.

**Әһле фәсад** اهل فساد *ст.* Бозык кешеләр. — *сс.* Возмутители, бунтовщики, развращённые люди.

**Әһле һава** اهل هوا *ст.* Азгын кешеләр, бозык, әхлаксыз кешеләр. — *сс.* Развратники, безнравственные люди.

**Әһле һөнәр** اهل هنر *ст.* Һөнәр ияләре, һөнәрле кешеләр. — *сс.* Люди, владеющие ремеслом (вообще); ремесленники.

**Әһли** اهلى *с.* Кулга ияләшкән. — *прил.* Ручной, прирученный, домашний.

**Әһли хайван** — йорт хайваны. — Домашнее животное.

**Әһлиять** اهليت *ис.* Бер нәрсәгә әһел булу; бер эшне белү, аны булдыра алу. — *сущ.* Способность к чему-либо; пригодность.

**Әһлән вә мәрхәба** اهلاً ومرحبا *гыйб.* Хуш килдегез, рәхим итегез! мәгънәсендә кулланыла. *„Әһлән вә мәрхәба!“ — дип нәфис нигъмәтләр китерде.* (К. Нас.) — *фр.* Добро пожаловать! здравствуйте!

**Әһлән вә сәһлән** اهلاً وسهلاً *гыйб.* *кара:* әһлән вә мәрхәба. — *фр.* *см.* әһлән вә мәрхәба.

**Әһрам** اهرام *ис.* Һәрәм II-нең *к.* — *мн. сущ.* от һәрәм.

**Әһәм** اهم *с.* Бик әһәмиятле, иң мөһим. — *пр. ст.* от мөһим — значительный, важный.

**Әһәмият*** (әһәммиять) اهميت *ис.* Кирәклелек, әһәмият. — *сущ.* Значение, важность.

# Ө

**Ө** — татар әлифбасында утыз дүртенче хәреф булып, гарәп әлифбасының беренче хәреф булган әлиф (اُ) һәм өтер — 34-я буква татарского алфавита. Обозначает алиф или другую согласную с даммой в арабс-

(замма) билгесе урыннарында кулланыла. — ком письме. Чаще всего бывает в начале слова.

**Өбүвәт** أبوت *ис.* Аталык, ата булу. — *сущ.* Отцовство.

**Өгъҗүбә** أعجوبه *ис.* Таң калырлык эшләр, шаккатыргыч эшләр. — *сущ.* Чудо, (что-либо) небывалое.

**Өдәба** أدبا Әдиб-нең *к.* — *мн.* от әдиб.

**Өзен** أذن *ис.* Колак. *Сурәтең чәшмемдәдер, өзенемдәдер саутың һәнүз.* (Г. Тук.) — *сущ.* Ухо.

**Өлеләлбаб** اولوالالباب *гыйб.* Акыл ияләре, акыллылар. — *фр.* Разумные люди.

**Өлеләмер** اولوالامر *гыйб.* Әмер ияләре, боерык бирүчеләр, зур түрәләр. — *фр.* Власти, начальство.

**Өлфәт** الفت *ис.* 1) Аралашу, ияләшү, үзләшү, дуслашу. 2) Бердәмлек. *Дуслык вә кардәшлек өлфәткә, вә өлфәт куәткә сәбәбдер.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Дружба, симпатия. 2) Согласие, единодушие.

**Өлүф** الوف *сан* Әлеф-нең *к.* — *ч. мн.* от әлеф — тысяча.

**Өлүһиять** الوهيت *ис. дини* Тәңрелек, аллалык. — *сущ. рел.* Божественность.

**Өмид*** اميد *ф. ис.* Өмет, бер нәрсәнең булуын көтеп тору. — *п. сущ.* Надежда.

**Өмид бәхеш** اميدبخش *ф. с.* Өметләндерүче. — *п. прил.* Обнадёживающий.

**Өмидвар** اميدوار *ф. с.* Өмет итүче, өметле. — *п. прил.* Надеющийся.

**Өмидгяһ** اميدگاه *ф. ис.* Өмет ителгән урын, ышаныч. — *п. сущ.* Оплот, надежда.

**Өмиддар** اُميددار *ф. ис.* Өметле, өмет баглаучы, өмет тотучы, ышанган. *Кичәкөндез өмиддармын сиңа.* (Дәрд). — *п. сущ.* Надеющийся, имеющий надежду.

**Өм** اُم *ис.* Ана. — *сущ.* Мать.

**Өммелхәбаис** اُم‌الخبائث *гыйб.* Әшәкелекләрнең анасы, ягъни исерткечләр. — *фр. букв.* „Мать мерзостей, пакостей" — в значении спиртные напитки.

**Өмми** اُمى *с.* Укый-яза белмәүче. — *прил.* Неграмотный.

**Өммәт*** امت *ис.* 1) Өммәт, бер пигамбәрнең дингә өндәгән халкы. 2) Милләт. — *сущ.* 1) Последователи (какого-либо) пророка 2) Нация, народ.

**Өммәһат** اُمهات Өм-нең *к.* — *сущ. мн.* от өм.

**Өмур** اُمور Әмер I-нең *к.* *Өмуре әһле дөнья бунлара тәслим улынмыштәр.* (Г. Тук.)
*мн.* от әмер I.

**Өмур ашна** — эш белүче.
Знающий дело, умеющий.

**Өмумәт** اُمومت *ис.* Ана булу.
*сущ.* Материнство.

**Өмурдидә** اُموردیده *гф.* *ст.* Эш күргән, тәҗрибәле.
*ар.-п.* *сс.* Практик, имеющий большой опыт работы.

**Өмуре зарурия** امورضروریه *ст.* Бик кирәкле эшләр.
*сс.* Необходимые дела.

**Өмуре мөлкия** امورملکیه *ст.* Дәүләт эшләре.
*сс.* Государственные дела.

**Өмәм** امام Өммәт-нең *к.*
*мн.* от өммәт.

**Өмәра** امرا Әмир-нең *к.*
*мн.* от әмир.

**Өнес** اُنس *ис.* 1) Ияләшү, ияләнү, күнегеп киту. 2) Дуслашу, гадәтләнү.
*сущ.* 1) Привычка, привязанность. 2) Общительность, дружба.

**Өнса** انثی،انثا *ис.* Хатын-кыз. *Иел, әй халкы дөнья! Уртада юл бир хатыннарга! Яшә, әй галәме өнса! — Вакыт хакларны аңларга.* (Г. Тук.)
*сущ.* Женщина.

**Өсбуг** اسبوع *ис.* Атна.
*сущ.* Неделя.

**Өслүб** اسلوب *ис.* Стиль, ысул, рәвеш, кыяфәт.
*сущ.* Способ, метод, стиль.

**Өсреб** اسرب *ис.* Кара кургашын.
*сущ.* Свинец.

**Өстад*** (**өстаз, остаз**) استاد *ф.* *ис.* 1) Өйрәтүче, укытучы, тәрбияче. 2) Оста. 3) Профессор, остаз.
*сущ.* 1) Учитель, воспитатель. 2) Мастер. 3) Профессор.

**Өстарә** اوستره،استره *ф.* *ис.* Бритва. *Сакал-мыек кырырга пәке вә өстарәләр сорады.* (Г. Фәез.)
*п.* *сущ.* Бритва.

**Өстевар** استوار *ф.* *с.* Нык, таза, көчле, каты.
*п.* *прил.* Прочный, устойчивый, жёсткий.

**Өстехан** استخوان *ф.* *ис.* Сөяк. *Көюбән өстехан буде булды* (Сайяди).
*п.* *сущ.* Кость.

**Өстуванә** اسطوانه *ис.* Багана, колонна.
*сущ.* Колонна, столб.

**Өсәра** اُسرا Әсир I-нең *к.* *Без өсәраи, көсәляи дә сәвекъ ит һиммәтә, кыйл тәрәххем милләтә, калдырма зинһар зилләтә.* (Г. Тук.)
*мн.* от әсир I.

**Өфык*** افق *ис.* Күкнең җиргә тигән кебек булып торган итәге, горизонт. — *сущ.* Горизонт.

**Өфкый** افقى *с.* Горизонталь, ятма. — *прил.* Горизонтальный.

**Өфтадә** افتاده *ф. ис.* Төшкән; кешелектән чыккан. — *п. сущ.* Павший, опустившийся (морально).

**Өфтан вә хизан** افتان وخيزان *ф. р.* Ава-түнә. *Йөкерде кызыйга өфтан вә хизан* (Сайяди). — *п. н.* Падая и вставая.

**Өхет** اخت *ис.* Кыз туган, кыз кардәш. — *сущ.* Сестра.

**Өхуәт** اخوت *ис.* Кардәшлек, бертуганлык. — *сущ.* Братство.

**Өҗрә** اجره *кара:* өҗрәт. — *см.* Өҗрәт.

**Өҗрәи кәлямия** — язган өчен түләү, гонорар. — Гонорар.

**Өҗрәт** اجرت *ис.* Эш хакы, хезмәт хакы. — *сущ.* Плата, вознаграждение, заработная плата.

**Өҗүр** اجور Әҗер-нең *к.* — *мн.* от әҗер.

# Җ

**Җ** — ج. Татар әлифбасында утыз алтынчы, гарәп әлифбасында бишенче хәреф булып, сан урынына кулланганда 3 не белдерә. — 36-я буква татарского алфавита. Обозначает пятую букву арабского алфавита „дж" с цифровым значением 3.

**Җаби** جابى *сф. дини* Салымнар һәм вәкыф акчаларын җыючы. — *пр. д.* Сборщик оброка и других доходов, причитающихся мечетям.

**Җабир** جابر *сф.* Җәберләүче; кыерсытучы, урынсыз (хаксыз) каһәрләүче. — *пр. д.* 1) Притеснитель, тиран. 2) Обидчик.

**Җабиранә** جابرانه *гф. р.* Җәберләүчеләрчә, каһәрләүчеләрчә, тираннарча. — *ар.-п. н.* Тиранически, деспотично.

**Җабәҗа** جابجا *ф. р.* Анда-монда, анда-санда. — *п. н.* И там и сям.

**Җаваб*** جواب *ис.* Җавап. — *сущ.* Ответ.

**Җавабе мөстәкитә** — кешене телсез калдырырлык итә торган җавап; тапкыр җавап. — Ответ, заставляющий собеседника замолчать; быстрый ответ.

**Җавабе катгый** جواب قطعى *ст.* Кискен җавап. — *сс.* Категорический ответ.

**Жавабе рәд** جواب‌رد *ст.* Тискәре жавап, кире жавап. — *сс.* Отрицательный ответ.

**Жавабе шафи** جواب‌شافی *ст.* Канәгатьләндерә торган жавап, сораганны кабул иткән жавап. — *сс.* Положительный, удовлетворительный ответ.

**Жавабнамә*** جوابنامه *гф. ис.* Жавап хаты, жавап язуы. — *ар.-п. сущ.* Ответное письмо.

**Жавабән** جوابا *р.* Жавап итеп, жавап йөзеннән. — *н.* В ответ на...

**Жавид** جاوِد *ф. с.* Мәңге, мәңгелек, үлми (бетми) торган. — *п. прил.* Вечный.

**Жавидан** جاودان *ф. с.* Мәңге бетмәс, мәңгелек. *Гыйшык җәннәттер, морад итсәң хәят җавидан.* (Дәрд.) — *п. прил.* 1. Вечный. 2. Вечно.

**Жавиданә** جاودانه *ф. р.* Мәңгегә, мәңгелек булып. *Җиһан калмас кешегә җавиданә.* (Хорәз.) — *п. н.* Вечно.

**Жаддә** جاده *ис.* Олы юл. — *сущ.* Широкая дорога, путь.

**Жаду** جادو *ф. ис.* Сихырчы, күрәзәче, күрәзәлек итүче. — *п. сущ.* Чародей, волшебник, колдун, маг.

**Жадуанә** جادوانه *ф. р.* Күрәзәчеләрчә, сихырчыларча. — *п. н.* Колдовски, магически, как волшебник.

**Жае сафа** جای‌صفا *гф. ис.* Кәеф-сафа урыны, рәхәтләнү урыны. *Бу дөнья бер таkым вәхшиләргә җае сафа улды.* (Г. Тук.) — *ар.-п. сущ.* Увеселительное место.

**Жазиб** جاذب *сф.* 1) Үзенә тартучы, үзенә каратучы. *Хәлаек кальбе җалиб вә җазиб.* (Г. Тук.) 2) Сөйкемле, сокландыра торган. — *пр. д.* 1) Протягивающий, привлекающий. 2) Привлекательный.

**Жазибә** جاذبه *ис.* 1) Жазиб-нен *мнс.* 2) Кешенең күңелен үзенә тарта торган көч (сыйфат). *Юкса эченә бер җазибәле нәрсә салдыгызмы.* (З. Һад.) — *сущ.* 1) *жен.* от жазиб. 2) Привлекательность, сила влечения.

**Жазим** جازم *сф.* 1) Кискен карарга (фикергә) килүче. 2) *грам.* Гарәп синтаксисында киләчәк заман фигылен сәкен белән кисеп әйтелүне тудырган хәл. — *пр. д.* 1) Решающий, решительный. 2) *грам.* Частица, требующая усечённого наклонения (в глаголах будущего времени).

**Жаигъ** جایع *сф.* Ач, ачыккан. — *пр. д.* Голодный.

**Җаиз** جائز *сф.* Дөрес, ярый торган, яраклы. *Аның осулы тәдрисе җаиз дәгел.* (М. Ак.) — *пр. д.* 1) Подходящий 2) Позволительный, допустимый, дозволенный

**Җай** جاى *ф. ис.* Урын. *Парау атлы нәфис җайга.* (Г. Кан.) — *п. сущ.* Место.

**Җайгир** جايگير *ф. с.* Җирләшкән, урнашкан. — *п. прил.* Занявший место, обосновавшийся.

**Җайир** جاير،جائر *сф.* 1) Азаплаучы, кысучы, җәберләүче. 2) Гаделсез. — *пр. д.* 1) Притесняющий, жестокий. 2) Несправедливый.

**Җалиб** جالب *сф.* Үзенә каратучы, күңелне үзенә тартучы, җәлеп итүче. — *пр. д.* Привлекающий, привлекательный.

**Җалис** جالس *сф.* Утыручы. — *пр. д.* Сидящий.

**Җам** جام *ф. ис.* Эчә торган бокал, кәсә. *Гафләт җамын илар берлә ярышмышмән.* (М. Кол.) — *п. сущ.* Чаша, кубок.

**Җамбаз** جامباز *ф. ис.* Бик күп аракы эчүче, эчкече, исерек баш. — *п. сущ.* Пьяница, кутила

**Җами җам** جامیجام *ф. ис.* Сихырлы бокал (Иран хорафатында хәмерне уйлап табучы Җәмшид бокалы). — *п. сущ.* Волшебный бокал (по древнеиранскому преданию бокал изобретателя вина Джамшида).

**Җамигъ** جامع *сф.* 1) Җыючы, җыя торган. 2) Җомга укыла торган зур мәчет. — *пр. д.* 1) Собирающий. 2) Объединяющий, соединяющий. 3) Мечеть (соборная).

**Җамид** جامد *сф.* 1) Туң, туңган, каткан. *Селкенми бик озак торганга, чыпчыклар аны җамид нәрсәгә хисаплар-лар иде.* (К. Нас.) 2) *хим.* Органик булмаган каты әйберләр. 3) *грам.* Тамыр сүз. — *пр. д.* 1) Твёрдый, застывший; замёрзший. 2) *хим.* Неорганическое твёрдое тело, минерал. 3) *грам.* Непроизводный.

**Җамә** جامه *ф. ис.* Өске күлмәк, кием. *Җамәсе көһнә улана бәдгөмән мәтлуб имәс.* (Ак). — *п. сущ.* Платье, одежда.

**Җамәдан** جامه‌دان *ф. ис.* 1) Күлмәк (кием) сандыгы, кием шкафы. 2) Чемодан. — *п. сущ.* 1) Сундук для платья, платяной шкаф. 2) Чемодан.

**Җамәкән** جامه كن،جامكان *ф. ис.* 1) Чишенү бүлмәсе (мунчада). 2) Кием шкафы (гардероб). 3) Пыяла витрина. 4) Пыялалы парник. 5) Өй эчендә пыялалы бүлем. — *п. сущ.* 1) Раздевальня в бане. 2) Гардероб 3) Стеклянная витрина. 4) Стеклянные рамы парника. 5) Стеклянная перегородка.

**Жамә хаб** جامەخواب *ф. ис.* Йокы күлмәге, йокы киеме. *Әгәр безне җамәи хабдә күрсәң иде, бер төн дип хисап итәр идең.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Ночная, спальная рубашка.

**Жан*** جَان *ф. ис.* Жан кот. — *п.* сущ. Душа; дух.

**Жанан** جانان *ф. ис.* Сөекле, сөйгән кыз, җанаш. — *п. сущ.* Возлюбленная, милая.

**Жандар** جاندار *ф. с.* 1) Жанлы, тере. 2) Дәртле кеше, елдам. — *п. прил.* 1) Живое существо, живая душа. 2) Энергичный человек.

**Жани** جانى *ис.* Жинаятьче, хыянәтче, закон бозучы. *Жаниләрнең җид·нче ел җеназасын укырбыз, инде вакыт, алар бетсен.* (М. Гаф.) — *сущ.* Преступник, злодей.

**Жаниб** جانب *ис.* Як, тараф. *Казан Идел елгасының сул җанибендәдер.* (К. Нас.) — *сущ.* Бок, сторона; фланг.

**Жанибәйн** جانبين *ис.* Һәр ике як, һәр ике тараф. — *сущ. дв. ч.* Две стороны.

**Жанишин** جانشين *ф. ис.* Урынбасар. — *п. сущ.* 1) Заместитель. 2) Заменитель.

**Жания** جانيه *кара:* жани. *Монда сакин божи фирка җания, табигыйннар мәзһәбе Гайнания.* (Г. Тук). — *см.* Жани.

**Жар** جار *ис.* Күрше. — *сущ.* Сосед.

**Жари** جارى *с.* 1) Агым, ага торган, агымдагы. *„Белмәдем мин" дип хаҗи зари кыла, күзләреннән яшьләрен җари кыла.* (Г. Тук.) 2) Кулланыла торган. 3) Булып торган, дәвам итә торган. *Ике адәм арасында җари булган мохабәрат...* (К. Нас.) — *прил.* 1) Текущий. 2) Употребляемый. 3) Находящийся в употреблении.

**Жарих** جارح *сф.* Яралаучы, яралый торган, җәрәхәтли торган. *Аләте җарихә* — яралау коралы. — *пр. д.* Ранящий.

**Жария*** جاريه *сф.* 1) *кара:* жари. 2) Яшь кол хатын, кәнизәк. *Хатыннары өстеннән күп җарияләр алмышлардыр.* (З. Һад.) — *пр. д.* 1) *жен.* от жари. 2) Невольница, молодая рабыня.

**Жасус** جاسوس *ис.* 1) Шымчы; шпион. *Әнкәм бер җасус иде, әткәй жандар, тәрәзәдән караганны күрсә анлар...* (Г. Тук.) 2) Яшерен полиция агенты. — *сущ.* 1) Шпион, сыщик. 2) Агент тайной полиции.

*Бу заманның дуслары гаеб эзләүче җасуслардыр.* (К. Нас.)

**Җафи** جافى *сф.* Азаплаучы, җәфалаучы. — *пр. д.* 1) Мучающий. 2) Мучитель.

**Җаһ** جاه *ф. ис.* Югары дәрәҗә, чин. *Кил, и Сайяди, җаһ былбыл хуш әлхан* (Сайяди). — *п. сущ.* Высокий ранг, чин, высокое положение, сан.

**Җаһид** جاهد *сф.* Тырыш, тырышучы, тырышып эшләүче, иҗтиһад итүче. — *пр. д.* Прилежный; старательный, усердный.

**Җаһил*** جاهل *сф.* Надан, белемсез, укымаган. *Җаһил белән галимнәрне кушып бергә, өйрәтермен һәрбересен берләшергә.* (М. Гаф.) — *пр. д.* 1) Невежественный, неграмотный. 2) Невежа, неуч.

**Җаһила (җөһәля)** جاهلا *ис. к.* Наданнар, белемсезләр. *Бәнчә сезне җаһиланың сәүмәсе лязим дәгел.* (Г. Тук). — *сущ. мн.* Невежды, тупицы.

**Җаһиланә** جاهلانه *гф. р.* Наданнарча, белмичә, наданлык белән. — *ар.-п. н.* По неведению, по незнанию; как невежда; невежественно.

**Җаһиле мөрәккәб** جاهل مركب *ст.* Үзен галим дип санаган надан, икеләтә надан, чеп-чи надан. — *сс. букв.* Невежественный в квадрате, неуч, тупица.

**Җаһили** جاهلى *с.* 1) Наданнар(га), белемсезләр(гә бәйләнешле), 2) Ислам чорына чаклы булган дәвер(гә караган). — *прил.* 1) Невежественный. 2) Доисламский, живший в доисламскую эпоху.

**Җаһилиять** جاهليت *ис.* 1) Наданлык, белемсезлек, аңсызлык. 2) Мәҗүсилек; исламгача дәвер. *Гарәп халкы арасында җаһилиять заманында бәгъзы бер гадәтләр бар иде.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Невежество. 2) Язычество; доисламская эпоха.

**Җенес* (җинес)** جنس *ис.* 1) Хайваннар, үсемлек һәм башкаларның аерым төрләре. 2) Нәсел, раса; кабилә, кавым. 3) Төр, иш, сорт. 4) Ирлек, хатынлык. 5) *грам.* Җенес. — *сущ.* 1) Род. 2) Сорт; класс, разновидность. 3) Порода; племя, раса, народность. 4) Пол. 5) *грам.* Род.

**Җенси* (җинси)** جنسى *с.* 1)Раса(га караган), раса(га бәйләнешле). 2) Җенес(кә бәйләнешле). — *прил.* 1) Расовый, родовой. 2) Половой.

**Җенсиять (җинсиять)** جنسيت *ис.* 1) Җенеслек, 2) Бер җенестән булучылык. 3) Җенеслек сыйфаты. — *сущ.* 1) Пол. 2) Одинаковое происхождение. 3) Национальное качество.

**Җенсән** جنساً *р.* Җенес-нәсел ягыннан. *Җенсән бу зат мишәрдер, димәк хәйрел бәшәрдер.* (Г. Тук.) — *н.* Качеством.

**Җефет** جفت *ф. ис.* 1) Җөп, пар, так түгел. 2) Икегә бүленә торган сан. 3) Ирнең хатыны. *Булмадың ярым вә булмассың беләм. җефтем минем.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* 1) Пара, чета. 2) Парный; чётный 3) Мужняя жена, супруга.

**Җибал** جبال Җәбәл-нең *к.* — *мн.* от җәбәл.

**Җибилли** جبلى *с.* Табигый, тумыштан, яратылыштан булган. *Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән кермәс; табигатендә кабилияте җибиллисе булмаса, синең нәсыйхәтең әсәр итмәс — димәктер.* (К. Нас.) — *прил.* Врождённый, природный; прирождённый.

**Җибиллиять** جبليت *ис.* Тумыштан булган сыйфат, кешенең тумыштан булган холкы (табигате). — *сущ.* Врождённое качество; характер, натура.

**Җибрил** جبريل *ис. дини* Бер фәрештә исеме. *Хәзрәте Җибрил бәшарәт әйләде дип: „я рәсүл“.* (Г. Тук.) — *сущ. рел.* Архангел Гавриил.

**Җибһә** جبهه *кара:* җәбһә. *Кипми нык шөбһә тире бу җибһәдән.* (Г. Тук.) — *см.* Җәбһә.

**Җивар** جيوار *ис.* Күрше; тирә-як, тирә. *Шәһәр җиварында* — шәһәр тирәсендә. — *сущ.* Соседство, близость, окрестность.

**Җивә** جيوه *ф. ис.* Терекөмеш, күнә суы. — *п. сущ.* Ртуть.

**Җигәр (җегәр)** جگر *ф. ис.* Бавыр, бәгырь. *Ак җегәр* — үпкә. *Кара җегәр* — талак. — *п. сущ.* Печень, ливер.

**Җигәр хун** — бавыр каны. *Тотып күңелдә җигәр хун.* (Г. Кан.) — Кровь печени.

**Җидаль** جدال *м. III.* Кычкырышу, талашу, гауга, низаг чыгару. *Һәм дә җәнҗалдан, җидальдән кыл кадәр ис кермәсен.* (Г. Тук.) — *м. III.* Спор, прения; скандал, ссора.

**Җидар** جدار *ис.* Койма, дивар, киртә. — *сущ.* Стена, ограда, забор.

**Җид** جد *ис.* 1) Тырышлык, тырышу, көч кую. 2) Җитдилек. — *сущ.* 1) Усердие, старание, труд. 2) Серьёзность.

**Җидди*** جدى *с.* Чынлыклы, җитди, уен-көлке түгел. — *прил.* Серьёзный, нешуточный.

**Җиддият** جديات Җиддиять-нең *к.* — *мн.* от җиддиять.

**Жиддиять** جدیت *ис.* Житдилек, тырышучанлык, көч куючанлык, игътибар белән эш итүчәнлек. *Ул житдиять вә самимиять белән сөйләп барды* (Г. Газиз). — *сущ.* 1) Серьёзность, усердие, старательность. 2) Внимательное отношение.

**Жиддән** جدًا *р.* Чынлап, дөрестән, үен-көлкесез. — *н.* Серьёзно, ревностно.

**Жизия (жәзия)** جزیه *ис. тар.* Ислам дәүләтләрендә мөселман булмаган кешеләр түли торган налог (салым). — *сущ. ист.* Подушная подать, которую платили в мусульманских старанах иноверцы.

**Жила (жәлә)** جلا *ис.* 1) Ялтыравык. *Күзгә куәт вә жила бирер.* (К. Нас.) 2) Ялтыратылган. — *сущ.* 1) Блеск, лоск. 2) Полированный.

**Жилвә** جلوه *ис.* 1) Ялтырау, балку. 2) Торышта, хәрәкәттә матурлык. 3) Купшылык, көязлек. 4) Кыланчыклык. 5) Кызның киявенә беренче мәртәбә йөзен күрсәтүе. — *сущ.* 1) Блеск, сияние. 2) Статность, стройность. 3) Щегольство. 4) Кокетство, игривость. 5) Снятие покрывала с лица невесты.

**Жилвәгәр** جلوگر *гф. с.* 1) Балкучы; ялтыраучы, нурлы, нур чәчеп балкып тора торган. 2) Күренеп үтүче. — *ар.-п. прил.* 1) Сияющий, лучезарный; блестящий. 2) Кажущийся, появляющийся.

**Жилвәкяр (жилвә саз)** جلوكار *гф. с.* 1) Нурлы, балкулы. 2) Нәзакәтле; сокланырлык матур; купшы, көяз. — *ар.-п. прил.* Лучистый, блестящий. 2) Изящный, прелестный; прекрасный, щегольский.

**Жилвә фруш** جلوەفروش *гф. ис.* 1) Чытлык, кыланчык. 2) Чытлыклык, кыланчыклык. — *ар.-п. сущ.* 1) Кокетливый, кокетка. 2) Кокетство, щегольство.

**Жилд** جلد *ис.* 1) Тире. 2) Китапның катыргы тышы. 3) Том (бер китапның аерым-аерым төпләнгән өлешләре). 4) Данә, китап хисабының берәмлеге. — *сущ.* 1) Кожа, шкура. 2) Переплёт (книги). 3) Том, книга. 4) Экземпляр, нумератив при счёте книг.

**Жим** جیم *ис.* „Ж" хәрефенең исеме. *Мимгә өс, жимгә сәкен һәм нун батыр ну, нун сәкен* (мәжнүн). (Ш. Баб.) — *сущ.* Название буквы „дж".

**Жин*** جن *ис. миф.* Жен, пәри. — *сущ. собир. миф.* Духи, демон.

**Жинан** جنان Жәннәт-нең *к.* *Аяк баскан жирем барсы, гөлстан бер жинаннардан.* (С. Рәми.) — *мн.* от жәннәт.

**Жинас** جناس *м. III.* 1) Сүз уйнату. 2) Мәгънәдәш һәм аваздаш сүзләрне һәр ике мәгънәсен аңларлык итеп куллану. — *м. III.* 1) Игра слов 2) Созвучие двух сходных по произношению слов.

**Жинаять*** جنايت *ис.* Жинаять, закон бозу. — *сущ.* Преступление, проступок.

**Жинаять пәрвәр** جنايتپرور *гф. ис.* Жинаятьче. *Кем һөҗүм итте, пәдәр, һанки җинаять пәрвәран?* (Г. Тук.) — *ар.-п. сущ.* Преступник.

**Жинни** جنى *с.* Жен(гә бәйләнешле), женле. — *прил.* Сумасшедший, дьявольский, чудовищный.

**Жиран** جيران Жар-ның *к.* — *мн.* от жар.

**Жирахи** جراحى *с.* **1.** Хирургия(гә бәйләнешле). **2.** Хирург. — *прил.* **1.** Хирургический **2.** Хирург.

**Жисем*** جسم *ис.* 1) Жисем 2) Гәүдә, тән. *Калса исмең шул җитәр, җисемеңне монда саклама!* (Ш. Баб.) 3) Матдә. — *сущ.* 1) Тело. 2) Корпус. 3) Масса, вещество.

**Жисер** جسر *ис.* Күпер. — *сущ.* Мост.

**Жисмани (жисмания)** جسمانى *с.* 1) Гәүдә(гә), тән(гә бәйләнешле). *Язу рухани һәндәсәдер, аләте җисмания беләя зоһур итте.* (К. Нас.) 2) Физик. 3) Матдә(гә караган), матди. — *прил.* 1) Телесный. 2) Физический. 3) Вещественный.

**Жисмән** جسماً *р.* Гәүдә ягыннан, гәүдә буларак. *Мин хәзер шундый кеше: җисмән дә кол, фикрән дә кол.* (Г. Сонг.) — *н.* Телом

**Жифә** جيفه *ис.* Үләксә, үле тән. *Ала карга кеби сез җифәләргә улдыгыз дәлләл.* (Г. Тук.) — *сущ.* Падаль, мертвечина, труп.

**Жиядәт** جيادت *ис.* Бик шәплек, бик яхшылык, сафлык. — *сущ.* Чистота, непорочность

**Жиһад** جهاد *м. III.* Изге сугыш, сугыш. — *м. III.* Священная война.

**Жиһаз*** جهاز *ис.* 1) Бер эш өчен кирәк булган әсбаплар, кораллар, әйберләр, берәр эш өчен кирәк-яраклар. 2) Өй кирәк-яраклары, мебель. *Син беләмсең бу биналар, бу җиһазлар кемнеке?* (Ә. Сәгъ.) — *сущ.* 1) Всё необходимое; снаряжение; оборудование. 2) Домашние вещи, мебель.

**Җиһан*** جهان *ф. ис.* Дөнья, галәм. *Кузгал, эшчеләр, таң калсын җиһан.* (М. Гаф.) — *п. сущ.* Мир, вселенная.

**Җиһанара** جهان‌ارا *ф. с.* Бөтен дөньяны бизәп (нур биреп) тора торган, дөнья күрке, дөньяга зиннәт бирүче. — *п. прил. букв.* Украшающий вселенную, освещающий своими лучами весь мир.

**Җиһанбаз** جهانباز *ф. с.* 1) *дини* Дөньяны саклап торучы (алла). 2) Патша. — *п. прил.* 1) *рел.* Миродержец; бог. 2) Хранитель мира; государь.

**Җиһангир** جهانگير *ф. ис.* Дөньяны үзенә каратучы, дөньяны яулап алучы. — *п. сущ.* Повелитель вселенной, покоритель мира.

**Җиһандидә** جهانديده *ф. с.* Күпне күргән, күп яшәгән, күп гизгән; тәҗрибәле. — *п. прил.* Много повидавший, поживший; опытный, бывалый.

**Җиһандар** جهاندار *ф. с.* Дөньяның иясе; хөкемдар, патша. — *п. прил.* Обладатель мира, повелитель.

**Җиһанәфруз** جهان‌فروز *ф. с.* Дөньяны яктыртып торучы, нурландыручы. — *п. прил. букв.* Украшающий мир своими лучами.

**Җиһар** جهار *ис.* 1) Кычкырып уку (яки сөйләү). 2) Ачыклык, билгелелек. — *сущ.* 1) Громкое чтение (или громкая речь). 2) Явность, известность, гласность.

**Җиһарән** جهاراً *кара:* җәһрән. — *см.* Җәһрән.

**Җиһат** جهات Җиһәт-нең *к.* *Ияртеп гаскәрен саф-саф, тезеп һәр дүрт җиһатенә.* (Г. Тук.) — *мн.* от **җиһәт**.

**Җиһәт (җәһәт)** جهت *ис.* Як, тараф; җәһәт. *Бер җәһәттән эш сорап, икенче яктан садака соранып, бераз нәрсәләр җыйды.* (М. Гаф.) — *сущ.* Бок, сторона; направление.

**Җомга*** جمعه *ис.* 1) Җыелып укыла торган намаз. 2) Җыелып намаз укый торган көн, атнаның алтынчы көне исеме. 3) Атна. *Бу маҗаралардан ике җомга мөкаддәм.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Молитва, совершаемая вместе, коллективно. 2) День коллективного совершения молитвы, пятница. 3) Неделя.

**Җуг** جوع *ис.* Ачлык; ачыгу. — *сущ.* 1) Голод, недоедание. 2) Голодовка.

**Җулаһ** جولاه *ф. ис.* Тукучы. *Бер вакыт бер җулаһ бер күлмәк тукыды* (Көлкенамә). — *п. сущ.* Ткач.

**Җуш** جوش *ф. ис.* 1) Кайнау. *Шу дикле гыйшнуш итдем, сафа вә зәүкы* — *п. сущ.* 1) Кипение. 2) Возбуждение.

*җуш итдем.* (Г. Кан.) 2) Уяту, кузгалу, тудыру, дулкынландыру.

**Җәбан** جبان *с.* Куркак, өркәк. — *прил.* 1. Трусливый, боязливый. 2. Трус.

**Җәбанәт (җибанәт)** جبانت *ис.* Куркаклык, курку, өркүчәнлек. *„Мин арслан!“ ди синең малны тәләф иткәндә ул. Син аңар калсаң, „фәкыйрьмен“,— ди, җәбанәт күрсәтә.* (Г. Тук.) — *сущ.* Трусость, боязливость, боязнь, малодушие.

**Җәббар** جبار *с.* 1) Бик көчле, бик куәтле, зур көч (куәт) иясе. 2) Алла. *Аздырырмын дөньяны, бел җәббарым.* (Ш. Баб.) 3) Бик кысрыклаучы, җәберләүче. *Ире Җәлальне хаксыз рәвештә үзенә хуҗалык итмәктә булган бер залим, бер җәббар кебек тоя.* (Г. Ибр.) 4) *астр.* Орион. — *прил.* 1) Могущественный, могучий. 2) Эпитет аллаха. 3) Жестокий; немилосердный. 4) *астр.* Орион.

**Җәбер*** جبر *ис.* 1) Золым, җәбер, каһәр; көчләү, ирексезләү, каһәрләү, кыерсыту. *Нишлисең соң, безгә тәкъдирнең зәһәрле җәбере бу.* (Ш. Баб.) 2) Алгебра. — *сущ.* 1) Гнёт, принуждение, насилие; обида. 2) Алгебра.

**Җәбин I** جبين Куркак, йөрәксез. — *прил.* Трусливый, малодушный.

**Җәбин II** جبين *кара:* җәбһә. — *см.* Җәбһә.

**Җәбирә** جبيره *ис. мед.* Яра өстенә ябылган нәрсә, яраны каплап бәйләгән чүпрәк. — *сущ. мед.* Лубок, шина, бандаж.

**Җәбраил*** جبرائيل *кара:* җибрил. — *см.* Җибрил.

**Җәбри** جبرى *с.* 1) Ирексездән, көчләнеп эшләнгән. 2) Алгебраик. — *прил.* 1) Принудительный, насильственный, вынужденный. 2) Алгебраический.

**Җәбрән** جبراً *р.* Ирексезләп, көчләп. *Бармасаң, җәбрән бирермез.* (М. Ак.) — *н.* По принуждению, вынужденно, насильно.

**Җәбә** جبه *ф. ис.* Корыч кием, күбә (сугыш киеме). — *п. сущ.* Доспехи, броня, латы.

**Җәбәл** جبل *ис.* Тау. — *сущ.* Гора.

**Җәбәли** جبلى *с.* Тау(га караган), тау(га бәйләнешле). — *прил.* Горный.

**Җәбәрут** جبروت ис. Тулы көчлелек, һәммә нәрсәгә көч җитүчелек. — *сущ.* Мощь, сила, могущество.

**Җәбһә** جبهه *ис.* 1) Маңгай. 2) Йорт һәм өйләрнең ал ягы, фасад. 3) Фронт. — *сущ.* 1) Лоб. 2) Передняя часть здания, фасад. 3) Фронт.

**Җәвад** جواد *ис.* 1) Юмарт, киң күңелле кеше. 2) Аргамак, нәселле ат; йөгерек ат, тулпар.
*сущ.* 1) Щедрый, великодушный человек. 2) Аргамак; породистая лошадь; скакун, рысак.

**Җәваз** جواز *ис.* Дөреслек, дөрес булу, ярау, эшләргә ярау. *Театрга баруның җәвазына бирәр гыйбарә таптыгызмыни соң.* (Ф. Әмир.)
*сущ.* Допустимость, позволительность; законность, разрешение.

**Җәвамиг** جوامع Җамигъ-ның *к.*
*мн.* от җамигъ.

**Җәван** جوان *ф. ис.* 1) Яшь. 2) Яшь егет. *Шунда бардыр бер мөселман пәһлеван, бик озын, бик көчле, гайрәтле җәван.* (Г. Тук.)
*п. сущ.* 1) Молодой, юный. 2) Юноша, молодой человек.

**Җәванмәрд** جوانمرد *ф. с.* Мөхтәрәм кеше; юмарт, шәфкатьле. *Шөкер кыла белмәгән кешегә ихсан кыйлып җәванмәрдлек иткәннең җәзасы ошбудыр.* (К. Нас.)
*п. прил.* Благородный, великодушный, щедрый.

**Җәваниб** جوانب Җаниб-нең *к.*
*мн.* от җаниб.

**Җәваһир** جواهير Җәүһәр-нең *к.*
*мн.* от җәүһәр.

**Җәвлан** جولان *кара:* җәвәлан.
*см.* Җәвәлан.

**Җәвәлан** جولان *ис.* Әйләнеш, әйләнеп йөреш, хәрәкәт, эш итү.
*сущ.* 1) Блуждание; хождение. 2) Вращение; деятельность.

**Җәвәләнгяһ** جولانگاه *гф. ис.* Әйләнеп йөргән (эш иткән) урын; мәйдан, арена; сугыш кыры. *Иске вакытлардан бирле төрек каумнарының җәвәләнгяһы булган киң сахраларда табылган иске язулар.* (Р. Фәх.)
*ар.-п. сущ.* Арена, поле деятельности; площадь; поле битвы.

**Җәгъли** جعلى *ис.* 1) Ясалма, уйдырма. 2) Охшатып эшләнгән, чын түгел. *Сәедгәрәй шул җәгъли чалбар белән эре генә йөрергә чыккан иде* (Г. Газиз).
*сущ.* 1) Искусственный, надуманный. 2) Поддельный; фальшивый.

**Җәгърафи (җогърафи)** جغرافى *с.* География(гә бәйләнешле), географик.
*прил.* Географический.

**Җәгърафия (җогърафия)** جغرافيه *ис.* География.
*сущ.* География.

**Җәдавил** جداول Җәдвәл-нең *к.*
*мн.* от җәдвәл.

**Җәдвәл** جدول *ис.* Таблица, расписание, җәдвәл. *Үзләре чөн төзделәр иң әүвәле мәңгелек тәфсыйллы „шәйтан җәдвәле“.* (Ш. Баб.)
*сущ.* Таблица; парадигма; список; расписание; перечень; диаграмма.

**Жәд** جد *ис.* Дәү ата, дәү әти, баба, карт ата.
*сущ.* 1) Дед. 2) Предок.

**Жәддә** جده *ис.* Дәү ана, дәү әни, әби.
*сущ.* Бабушка.

**Жәди** جدى *ис.* 1) Кәҗә бәтие. 2) Зодиак тамгасы буенча егерме икенче декабрьдан егерме икенче январьгача булган вакыт; Иран ел хисабы буенча 10 нчы ай.
*сущ.* 1) Козлёнок. 2) Козерог (знак зодиака, соответствующий 10-му месяцу иранского солнечного года, от 22 декабря до 22 января).

**Жәдид*, жәдидә** جديد، جديده *с.* 1) Җәдит, яңа. 2) Яңалык, „җәдитлек" хәрәкәте ягындагы кешеләргә бирелгән исем. *Мин түгел, ди, абзарауны һәм түгелмен, ди, җәдид.* (Г. Тук.)
*прил.* 1) Новый, новейший; недавний, последний. 2) Последователь „джадидизма" (общественное течение конца XIX и начала XX века среди тюркских народов России).

**Жәдир** جدير *с.* Ятышлы, лаек.
*прил.* Достойный, заслуживающий (чего-либо).

**Жәдри** جدرى *ис. мед.* Чәчәк (авыру).
*сущ. мед.* Оспа.

**Жәдри кязиб** جدرى كاذب *ис.* Су чәчәге.
*сущ. мед.* Ветряная оспа.

**Жәдәл** جدل *ис.* Бәхәсләшү, сүз көрәштерү, тартышу. *Гыйльме җәдәл* — логика нигезендә сүз көрәштерү гыйлеме, диалектика. *Әбүйосыф гыйльме җәдәлне үгрәнмәк диндә зиндикълык пәйдә кылыр диде.* (К. Нас.)
*сущ.* Спор, прения, дебаты.
Диалектика.

**Жәеб** جيب *ис.* 1) Синус. 2) Яка ачыклыгы. 3) Кесә. *Дөрр мәгънә җәебеңә тулмак кирәк.* (Ут. Им.)
*сущ.* 1) Синус. 2) Выем воротника. 3) Карман.

**Жәзаә* (җәза)** جزاء *ис.* 1) Җәза. 2) Үч алу.
*сущ.* 1) Наказание; взыскание. 2) Возмездие.

**Жәзаир** جزائر Җәзирә-нең *к.*
*мн.* от җәзирә.

**Жәзаән** جزاً *р.* Җәза йөзеннән, җәза итеп.
*н.* Наказывая.

**Жәзгъ** جذع *ис.* 1) Кәүсә; сабак. 2) Гәүдә, тән.
*сущ.* 1) Ствол; стебель. 2). Туловище, тело.

**Жәзеб** جذب *ис.* 1) Үзенә тарту. 2) Тартып алу, суырып тартып китерү. 3) *дини* Гыйбадәттә шашу дәрәҗәсенә җитү.
*сущ.* 1) Влечение. 2) Привлечение. 2) *рел.* Экстаз, исступление.

**Җәзем** جزم *ис.* 1) Кисү. 2) Кискен карарга килү; кискен итеп сүз бирү. 3) *грам.* Киләчәк заман фигыленең ахыры киселеп (сәкен белән) укылу. 4) *грам.* Кисү билгесе — сәкен. — *сущ.* 1) Усечение. 2) Решительность; решимость. 3) *грам.* Постановка глагола в усечённом наклонении. 4) *грам.* Значок безгласия — сукун.

**Җәзер I** جذر *ис.* 1) Тамыр, үсемлек тамыры. 2) *мат.* Тамыр билгесе. — *сущ.* 1) Корень. 2) Основа. 3) *мат.* Корень.

**Җәзер II** جزر *ис.* Диңгез суының кире кайтуы. — *сущ.* Отлив (морской).

**Җәззар** جزار *ис.* 1) Сугымчы, итче. 2) *күч.* Кан эчүче, мәрхәмәтсез, кансыз. — 1) Мясник. 2) *перен.* Кровопийца, кровосос; жестокий.

**Җәзил** جزيل *с.* Күп, мул. *Кәсептә әҗер җәзил булыр.* (Г. Фәез.) — *прил.* Обильный.

**Җәзирә** جزيره *ис.* Атау, утрау. *Ихлас дәрьясында йөзсен безнең караб, китсен тугры гыйрфан җәзирәсен карап.* (Г. Тук.) — *сущ.* Остров.

**Җәзәгъ** جزع *ис.* 1) Сабырсызлану. 2) Каушау. 3) Курку. 4) Кайгыру, кайгыга төшү. *Әгәр хәйлә белән дә мөмкин түгел икән, җәзәгъ, фәзгъ кыйлма.* (К. Нас.) 5) Елау, кычкырып елау. — *сущ.* 1) Нетерпение. 2) Встревоженность, озабоченность. 3) Смущение; испуг. 4) Печаль; скорбь. 5) Плач, рыдание.

**Җәйед** جيد *с.* Бик шәп, бик яхшы. — *прил.* Отличный, превосходный.

**Җәйш** جيش *ис.* Гаскәр, армия. — *сущ.* Армия, войско.

**Җәйхун** جيحون *ис.* Аму-Дарья. — *сущ.* Аму-Дарья.

**Җәлеб*** جلب *ис.* Үзенә таба тарту, үзенә карату, җәлеп итү. *Җәлеб итәрлек тиречеләр дикъкатен.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Привлечение. 2) Навлечение.

**Җәлил** جليل *с.* 1) Зур. 2) Бөек; олы дәрәҗәле, кадерле, мәртәбәле. 3) Данлы, шөһрәтле. — *прил.* 1) Большой, огромный. 2) Великий, величественный, славный, великолепный, важный. 3) Знатный, уважаемый; почтенный.

**Җәлилә** جليله Җәлил-нең *мнс.* — *жен.* от җәлил.

**Җәлис** جليس *с.* Бергә утыручы, утырдаш, мәҗлестәш. — *прил.* Приятель; собеседник, компаньон.

**Җәлле** جل *с.* Олы, бөек. — *прил.* Большой, великий.

**Җәлле вә эгъля** جل واعلا *гыйб.* Бик олы мәртәбәле. — *фр.* Очень важный, почтеннейший.

**Җәлляд** جلاد *ис.* 1) Баш кисүче, палач. *Каенанасын күрә төшләрендә, җәлляд булып килә каршына.* (М. Ук.) 2) Бик кансыз, мәрхәмәтсез кеше. — *сущ.* 1) Палач. 2) Жестокий человек; кровосос.

**Җәлсә** جلسه *ис.* 1) Утырыш, мәҗлес. 2) Бер утырып алу; утыру кыяфәте... — *сущ.* 1) Заседание, собрание. 2) Посадка, манера сидеть.

**Җәлядәт** جلادت *ис.* 1) Ныклык, чыдамлык. 2) Егетлек, батырлык, йөрәклелек, кыюлык. — *сущ.* 1) Стойкость, выносливость, терпение. 2) Смелость, мужество; храбрость.

**Җәлял** جلال *ис.* Бөеклек, олылык. — *сущ.* Величие, блеск, великолепие.

**Җәляләт** جلالة *ис.* 1) Олылык. 2) Югары дәрәҗәлелек, галиҗәнаблык. — *сущ.* 1) Величие. 2) Превосходительство, величество (титулы).

**Җәмагать*** جماعت *ис.* 1) Җыелган халык, җыелган кешеләр төркеме. 2) Бер урында бергә яшәүче халык. 3) Берәүнең хатыны. 4) Өй кешеләре. — *сущ.* 1. Группа людей, толпа. 2) Общество, община. 3) Жена. 4) Домашние.

**Җәмад** جماد *ис.* Җансыз, органик булмаган әйбер. — *сущ.* Минерал, неорганическое вещество.

**Җәмадат** جمادات Җәмад-ның *к.* — *мн.* от җәмад.

**Җәмал** جمال *ис.* Матурлык, чибәрлек, йөз матурлыгы, гүзәллек, ягымлылык, ямьлелек. *Гүзәлсең алтын алмадай, җәмалең күңлем аулады.* (Г. Кан.) — *сущ.* Красота, миловидность, привлекательность.

**Җәмганъ** جمعا *р.* Бергәләп, барысы бергәләшеп, барысы бер булып, җыйнаулашып. — *н.* Вместе, совместно, сообща.

**Җәмгъ** جمع *ис.* 1) Җыю, туплау. 2) *мат.* Кушу. 3) *грам.* Күплек. 4) Барысы, бөтенесе. *Шунда картлар җәмгъ улып киңәштеләр.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Собирание, сбор. 2) *мат.* Сложение. 3) *грам.* Множественное число. 4) Всё, все.

**Җәмгыяте бәшәрия** جمعيت بشريه *ст.* Кешелек җәмгыяте. — *сс.* Человеческое общество.

**Җәмгыяте хәйрия** جمعيت خيريه *ст.* Ярдәм күрсәтү җәмгыяте. — *сс.* Благотворительное общество.

**Җәмгыять*** جمعيت *ис.* 1) Җәмгыять. 2) Җыен, күп халык. 3) Җәмгыять, берләшмә, оешма, бер максат белән берләшкән халык төркеме. — *сущ.* 1) Общество. 2) Собрание, толпа. 3) Союз, ассоциация.

**Жәмигъ** جميع *с.* Бөтен, барлык, һәммә. *Жәмигъ авыл аны тәгъзыйм идеп* ... (М. Ак.)

*прил.* 1) Весь, вся, всё. 2) Совокупность.

**Жәмиганъ** جميعاً *р.* Барысы бергә, бары да.

*н.* В совокупности, вместе; целиком.

**Жәмил, жәмилә** جميل، جميله *с.* Матур, гүзәл, күркәм, яхшы, чибәр. *Әүсафе жәмилә*— күркәм сыйфатлар.

*прил.* Красивый, прекрасный, миловидный, привлекательный.

**Жәммад** جماد *кара:* жәмад.

*см.* Жәмад.

**Жәнаб*** جناب *ис.* Берәүне олылау йөзеннән әйтелә торган сүз.

*сущ.* Господин, превосходительство (обращение к высокопоставленным лицам).

**Жәнабе мән ләһелфәрман** — боеру аның кулында булган зат. *Вирер дәрмани дә шаять, жәнабе мән ләһелфәрман.* (Г. Тук.)

Всемогущее существо (о боге).

**Жәнабе гали** جناب عالى *ст.* Өстенлек иясе, барыннан да өстен булган зат, бик хөрмәтле.

*сс.* 1) Превосходительство (титул). 2) Высокопоставленный, почтенный (о личности).

**Жәназа*** جنازه *ис.* 1) Күмәргә хәзерләнгән мәет. 2) Мәет күмү.

*сущ.* 1) Покойник, подготовленный для погребения. 2) Похороны, похоронная процессия.

**Жәнан** جنان *ис.* Йөрәк, күңел.

*сущ.* Сердце, душа.

**Жәнах** جناح *ис.* Канат.

*сущ.* Крыло.

**Жәнеб** جنب *кара:* жаниб.

*см.* Жаниб.

**Жәнин** جنين *ис.* Ана карынындагы яралгы. *Бала жәнин мәшимә эчендә ике кулын тезенә куеп вә күзләрен ике кул аркасына куеп, туп кеби йомарлак булыр.* (К. Нас.)

*сущ.* Зародыш, эмбрион.

**Жәнк** جنك *ф. ис.* Сугыш, бәрелеш. *Баһадирларча мөлакый булып жәнк кылдым.* (К. Нас.)

*п. сущ.* Война, битва, сражение, бой.

**Жәннәт*** جنت *ис.* 1) Бакча. 2) *дини* Ожмах.

*сущ.* 1) Сад. 2) *рел.* Рай.

**Жәнүб** جنوب *ис.* Көньяк. *Аккош китә „һаң" итеп, жәнүб таба юл тотып.* (М. Ук.)

*сущ.* Юг.

**Җәнүби** جنوبی *с.* Көньяк(ка бәйләнешле). — *прил.* Южный.

**Җәнүбән** جنوباً *р.* Көньяктан. — *н.* С юга; южнее.

**Җәнҗал*** جنجال *ф. ис.* Гауга, шау-шу, ызгыш. — *п. сущ.* Скандал, гвалт, дрязги.

**Җәрад** جراد *ис.* Саранча. — *сущ. соб.* Саранча.

**Җәраид** جرائد Җәридә-нең *к.* *Ятар өстәлендә дөрле җәраид.* (Г. Тук.) — *мн.* от җәридә.

**Җәрахәт*** جراحت *ис.* Яра. — *сущ.* Рана, язва.

**Җәрех** جرح *ис.* 1) Яралау. 2) Рәнҗетү, хурлау, ялганга чыгару. *Сүз сөйләмәс бәрәүне җәрех кылмай.* (Ак.) — *сущ.* 1) Ранение, порез. 2) Оскорбление, клевета (на кого-либо).

**Җәридә** جریده *ис.* Газета (төп мәгънәсе борын заман салым җыючыларның салым салырга тиешле җирнең үлчәвен яза торган кәгазь яки дәфтәрләре). *Җәридә файдасы чукча мөҗәррәбдер бу галәмгә.* (Г. Тук.) — *сущ.* Газета.

**Җәримә** جریمه *ис.* 1) Гаеп, гөнаһ. 2) Штраф. — *сущ.* 1) Преступление, грех. 2) Штраф.

**Җәриә** جری *с.* Кыю, батыр, куркусыз. — *прил.* Смелый, отважный, неустрашимый.

**Җәр** جر *ис.* 1) Өстерәү, тарту. 2) *грам.* Исемне кыек килештә кую. 3) Үз ягына тарту. *Хруфе җәр* — исемнәрне „и“ белән укырга тиешле итә торган бәйлекләр. — *сущ.* 1) Волочение. 2) *грам.* Постановка существительного в родительном падеже. 3) Тянущий в свою сторону.

**Җәррар** جرار *ис.* 1) Сорап йөдәтүче һәм сораганын алмый китми торган теләнче. 2) Баер өчен теләнеп йөрүче теләнче. — *сущ.* 1) Надоедающий просьбами; пристающий; надоедливый. 2) Нищенствование с целью наживы.

**Җәрре әскаль** جراثقال *ст.* Механика фәне. *Җәрре әскаль фәнендә маһирләр ... агыр ташны бер җирдән икенче җиргә ансатлык белән китерерләр.* (Г. Фәез.) — *сс.* Механика.

**Җәрәян** جریان *ис.* 1) Агу, агып тору; үтү. 2) Булу, булып узу. *Халык арасында дөрле-дөрле тәфәккерләр җәрәян әйләде.* (М. Ак.) — *сущ.* 1) Течение, ход; движение. 2) Прохождение.

**Җәсамәт** جسامت *ис.* Эрелек, зурлык, мәһабәтлек. — *сущ.* Большой размер, огромность, солидность.

**Җәсарәт** جسارت *из.* Батырлык, кыюлык, йөрәклелек. *Һичбер инсан аңа каршы дорырга җәсарәтләнмәс иде.* (М. Ак.) — *сущ.* Смелость, храбрость, мужество, неустрашимость.

**Җәсим** جسيم *с.* 1) Эре, зур, олы. 2) Гәүдәле, күләмле, тулы гәүдәле. — *прил.* 1) Большой, огромный. 2) Дородный, солидный.

**Җәсәд** جسد *ис.* Гәүдә. *Без китәбез, сез каласыз дип — җырлармын, җәсәдемне туфрак белән күмгәндә дә.* (Г. Тук.) — *сущ.* Тело, плоть.

**Җәсүр** جسور *ис.* Батыр, гайрәтле, кыю. *Алар алдарлар, алдансаң, җәсүр мөфти дә юк дирләр.* (Г. Тук.) — *сущ.* Очень смелый, храбрый, дерзкий.

**Җәфа*** جفا *ис.* 1) Җәфа, азап, авырлык. 2) Иза чигү. — *сущ.* 1) Притеснение, обида. 2) Мучение.

**Җәфакяр** جفاكار *гф. с.* Җәфалаучы, җәфа чиктерүче. — *ар.-п. прил.* Притеснитель, мучитель.

**Җәфакәш** جفاكش *гф. ис.* Җәфа чигүче, җәфаланучы. — *ар.-п. сущ.* 1) Притесняемый, угнетаемый. 2) Мученик, страдалец.

**Җәфн (җәфен)** جفن *ис.* Күз кабагы. — *сущ.* Веко.

**Җәффелкаләм** جفالقلم *гыйб.* Уйламастан язып (сөйләп) ташлау, уйламыйча хөкем итү. — *фр.* Необдуманно сказать (написать, решить) что-либо.

**Җәхед** جحد *ис.* 1) Тану, инкарь итү. 2) Ышанмау. 3) *грам.* Киләчәк заман фигыленнән үткән заманның юклыгын ясау формасы. — *сущ.* 1) Отрицание, непризнание. 2) Неверие. 3) *грам.* Постановка глагола в усечённом наклонении (с отрицательной частицей „лям“).

**Җәхим** جحيم *ис. дини* Тәмуг, җәһәннәм уты. *Мөхәррирләр сәбәб диндә сәбатә, ике дөнья җәхименнән нәҗатә.* (Г. Тук.) — *сущ. рел.* Адский огонь.

**Җәхуд** جحود *ис.* 1) Кире кагу, инкарь итү; танымау, баш тарту. 2) Ышанмау. *Ишеттекчә сөннәти улма җәхуд.* (Ут. Им.) — *сущ.* 1) Отрицание, непризнание. 2) Неверие.

**Җәяф** جياف *ис.* Кабер ачып, кәфен талаучы кеше. — *сущ.* Грабящий могилы (снимающий одежду с покойников).

**Җәүве** جو *ис.* Җирне чолгап алган һава, атмосфера. *сущ.* Воздух, атмосфера.

**Җәүдәт** جودت *ис.* 1) Яхшылык, һич кимчелексез булу, саф булу. 2) Өстенлек. *сущ.* 1) Доброта, непорочность. 2) Превосходство; высокое качество.

**Җәүза** جوزا *ис.* Игезәкләр (зодиак тамгасы, май ае тамгасы). *сущ. астр.* Созвездие Близнецов.

**Җәүр** جور *ис.* Урынсыз азаплау, хаксыз рәнҗетү, золым, җәфалау, кысу, изү. *Нидер бу дәүләт кем, шөкер итмәк чук; минем беркемгә җәүр итәр көчем юк.* (Дәрд.) *сущ.* Притеснение, насилие, жестокость, несправедливость; произвол.

**Җәүф** جوف *ис.* 1) Эч, эчке як, урта. 2) Куышлык, бушлык. *сущ.* 1) Полость, внутренность, недра. 2) Пустота.

**Җәүһәр* (гәүһәр)** جوهر *ис.* 1) Кыйммәтле таш (алмаз, якут, зөбәрҗәт, фирүзә кебек ташлар); кыйммәтле әйбер. *Кызны котлап җәүһәр муенсалар, беләзекләр бүләк иттеләр.* (М. Җәл.) 2) Асыл, төп яратылыш, үвенчәлек. *сущ.* 1) Драгоценный камень (алмаз, жемчуг, бриллиант и т. п.), драгоценность. 2) Суть, сущность, существо, основное свойство.

**Җәүһәре фәрд** جوهرفرد *ст.* Матдәнең артык бүленә алмый торган иң вак кисәге, атом. *сс.* Неделимая часть вещества, атом.

**Җәүһәр фруш** جوهرفروش *гф. ис.* Асыл ташлар белән сату итүче. *Күрсәткел җәүһәр фрушкә бер йирдә хали.* (Мөхм.) *ар.-п. сущ.* Продавец драгоценных камней.

**Җәүһәр шинас** جوهرشناس *гф. ис.* Асыл ташлар белгече. *Җәүһәр шинас диде: „Бу сиңа кандин килде“.* (Мөхм.) *ар.-п. сущ.* Специалист по драгоценным камням, ювелир.

**Җәһаләт** جهالت *ис.* Наданлык, аңбелемсезлек. *Иҗек илә башымызны катырдыгыз, җәһаләткә, сәфаләткә батырдыгыз.* (М. Моз.) *сущ.* Невежество, неведение, неопытность.

**Җәһед** جهد *ис.* Тырышу, көч кую. *сущ.* Старание, усилие.

**Җәһел** جهل *ис.* Наданлык, томаналык, белемсезлек, белмәү, белмәүчелек. *Якты көннәр алда әле, җәһел безне алдалый.* (Г. Тук.) *сущ.* Невежество; темнота; неопытность.

**Җәһле мөрәккәб** جهل مرکب *ст.* 1) Белмәү белән бергә үзенең белмәгәнлеген дә белмәү. 2) Бернәрсә дә белмәүче, чип-чи надан. *сс.* 1) Полное неведение, невежество. 2) Полнейший профан, невежда.

**Җәһлән** جهلاً *р.* Белмичә, белмәгән хәлдә, наданлык белән. — *н.* Из-за невежества; не зная, не ведая.

**Җәһр** جهر *ис.* Кычкыру; кычкырып уку (яки сөйләү). — *сущ.* Крик; громкое чтение или громкий разговор.

**Җәһрән** جهراً *р.* Ачыктан-ачык; кычкырып; тавыш белән. *Итмәде тәэсир, чалыштым хәфьятән, җәһрән дә бән.* (Г. Тук.) — *н.* Явно, открыто; громогласно.

**Җәһәлә** جهله Җаһил-нең *к.* — *мн.* от җаһил.

**Җәһәннәм*** جهنم *ис.* Тәмуг. — *сущ.* Ад, преисподняя.

**Җәһәннәми** جهنمی *с.* Җәһәннәмлек. — *прил.* Адский.

**Җәһәт* (җиһәт)** جهت *ис.* Як, тараф. *Һәр җәһәттән хөрриятләр ачылганга, бу көндә хәсрәтемнән шатлыгым күп.* (М. Гаф.) — *сущ.* Сторона, бок, направление.

**Җәһүл** جهول *с.* Бик надан, бик белексез. — *прил.* Крайне невежественный.

**Җөббә** جبه *ис.* Җөббә (җиләннең бер төре). — *сущ.* Джубба (вид одежды).

**Җөбен** جبن *ис.* Курку, куркак булу ... *аны җөбен вә йөрәксез дип зәм кыйлырлар.* (К. Нас.) — *сущ.* Трусость, малодушие.

**Җөгаль** جعل *ис.* Тирес корты, тирес коңгызы (көньякта була). *Җөгальгә на хуш ула буе гөлаб.* (Ут. Им.) — *сущ.* Навозный жук, скарабей.

**Җөда** جدا *ф. ис.* Аерылган, аерылуга дучар булган. *Барча иркеңнән вә циркыңнан җөда булдың, инде бәс сиңа миннән дога.* (Г. Тук.) — *п. прил.* Разъединённый; расставшийся (с кем-либо).

**Җөзам** جزام *ис. мед.* Махау авыруы. — *сущ. мед.* Проказа.

**Җөзаф** جزاف *ис.* 1) Үлчәүсез сөйләү. 2) Үз дәрәҗәсеннән узып ляф ору. *Тел төбендә бер сүзем бар, сүз төбендә бик лаек. Бер җөзаф сүз булса да гәр, бер изахсыз үтмәек.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Необдуманный поступок; необдуманное слово. 2) Хвастовство.

**Җөзә** جزء ، جزو *ис.* 1) Кисәк, өлеш. 2) Бүлек, бүлекчә, парча. — *сущ.* 1) Часть; часть от целого. 2) Доля, частичка.

**Җөзьән ля ятәҗәзза** جزءلايتجزى *гыйб.* Тагын да кисәкләргә бүленә алмый торган кисәк, атом. *Җөзьән ля ятәҗәзза кабиленнән хәрдәбин аркы-* — *фр.* Неделимая часть, атом.

*лы карап та көч белән күренә торган кечкенә хайваннар бардыр.* (К. Нас.)

**Җөзэ фәрд** جزوٴفرد *ис.* Атом. — *сущ.* Атом.

**Җөзьи** جزئی *с.* 1) Әйбернең бер өлешенә бәйләнешле, бик аз. 2) Вак, кечкенә; әһәмиятсез. — *прил.* 1) Частичный, частный. 2) Мелкий, незначительный; пустячный.

**Җөзьият** جزئیات Җөзьи-нең *к.* — *мн.* от җөзьи.

**Җөлаб** جلاب *ф. ис.* 1) Роза чәчәге суы. 2) *мед.* Йомшаткыч дару. *Шифа җөлаб бар матур күзеңдә.* (Дәрд.) — *п. сущ.* 1) Розовая вода (сок розы). 2) Смягчающее средство.

**Җөлүс** جلوس *ис.* 1) Утыру. 2) Тәхеткә утыру. — *сущ.* 1) Сидение. 2) Восшествие (на престол).

**Җөмадиәлахир** جمادی الاخر *гыйб.* Ай елының алтынчы ае исеме. — *фр.* Название шестого месяца лунного календаря.

**Җөмадиәләүвәл** جمادی الاول *гыйб.* Ай елының бишенче аеның исеме. — *фр.* Название пятого месяца лунного календаря.

**Җөмлә*** جمله *ис.* 1) *грам.* Җөмлә. 2) Бөтен, барлык, һәммә. *Ни сәбәп соң җөмлә әдна бәндәләрдән бән дәни.* (Г. Тук.) 3) Иш, рәт, исәп. *Ул фөнүне әдәбия җөмләсеннән бер фәндер.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) *грам.* Предложение. 2) Совокупность, всё, сумма, итог. 3) Пара; некоторое количество, одно из ...; счёт.

**Җөмләи могтариза** جمله‌معترضه *ст.* Кереш җөмлә, җәяләр эченә алынган җөмлә. — *сс.* Предложение, взятое в скобки; вводное предложение.

**Җөмләтән** جملةً *р.* Бары бергә; һәммәсе дә, берьюлы, барысы да. *Белмәли сән: җөмләтән дустыр голум әһле сәңа.* (Г. Тук.) — *н.* Все сразу, целиком.

**Җөмәл** جمل Җөмлә-нең *к.* — *мн.* от җөмлә.

**Җөмһүр** جمهور *ис.* 1) Җәмәгать, халык, гомум халык. 2) Җәмгыять, груһ. — *сущ.* 1) Толпа, масса, публика, народ. 2) Общество, группа.

**Җөмһүри** جمهوری *с.* 1) Җөмһүр(гә бәйләнешле). 2) Республика(га караган). — *прил.* 1) Общий, народный. 2) Республиканский.

**Җөмһүрият** جمهوریت *ис.* Республика. — *сущ.* Республика.

**Җөмһүрияте мөттәхидә** جمهوریت متحده *ст.* Союздаш республика; федератив республика. — *сс.* Союзная республика; федеративная республика.

**Җөнд** جند *ис.* Гаскәр, армия. — *сущ.* Войско, армия.

**Җөнуд** جنود Җөнд-нең *к.* — *мн.* от җөнд.

**Җөнүн** جنون *ис.* 1) Акылдан язучылык. 2) Ярсу. — *сущ.* 1) Безумие, помешательство. 2) Ярость.

**Җөрга** جرعه *ис.* 1) Бер йотым. *Берике җөрга аракыны эчеп* ... 2) *мед.* Доза. (З. Биг.) — *сущ.* 1) Глоток. 2) *мед.* Доза.

**Җөрем** جرم *ис.* Гөнаһ, начарлык, закон чигеннән чыгып эшләнгән эш, закон бозу. — *сущ.* Грех, преступление, нарушение законов.

**Җөрмук (җәрмук)** جرموق *ис.* Ерыклы аяк киеме, шнур белән бәйләп киелә торган аяк киеме. — *сущ.* Шнуровая обувь.

**Җөрьәт*** جرأت *ис.* Батырлык, йөрәклелек, кыюлык, батырчылык. *Мин дә каршы килергә җөрьәт итә алмадым.* (Ш. Кам.) — *сущ.* 1) Смелость, отвага, дерзание. 2) Дерзость.

**Җөссә** جثه *ис.* Гәүдә, җисем. *Бер гарәп кулындагы бер динарга карап: „Ни гаҗәб, синең җөссәң бу кадәр кечкенә, әмма һимматең бик зур",— диде.* (К. Нас.) — *сущ.* Туша (животного); туловище, фигура (человека).

**Җөсстән** جثةً *р.* Гәүдә буларак, гәүдәсе ягыннан. — *н.* Телом, туловищем.

**Җөст** جست *ф. с.* Житез, тиз. *Анасы җөст, чапык купты анда* (Сайяди). — *п. прил.* Расторопный, быстрый.

**Җөфет** جفت *кара:* җефет. — *см.* Җефет.

**Җөюш** جيوش Җәйш-нең *к.* — *мн.* от җәйш.

**Җөһәля** جهلا Җаһил-нең *к.* — *мн.* от җаһил.

**Җөһүд** جهود *ф. ис.* Яһүд, еврей кешесе. — *п. сущ.* Еврей.

**Җү** جو *ф. ис.* Арпа. — *п. сущ.* Ячмень.

**Җүд** جود *ис.* Юмартлык. *Ул вакытлы ракта җүд иясе Мәһләб диган бер вәли бар иде.* (К. Нас.) — *сущ.* Щедрость, великодушие.

# Һ

**Һ** — ه. Татар әлифбасында утыз сигезенче, гарәп әлифбасында егерме җиденче хәреф булып, сан урынында кулланганда 5 санына йөри. — 38-я в татарском алфавите, 27-я буква арабского алфавита. Цифровое значение 5.

**Һабитъ** هابط *сф.* Югарыдан түбән төшүче. — *пр. д.* Падающий, спускающийся.

**һава*** **I** هوا *ис.* 1) Һава; атмосфера. 2) Һава торышы. 3) Берәр җирнең һавасы. — *сущ.* 1) Воздух, атмосфера. 2) Погода. 3) Климат.

**һава II** هوى *ис.* 1) Күңел теләге, кәеф, һәвәс. 2) Гыйшык. 3) Һавалану, борын чөю, тәкәбберлек. *Адәмдә һава калмас гариб булмай, фокара сөхбәтенә кариб булмай.* (Ак.) — *сущ.* 1) Любовь, страсть, увлечение. 2) Причуда, каприз, прихоть. 3) Зазнайство, кичливость.

**һавадар** هوادار *гф. с.* 1) Саф һавалы җир. 2) Һәвәсле; гашыйк. 3) Тарафдар, теләктәш. — *ар.-п. сущ.* 1) Местность с хорошим воздухом. 2) Страстный; влюблённый. 3) Сторонник, единомышленник.

**һаваи** هوائى *с.* 1) Һава(га бәйләнешле). 2) Кәеф китерә торган, кәеф кору(га бәйләнешле). 3) Буш, мәгънәсез; мактанчык, борын чөючән. — *прил.* 1) Атмосферный, воздушный. 2) Вдохновляющий. 3) Пустой, бессмысленный; кичливый.

**һавапәрәст** هواپرست *гф. с.* Җенси дәрткә (гыйшыкка) бирелгән кеше. — *ар.-п. прил.* Отдавшийся страстям.

**һавия** هاويه *ис.* 1) Упкын. 2) Тәмуг. *Барчаңызны да йотар, ди, һавия.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Пропасть, бездна. 2) Ад.

**һади** هادى *сф.* Туры юл күрсәтүче, туры юлга күндерүче. — *пр. д.* Руководитель, предводитель, вожак, указывающий истинный путь.

**һадим** هادم *сф.* Юкка чыгаручы, җимерүче, харап итүче. — *пр. д.* 1) Разрушитель. 2) Разрушающий, уничтожающий.

**һазми** هضمى *с.* Аш сеңдерү(гә бәйләнешле), аш сеңдерә торган. — *прил.* Пищеварительный.

**һазум** هضوم *с.* 1) Күп сеңдерүче. 2) Аш сеңдерүче, аш сеңдерүгә ярдәм итә торган. — *прил.* 1) Пищеварительный. 2) Способствующий пищеварению.

**һазыйм** هاضم *сф.* Аш сеңдерүче, аш сеңдерә торган, аш сеңдерүгә ярдәм итә торган. — *пр. д.* Переваривающий (пищу), способствующий пищеварению.

**һазым** هضم *ис.* Аш сеңдерү, аш үтү. *Сеңдерә алмый саф гакыл һазымы сине.* (Г. Тук.) — *сущ.* Пищеварение.

**һазә** هذا *алм.* Бу. — *мест.* Это.

**һаиб** هائب *с.* Куркак. — *прил.* Испытывающий страх, боязливый.

**һаил** هائل *сф.* 1) Куркынычсала торган, коточыргыч. 2) Бик зур, мәһабәт. — *пр. д.* 1) Страшный, ужасный. 2) Огромный, колоссальный.

**һаилә** هائله *ис.* Коточкыч вакыйга, фаҗига. *һаиләләр ишкенә таба түшәлгән юлмидем.* (М.) — *сущ.* Ужасающее событие, трагедия.

**һакәза** هكذا *р.* Шулай, шулай ук, болай, моның кебек; һаман шул бер көе. — *н.* Так; таким образом; таким путём, всё также.

**Вә һакәза** و هكذا *ст.* һәм башкалар. — *сс.* И так далее.

**һалик** هالك *сф.* һәлак булучы, бетә торган, юкка чыга торган; үлгән; беткән. — *пр. д.* Гибнущий, погибающий; гиблый; умерший.

**һалә** هاله *ис.* Нур боҗрасы (ай яки кояш тирәсендә була торган). — *сущ.* Световое кольцо вокруг солнца или луны; ореол.

**һамиш** هامش *ис.* 1) Китап читенә язылган аңлатма — хашия. 2) Хат язылып бетеп кул куелгач, аска өстәп язылган язу, P. S. (постскриптум). — *сущ.* 1) Комментарий, написанный на полях книги. 2) Послесловие, postscriptum (P. S.).

**һаммә** هامه *ис.* 1) Баш түбәсе. 2) Олылау өчен баш түбәсенә куеп бирелгән хат, гариза. 3) Бөҗәкләр. 4) Сөйрәлүчеләр. — *сущ.* 1) Темень, макушка. 2) Письмо, прошение, подаваемое в знак почтения на голове. 3) Насекомые. 4) Пресмыкающиеся.

**һариб** هارب *сф.* Качучы; качкын. — *пр. д.* 1) Бегущий, сбежавший. 2) Беглец; беглый.

**һатиф** هاتف *сф.* 1) Кычкыручы, тавыш бирүче. 2) Яшерен тавыш, вөҗдан тавышы, гаиптән килгән тавыш, сизенү тавышы. *һатифтән килгән төсле: „әйтмә, хәрап итәсең“ дигән тавыш ишетелә иде* (Г. Газиз). — *пр. д.* 1) Кричащий. 2) Тайный голос (совести, предчувствия).

һаә هاء *ис.* „һ“ хәрефенең исеме. — *сущ.* Название буквы „һ“.

**һаи рәсмия** („ه“) сүз ахырындагы „һ“ хәрефе. — Написание буквы „ه“ в конце слова.

**һаяһу (һайһу)** هایاهو *ф. ым.* Шатлыкны белдерә торган ымлык. *Кая ул шәп һаяһулар, гөфтегүләр бар иде.* (Дәрд.) — *п. межд.* Восклицание радости.

**һибә** هبه *ис.* Бүләк (итеп бирү), буш бирү, багышлау. — *сущ.* Дар, подарок, подношение.

**һидая, һидаять** هدايت ،هدايه *ис.* Туры юлга керү, дөрес юл эзләү теләге. — *сущ.* Вступление на правильный путь, желание найти правильный, истинный путь.

**һидая шәрхе** — китап исеме. *Харам уен-фәләннәрдән за; ар тимәс, ходай кушса, „һидая шәрхе“ намында чуен калканымыз бардыр.* (Г. Тук.) — Название книги.

**һилял** هلال *ис.* Яңа туган ай, айның беренче чирege (7 көне). *Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә, яшь һилял урынында анда тулган айның яктысы.* (Г. Тук.) — *сущ.* Молодой месяц (семидневный), полумесяц.

**һиляле әхмәр** هلال‌احمر *ст.* Кызыл ай оешмасы (җәмгыяте). — *сс.* Красный Полумесяц.

**һимам** همام *ис.* *к.* һиммәт иялəре, Киң күңеллеләр. *һимамга юмартлык хастыр.* (К. Нас.) — *сущ.* *мн.* Достойные, доблестные, великодушные.

**һиммәт** همت *ис.* 1) Ялкынлы дәрт, теләккә омтылу; эше белән кайгыртучанлык күрсәтү. 2) Тырышлык. — *сущ.* 1) Энергия, пыл, усердие, старание, деятельность. 2) Хлопоты, заботы.

**һирас** هراس *ф. ис.* Курку, өркү; хәвеф, шомлану. — *п. сущ.* Страх, ужас; тревога.

**һирр** هر *ис.* Мәче. — *сущ.* Кошка.

**һия** هى *алм.* Ул (хатын). — *мест.* Она.

**һиҗа** هجا *кара:* һәҗа. — *см.* һәҗа.

**һиҗран** هجران *ис.* 1) Сөйгәненнән аерылу, аерылышу. 2) Ачындыру, әрнетү. *Синең мәндин һиҗраның сиңа мәхәббәтемнең пәрдәсен ертты.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Оставление, расставание (с возлюбленным); прекращение отношений. 2) Горечь, душевная боль.

**һиҗри* (һиҗрия)** هجرى ،هجريه *с.* һиҗрәттән башлап йөртелә торган ел исәбенә бәйләнешле. — *прил.* Относящийся к хиджре (мусульманское летоисчисление).

**Сәнәи һиҗрия** — Мөхәммәтнең Мәккәдән Мәдинәгә качуыннан башлап исәпләнеп йөртелә торган ел хисабы. — Хиджра, летоисчисление, которое начинается со дня бегства Мухамеда из Мекки в Медину.

**һиҗрәт*** هجرت *ис.* 1) Күчеп китү, чит илгә китү. *һаҗәр туташ күктән җиргә һиҗрәт иткән, һиҗрәт итеп матурлыкка хезмәт иткән.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Переселение; эмиграция. 2) Бегство Мухамеда из Мекки в Медину (16/VII-622 года

2) Мөхәммәтнең Мәккәдән Мәдинәгә качуы. 3) Мөселманнарның ай хисабы белән йөртелә торган елның башы (16/VII-622 ел миляди). — по христианскому летоисчислению). 3) Начало мусульманского летоисчисления по лунному календарю.

**һома (һөма)** هما *ф. ис.* 1) Бәхет кошы (күләгәсе кемгә төшсә, аңа чиксез бәхет китерә дип йөртелгән мифик кош исеме). 2) „Бәрән карак" бөркет. *һавалар тын ... кисеп очкан һөма юк.* (Дәрд.) — *п. сущ.* 1) Феникс (басословная птица, по поверью приносящая счастье тому, на кого упадёт ее тень). 2) Орёл-ягнятник, бородач.

**һуш*** هوش *ф. ис.* Акыл, аң. *Зәңгәр тулы күзләреңне бер сирпетсәң, бетте инде ... бөтен адәм һуштан яза.* (Ш. Баб.) — *п. сущ.* 1) Разум, ум, рассудок. 2) Сознание.

**һушьяр** هوشيار *ф. ис.* 1) Акыллы, аңлы, аек. 2) Уяу. — *п. прил.* 1) Разумный, рассудительный, понятливый, обладающий ясным умом. 2) Бдительный.

**һәба** هبا *ис.* 1) Тузан; тузан бөртеге. 2) Тузан кебек очып бетү. 3) Буш, файдасыз, нәтиҗәсез. — *сущ.* 1) Мельчайшая пыль; пылинка. 2) Бесследное, как пыль, исчезновение. 3) Пустой, бесполезный, ненужный.

**һәбаән мәнсүра** هباً منثورا *гыйб.* Һавага очкан тузан, һавага чәчелгән тузан (юкка чыгу, җилгә очу мәгънәсендә). *Карчык әйтте: „Каза ирешеп һәммәсе һәбаән мәнсүра булды",— диде.* (К. Нас.) — *фр.* Рассеявшаяся пыль, употребляется в значении „пойти прахом", сделать (что-либо) понапрасну, без пользы.

**һәвам** هوام *ис.* Зарарлы бөҗәк һәм сөйрәлүчеләр. *Өй эчендәге һәвам вә хәшарәтне бетерер.* (К. Нас.) — *сущ.* Вредные насекомые и пресмыкающиеся.

**һәвәс*** هوس *ис.* Теләк, эстәү, арзу, омтылу, күңел кую. *Ул укырга шул кадәр һәвәс кылды ки.* (З. Биг.) — *сущ.* Желание, хотение, охота; страсть, стремление.

**һәвәскяр*** هوسكار *гф. ис.* Һәвәскәр, теләүче. *Гыйлем вә һөнәр китапларын укымая һәвәскяр улды.* (Ш. ж.) — *ар.-п. сущ.* Любитель, любящий, склонный (к чему-либо).

**һәдая** هدايه һәдия-нең *к.* — *мн.* от һәдия.

**һәдем** هدم *ис.* Вату, җимерү, бозу; юкка чыгару, һәлак итү. — *сущ.* Разрушение, слом, снос (здания); гибель, уничтожение.

**һәдер** هدر *ис.* 1) Канга кан үчен алмый калдыру. 2) Бушка, әрәмгә югалту, әрәм итү. — *сущ.* 1) Неисполнение обета кровной мести. 2) Потеря.

**һәдия** هديه *ис.* Бүләк. — *сущ.* Подарок, дар.

**һәдиятән** هديةً *р.* Бүләк итеп, бушлай. — *н.* В качестве подарка, даром.

**һәдәф** هدف *ис.* Төбәү ноктасы, мишень. „*Ләтаиф риваятьнең*" *әүвәлге җөззәләре халыкларның тәгъриз вә тәгънәләренә һәдәф булды.* (Р. Фәх.) — *сущ.* Мишень.

**һәзар** هزار *ф. сан* Мең (1000). *Һәзар чәндан арзу берлә эстәюрмен.* (К. Гал.) — *п. ч.* Тысяча.

**һәзаран** هزاران һәзар-ның *к.* — *мн.* от һәзар.

**һәзар дастан** هزاردستان *ф. ис.* Сандугач. — *п. сущ.* Соловей.

**һәзар фән** هزارفن *гф. ис.* Төрле һөнәр белүче, ни тотса шуны башкаручы. — *ар.-п. сущ.* Мастер на все руки.

**һәзел** هزل *ис.* 1) Шаярту, уен-көлке сүз, мәзәк. 2) Уен-көлке, мәзәк рәвешендә язылган хикәя, шигырь, чәнечкеле җыр. *Күзләдем туй, тамаша, һәзел һәзьян мәҗлесе.* (Һ. Сал.) — *сущ.* 1) Подшучивание; шутка. 2) Рассказ, стихотворение, написанное в шуточном тоне, насмешливая песня.

**һәзлият** هزليات һәзел-нең *к.* — *мн.* от һәзел.

**һәзимәт** هزيمت *ис.* Җиңелү, тармар килү; җиңелеп качу. — *сущ.* Поражение, разгром; бегство.

**һәзьян (һәзәян)** هذيان *ис.* Саташу, мәгънәсез сүз. — *сущ.* Бред, бессмыслица.

**һәйбәт** هيبت *ис.* 1) Курку һәм олылау, курку катыш хөрмәтләү тойгысы уяндыра торган күренеш, мәһабәтлелек. 2) Авторитет; олысымаклык. *Бу хатынның һәйбәте илә гайрәте, һәр заманда җәлеб итәрди хәйраты.* (Г. Тук.) 3) Әйбәт. — *сущ.* 1) Боязнь, страх (перед кем-либо). 2) Уважение, почтение, уважение из боязни. 3) Достоинство, престиж, авторитет. 4) Хороший, хорошо.

**һәйкәл*** هيكل *ис.* 1) Сын, тораташ, статуя. 2) Һәйкәл. *Мин гашыйкны сүз аңлый дип уйлый инде, кадап куйган һәйкәл төсле кузгалмагач.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Статуя, фигура, изваяние. 2) Памятник.

**һәйкәлтәраш** هيكلتراش *гф. ис.* Һәйкәл ясаучы оста, скульптор. — *ар.-п. сущ.* Ваятель, скульптор.

**һәйәт** هيئت *ис.* 1) Тышкы күренеш, кыяфәт, сурәт. 2) Хәл. 3) Комиссия, комитет, коллегия, миссия, делегация (гомумән бер юлда, бер максатта җыелган аерым кешеләрнең барысы). 4) Хәрәкәт күренеше буларак күк йөзендә әйләнә торган җир һәм барлык галәм һәм шул турыдагы фән. — *сущ.* 1) Вид, внешность, фигура, осанка. 2) Образ, положение. 3) Комиссия, комитет, коллегия, миссия, делегация, состав, персонал. 4) Наука о движении небесных тел.

**һәйәт гыйльме** — астрономия, космография. Астрономия, космография.

**һәйәте аслия** — иң беренче, иң әүвәлге күренеш, төп хәл. Основное положение, первоначальный вид.

**һәйәте мәбгусан** — депутатлар палатасы. Палата депутатов.

**һәйәте сөфара** — дипломатик корпус. Дипломатический корпус.

**һәйәт шинас** هیئتشناس *гф. ис.* Астроном. *ар.-п. сущ.* Астроном.

**һәйһат** هیهات *ым.* 1) Ерак, бик ерак. 2) Кире кайтаруы мөмкин булмаган бер нәрсә өчен өзәләнгәндә әйтелә торган ымлык. *Һәйһат, яшь чаклар!* *межд.* 1) Как далеко! Какая большая разница! 2) О горе! увы!

**һәйһат сөммә һәйһат** هیهاتثم هیهات *гыйб.* Үкенеч соңында үкенеч; булмый да булмый инде! *фр. букв.* Разочарование за разочарованием, никак не получается!

**һәляк*** هلاك *ис.* Һәлак, бетү, үлү. *сущ.* Гибель, смерть.

**һәлякәт*** هلاكت *ис.* Һәлакәт, үлем; юкка чыгу, бетү, югалу, харап булу. *Акмый тышка мәгънәләр, кипкән күңелнең чишмәсе, калган урынында һәлякәт чокры, баткаклык күрәм.* (Г. Тук.) *сущ.* Смерть; исчезновение, гибель.

**һәлөммә җәрра** هلمجرا *ст.* 1) Һәм башкалары. 2) Шуның аркасында. *Бу сыйфатлар никадәр гүзәл булсалар да, әчендә берсе-берсе накыйс булса, вә һәлөммә җәрра башкаларына да ноксан килер.* (К. Нас.) *сс.* 1) И так далее. 2) Вследствие этого.

**һәм I** هم *ис.* 1) Гамь, кайгы, хәсрәт, борчылу. 2) Мәшәкать. *Дирһәмнең ахыры һәмдер.* (К. Нас.) *сущ.* 1) Забота, интерес, тревога, беспокойство, печаль. 2) Хлопоты.

**һәм II*** هم *ф. терк.* 1) Һәм, янә. 2) Сүз башына ялганып „даш-дәш" кушымчасы кебек уртаклыкны, бергәлекне белдерә: *һәмраһ* — юлдаш; *һәмдәм* — иптәш. *п. част.* 1) Также, тоже, и ещё, и. 2) Соответствует значению русской приставки „со-" (напр., сотрудничество, содружество и т. п.).

**һәман*** همان *ф. р.* 1) Бик тиз, һич кичекмәстән, шул вакытта ук. *Әхмәд Мәүләви һәман ул кәгазьне солтан кулына бирде.* (К. Нас.) 2) Һәрвакыт, тоташтан, өзлексез, һаман. *п. н.* 1) Очень быстро, без задержки. 2) Непрерывно, всё время, беспрестанно.

**һәмгасыр** همعصر *гф. ис.* Гасырдаш, замандаш. *ар.-п. сущ.* Современник.

**һәмдил** همدل *ф.* Фикердәш, бер күңелдән, бер караштан, бер тавыштан, бердәм. — *п.* 1. Единодушный, единогласный. 2. Единодушно, единогласно.

**һәмдәм** همدم *ф. ис.* Бергә яшәүче иптәш, дус. *Ник бәни шат итмәдең, ник әйләдең гамь һәмдәме?* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Искренний друг, товарищ.

**һәмдәст** همدست *ф. ис.* Хезмәттәш, бер үк эштә катнашучы, шәрик. — *п. сущ.* 1) Сотрудник, компаньон. 2) Соучастник.

**һәмзәбан** همزبان *ф. ис.* Бер телдә сөйләшүче, телдәш. — *п. сущ.* Говорящий на одном языке (с кем-либо).

**һәмишә*** هميشه *ф. р.* Һаман, һәркайчан, ялан, һәрвакыт, өзлексез. — *п. н.* Постоянно, всё время, беспрестанно, непрерывно.

**һәммәгънә** هممعنا *ф. с.* Мәгънәдәш, синонимик. — *п. прил.* Синонимичный, однозначный.

**һәмнам** همنام *ф. с.* Исемдәш; бер исемдәге; адаш. — *п. прил.* 1) Одноимённый. 2) Омонимичный. 3) Тёзка.

**һәмраз** همراز *ф. ис.* Сердәш, бер сердә. *Ки былбыл гөл белән һәмраз булды* (Сайяди). — *п. сущ.* Интимный друг.

**һәмраһ** همراه *ф. ис.* Юлдаш. *Кечек икән атамыз сатун алды; дора-дора безнең илә һәмраһ булды.* (К. Гал.) — *п. сущ.* Спутник.

**һәмрәнк** همرنك *ф.* с. Бер төсле, бер төстә, төсләре бер. — *п. прил.* Одноцветный, одномастный.

**һәмсини** همسن *гф. ис.* Яшьтәш. — *ар.-п. сущ.* Ровесник, тёзка.

**һәмсохбәт** همصحبت *гф. ис.* Утырдаш, мәҗлестәш, бергә сөйләшеп утыручы. — *ар.-п. сущ.* Собеседник.

**һәмсәбак** همسبق *гф. ис.* Сабакташ, шәрик. — *ар.-п. сущ.* Одноклассник.

**һәмта** همتا *ф. с.* Тигез, бердәй, охшаш, охшашлы. — *п. прил.* Равный, подобный, сходный.

**һәмханә** همخانه *ф. ис.* Өйдәш, күрше. *Гамең берлә бу көн һәмханәдермен* (Сайяди). — *п. сущ.* Сожитель(ница), сосед (по дому).

**һәмширә** همشيره *ф. ис.* Кыз туган, кыз кардәш (сеңел, апа, тута). *Хатын, бала табтым иремнең варисы бар дип, ул мөтәвафаның һәмширәсен мирастан мәхрүм кылды.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Сестра.

| | |
|---|---|
| **һәмәҗ** همج *ис.* 1) Варварлар. 2) Аннан-моннан җыелган кешеләр төркеме. 3) Черки, озынборын. | *сущ.* 1) *соб.* Варвары. 2) Сброд, скопище. 3) Комар. |
| **һәмхөдуд** همحدود *гф. с.* Чиктәш. | *ар.-п. прил.* Смежный, пограничный, граничащий. |
| **һәмҗинес, һәмҗенеси** همجنسی همجنس *гф. с.* Женестәш, бер төрдән булган, бер төрле. *Һәмҗенеси булган мәхлукатның гадәвәтләре куй белән бүре гадәвәте кеби булмас.* (Г. Фәез.) | *ар.-п. прил.* Однородный, единообразный; единородный. |
| **һәмһәмә** همهمه *ис.* 1) Сукрану, лыгырдау, мыгырдау. 2) Тавыш, шау. | *сущ.* 1) Ворчание, бормотание. 2) Шум. |
| **һәнгям** هنگام *ф. ис.* Вакыт, заман, ара. *Бәһәнгям* — үз вакытында, вакытлы. | *п. сущ.* Время, пора. |
| **һәнгямә** هنگامه *ф. ис.* 1) Әңгәмә. 2) Тавыш, гаугa, ыгы-зыгы, матавык. *Әйдә һәнгямәләрне вә мәҗараларны тамаша кыйл.* (Г. Фәез.) | *п. сущ.* 1) Беседа. 2) Суматоха; скандал. |
| **һәндәсә** هندسه *ис.* 1) Геометрия. 2) Инженерлык эше. | *сущ.* 1) Геометрия. 2) Инженерное дело. |
| **һәндәси, һәндәсия** هندسی، هندسیه *с.* Геометрик, геометриягә бәйләнешле. | *прил.* Геометрический. |
| **һәниә** هنی *с.* Ягымлы, ямьле, күңелле. | *прил.* Приятный; красивый. |
| **һәнүз*** هنوز *ф. р.* Әле дә, һаман, һаман да. *Бу кыз хәзер җиткән кыздыр, һәнүз кияүгә биргәне юк.* (К. Нас.) | *п. н.* Ещё (не), всё, ещё. |
| **һәрайинә** هراینه *ф. р.* Һәркайчан, һәрвакыт; һәр очракта; һәр хәлдә; әлбәттә, шиксез, һичшиксез. *Бары өй кызлары һәрайинә йөгерде* (Сайяди). | *п. н.* Всегда, во всякое время; во всяком случае; конечно, несомненно. |
| **һәран** هران *гф. р.* Һәрвакыт, һаман. *Бакып торыр идем һәран.* (Г. Кан.) | *ар.-п. н.* Всякий раз, каждый раз, всё время. |
| **һәрасә** هراسه *ф. ис.* 1) Курку, кот чыгу. 2) Куркыткыч. *Нә һәрасә бар дошманының.* (Җәвамигъ-ет-тәварих.) | *п. сущ.* 1) Страх, ужас. 2) Пугало. |
| **һәргиз** هرگیز *ф. р.* 1) Һәрвакыт, һәр тапкыр. 2) Һич, һичбер вакыт. *Яр җәүр итсә, һәргиз рәнҗемә.* (К. Нас.) | *п. н.* 1) Каждый раз, всегда. 2) Никогда. |
| **һәрдәм** هردم *ф. р.* Һәрвакыт, һәр сулыш. *Сезнең вар гомереңез кичте хәсәдләрдә янып һәрдәм.* (Г. Тук.) | *п. н.* Всегда, непрестанно. |

| | |
|---|---|
| **һәрзә** هرزه *ф. ис.* Буш (юк-бар) сүз, сафсата, лыгырдау; мәгънәсез сүз. | *п. сущ.* Пустословие, болтовня; бессмыслица. |
| **һәрим** هرم *с.* Бик картайган, бик бетерешкән, какшаган, тузган (кеше). | *прил.* Очень старый, дряхлый, престарелый. |
| **һәрисә** هريسه *ис.* Төйгән бодай белән каклаган иттән хәзерләнгән ашамлык. *Күп вакытны һәрисә ашар иде.* (К. Нас.) | *сущ.* Хариса (блюдо из мяса и толчёной пшеницы). |
| **һәркәс** هركس *ф. ис.* Һәр кеше. | *п. сущ.* Каждый человек. |
| **һәрәм I** هرم *ис.* Картлык, какшаганлык, бетерешкәнлек. | *сущ.* Дряхлость, старческая слабость. |
| **һәрәм II** هرم *ис.* Пирамида, әһрам. | *сущ.* Пирамида (египетская). |
| **һәрҗ** هرج *ис.* Хәрәкәткә килү, чуалыш, тавыш, шау-шу. | *сущ.* Возбуждение, волнение, шум, суматоха, гвалт. |
| **һәрҗ вә мәрҗ** هرج ومرج *ст.* Буталу, асты-өскә килү. | *сс.* Сильное возбуждение, переполох. |
| **һәст** هست *ф. ис.* Бар. | *п. сущ.* Есть, имеется. |
| **һәтек** هتك *ис.* 1) Ерту. 2) Хурлык. | *сущ.* 1) Разрывание. 2) Бесчестье, позор. |
| **һәтек гыйрыз** — йөз суын түгү, намуска тукыну. | Бесчестье. |
| **һәфт** هفت *ф. сан* Җиде. | *п. ч.* Семь. |
| **һәфтад** هفتاد *ф. сан* Җитмеш. | *п. ч.* Семьдесят. |
| **һәфтеяк*** هفتيك *ф. сан* 1) Җидедән бер. 2) Коръәннең җидедән бер өлешен эченә алган китап. *Кул керәнә былчырангач, һәфтеякнең һәр битен...* (Г. Тук.) | *п. ч.* 1) Одна седьмая. 2) Одна седьмая часть Корана (в виде отдельной книги). |
| **һәфтә** هفته *ф. ис.* Атна. | *п. сущ.* Неделя. |
| **һәшт** هشت *ф. сан* Сигез. | *п. ч.* Восемь. |
| **һәштад** هشتاد *ф. сан* Сиксән. | *п. ч.* Восемьдесят. |
| **һәштемин** هشتمين *ф. сан* Сигезенче. | *п. ч.* Восьмой. |
| **һәякил** هياكل Һәйкәл-нең *к.* | *мн.* от һәйкәл. |
| **һәяҗан** هيجان *ис.* 1) Дулкынлану. 2) Аптырау; эчтән куркуга төшү; ни эшләргә белмәү. | *сущ.* 1) Волнение, возбуждение. 2) Растерянность; испуг. |

**һәүл** هول *ис.* 1) Курку, куркыну, өркү. 2) *дини* Мәет күмелгән көнне кичен укыла торган намаз. — *сущ.* 1) Страх, ужас. 2) *рел.* Молитва, совершаемая вечером, в день погребения умершего.

**һәүн** هون *ис.* 1) Җиңеллек, ансатлык. 2) Әһәмиятсезлек, илтифатсызлык. — *сущ.* 1) Лёгкость. 2) Невнимательность, пренебрежение.

**һәҗа** هجا *ис.* Иҗек; сүзнең һәр кисәге. — *сущ.* Слог.

**һәҗин** هجن *ис.* 1) Саф канлы (саф токымлы) булмаган ат. 2) Гибрид, метис (катнаш токымлы хайван). 3) Тиз йөрешле тәвә. 4) Бер өркәчле тәвә. *Ике нәселдән булса да ярый, кирәк һәҗин, кирәк нар тәвә булсын* (Г. Газиз). — *сущ.* 1) Нечистокровный, непородистый. 2) Помесь, гибрид, метис. 3) Быстроходный верблюд. 4) Одногорбый верблюд.

**һәҗәр** هجر *ис.* 1) Туктату (эшне). 2) Хатынны ташлау. 3) Берәү белән аерылышу, мөнәсәбәтне өзү, туктату. — *сущ.* 1) Прекращение (занятий). 2) Оставление, покидание (жены). 3) Расставание (с кем-либо), разрыв отношений; прекращение общения.

**һәҗү (һөҗү)*** هجو *ис.* 1) Көлү. 3) Мәсхәрәләү, сатира. — *сущ.* 1) Высмеивание. 2) Насмешка. 3) Сатира, пасквиль.

**һәҗүви** هجوى *с.* 1) Көлкеле, мәсхәрәле. 2) Сатирик. — *прил.* 1) Насмешливый, язвительный. 2) Сатирический.

**һөбуб** هبوب *ис.* Исү (җил), котырыну (җил). — *сущ.* Завывание, бушевание (ветра).

**һөбут** هبوط *ис.* Түбән инү, югарыдан түбәнгә төшү. — *сущ.* Спуск, снижение, опускание.

**һөвә** هو *ал.* Ул (ир). — *мест.* Он.

**һөвәйда** هويد *ф. с.* Ачык, күзгә күренгән, реаль. *Хөсенне та һөвәйда кылды халик, хөс н берлә вафа булмас муафыйк.* (Хорәз.) — *п. прил.* Ясный, видный.

**һөдә** هدا *ис.* Туры юл, туры юлга күндерү. — *сущ.* 1) Правильный путь. 2) Ведение по правильному пути.

**һөдһөд*** هدهد *ф. ис.* Һөдһөд кошы. — *п. сущ.* Удод (птица).

**һөзал** هزال *ис.* Арыклык, ябыклык. — *сущ.* Худоба.

**һөмам** همام *ис.* *кара:* Һимам. *Һөмам гасрел җәдид, әлхәмде лилла.* (Г. Тук.) — *сущ.* *см.* Һимам.

**һөмаюн** همايون *гф. ис.* 1) Көчле, бәхетле. 2) Бөек, югары дәрәҗәле. 3) Патшага хас, патша тарафыннан булган. *Татар кызына „ага-эне җәбереннән башкалар көченә сыгынып сакланырга әм-ре һөмаюн булды...“* (Ф. Әмир.) — *ар.-п. прил.* 1) Сильный, счастливый. 2) Высший. 3) Королевский, царский, императорский.

**һөрмез, һөрмезд** هرمز *ф. ис.* Борынгы Иранда яхшылык алласы. — *п. сущ.* Ормузд (божество добра — в дуалистической религии древнего Ирана).

**һөжугъ** هجوع *ис.* 1) Йокы. 2) Тынычлану, тыныч булу. — *сущ.* 1) Сон. 2) Успокоение, затишье.

**һөҗүм*** هجوم *ис.* һөҗүм; өскә ташлану, дошман өстенә ыргытылу; атака. — *сущ.* Набег; наступление, нападение; атака.

*М. И. Мәхмутов*

# ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНӘ КЕРГӘН ГАРӘП-ФАРСЫ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ

(ГРАММАТИК БЕЛЕШМӘ)

# Мөселман яшьләренең мөрәҗәгате

Кардәш!

Галәмдәге бар нәрсә Аллага буйсына. Җир һәм күк, планета һәм йолдызлар - бар да Ходай кушканча хәрәкәт итә. Тормышның шушы табигый агышына кеше генә каршы төшә.

Без бүген бер яктан фән һәм технологиядә гаҗәеп ачышларны күрәбез. Ләкин, икенче яктан карaганда, адәм баласы көннән-көн үзенең кешелек сыйфатларын югалта, үз-үзен генә яратучыга, теләсә нинди җинаятьне эшли алучыга әйләнә бара. Кешелек бүген кулына куркыныч корал эләккән акылсыз баланы хәтерләтә.

Кеше табигатькә каршы торганга, тормышның табигый агымына каршы барганга күрә газап чигә. Галәм белән бердәмлеккә кире кайтырга, аны Тудыручыга, Бердәнбер, Бөек, Мәңгелек Аллага ышанырга кирәк. Әгәр дә син Ходайга ышанып, ул кушканча, аның кануннары буенча яши башласаң, синең тормышың тамырдан үзгәрер, ягъни ул имин һәм гармонияле булыр.

Бу юлны башлап сайлаучыларның берсе Мөселман Яшьләре Берлеге әгъзалары булды. Безнең максатыбыз - кешегә, җәмгыятькә Аллаһ ризалыгы өчен яшәргә булышу. Без һәркемгә иминлеккә, уңышка ирешергә ярдәм итәргә телибез. Бу олы максатка ирешә өчен Мөселман Яшьләре Берлеге яшьләргә чын инануга ирешергә, Алланы танырга өйрәнергә ярдәм итә, яшьләрне халыкка исламны танырга чакыра, ислам диненә хезмәткә яшьләрнең талантын үстерә, яшьләрне чын туганнар итеп берләштерә, яшьләргә шәхси һәм социаль проблемаларын, хәерчелекне җиңәргә ярдәм итә.

Безнең эшчәнлегебезнең кайбер төрләре:

- атна саен очрашулар уздыру;
- өйрәнү лагерьлары;
- уку курслары;
- әдәбият чыгару һәм тарату;
- экскурсияләр, табигатьтә җыйналулар һәм кичәләр;
- конференция, семинар, бәхәсләр;
- чит илгә сәяхәтләр һ.б...

Әгәр дә синең тамырыңда кайнар кан ага икән, әгәр дә синең йөрәгең куркусыз һәм кыю икән, син бөтен хыялланган нәрсәңә ирешә аласың. Кыю бул, хаклык, ислам ягына бас, явызлык һәм әшәкелеккә каршы көрәш! Һәм син үзеңнең ялгыз түгеллегеңне күрерсең.

Уян, алга чык - Мөселман Яшьләре Берлеге сафларына бас.

Белемеңә, чыгышыңа, милләтеңә, динеңә карамастан, әгәр син мәсләгебезне уртаклашасың икән, безгә кил, тормышыңны чын максат һәм чын шатлык өчен яңадан кора башла.

Безне Коръән Кәрим сүзләре илһамландыра: "Ничә тапкыр кечкенә яу зур чирләрне җиңде Аллаһы рөхсәте буенча! Тәхкыйк, Аллаһ - сабыр итүчеләр белән".

*Безнең адрес: 420029, Казан, а/я 63, Мөселман Яшьләре Берлеге.*

# КЕРЕШ СҮЗ

Татар халкының бай әдәби мирасы бар. Бу мирасны өйрәнү һәм милли мәдәниятне үстерү, яшь буынны милли рухта тәрбияләү өчен аннан файдалану бүгенге көндә иң әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Әмма мирасыбызны өйрәнү өчен борынгы татар телен яхшы белү кирәк, ә ул бигрәк катлаулы, кульязмалар, китапларның эчтәлеге ерак заманнар белән бәйләнгән, шул вакытлардагы, бүгенге кеше өчен авыррак аңлаешлы вакыйгаларны чагылдыралар; хәтта язуы да бүгенге түгел, хәрефләре, имласы башка...

Демократиялашу чоры һәм ул ачып җибәргән милли хәрәкәт, тарихи фикерләү һәм тарихи хәтергә таянган шикелле, милли үзаң да халыкның тарихына, аның рухи мирасына таяна. Болар барысы да азатлыкка омтылган халыкларның тормышына көчле тәэсир итә...

Телләрнең бер-беренә үзара ничек тәэсир итүен һәм закончалыкларын ачу өчен, иң элек аерым телнең үсеш-үзгәреш закончалыкларын, аның элекке тарихын һәм нинди үсеш юлы үтүен өйрәнергә кирәк.

Теге яки бу телнең лексикасы берьюлы гына, кинәт кенә барлыкка килмәгән кебек, татар теленең дә сүзлек составы берьюлы һәм кинәт кенә барлыкка килмәгән. Ул — күп гасырлар буена халыкның иҗтимагый тормышы, хезмәте һәм дөньяга карашы, хуҗалык һәм көнкүреше белән бәйләнеп үстерелгән тел иҗаты нәтиҗәсе.

Халык үзенең әдәби тел лексикасын баета бара. Ул моның өчен телдә булган сүзләрдән яңа сүзләр ясый (неологизмнар), җирле телдәге һәм шивәләрдәге сүзләрне үзләштерә (диалектизмнар), башка халыклар телендәге яңа төшенчәләр белән бергә шуларны белдерүче сүзләрне ала.

Сүзлегебез әнә шул әдәби тел лексикасы (сүз байлыгы) чыганакларының соңгысына караганлыктан, бу урында алынма сүзләр һәм, аерым алганда, гарәп һәм фарсы алынмаларына тукталабыз.

Алынмалар — чит телләрдән кергән аерым сүзләр, сүз тезмәләре һәм грамматик элементлар ул. Телдә алынма сүзләрнең булуы төрле халыкларның үзара тыгыз мөнәсәбәтләрдә яшәп килүен, бер-берсенең тәҗрибәсен, казанышларын уртаклашуын күрсәтә. „Һәрбер милләт бүтән милләтләрдән өйрәнә ала һәм өйрәнергә мәҗбүр

дә"[1], — дип яза К. Маркс. Теге яки бу өлкәдә алгарак киткән халыкның теленнән башка халыклар телләренә яңа төшенчәләр һәм шуларны белдерүче яңа сүзләр дә күчәләр.

Шулай итеп, телнең лексикасы үсә бара, кешеләрнең фикерләрен бер-берсенә ныграк һәм ачыграк итеп аңлату өчен аның мөмкинлекләре артканнан-арта.

Югарыда әйтелгәннәр татар теленә дә карый, чөнки бу — барлык телләр өчен дә уртак, объектив закончалык. Башка телләрдәге шикелле үк, хәзерге татар әдәби телендә дә чит телләрдән кергән сүзләр сүзлек составының шактый өлешен тәшкил итәләр.

Татар телендәге алынма сүзләрнең күбесе рус, гарәп, фарсы телләреннән кергән. Рус сүзләре телебезгә нигездә соңгы гасырларда кергән булса, гарәп-фарсы сүзләре исә аннан элегрәк кереп урнашканнар, хәзер аларның күбесенең ят сүзләр икәнлеге сизелми дә.

Гарәп һәм фарсы сүзләре татар теленә төрле заманнарда һәм төрле юллар белән килеп кергәннәр. Унынчы гасырга чаклы ук инде Болгар дәүләтенә гарәп сәүдәгәрләре һәм сәяхәтчеләре килә башлый[2]. Сәүдә итү белән беррәттән, алар монда ислам дине таратып йөргәннәр һәм, шул максат белән мәчетләр һәм мәдрәсәләр ачып, гарәп язуы һәм гарәп теле өйрәткәннәр. Бу хәл, әлбәттә, болгарлар теленә тәэсир итми калмаган. Урта Азия, Иран һәм башка халыклар белән булган сәүдә һәм культура бәйләнешләре аркылы болгар-татар теленә, ә соңыннан исә, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында, татар теленә гарәп-фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре килеп кергән.

XIII — XIV гасырларда Алтын Урда белән гарәп илләре һәм, бигрәк тә, Мисыр арасында сәүдә һәм культура бәйләнешләре бик нык көчәеп китә. Сарайда һәм Алтын Урданың бүтән мәдәни учакларында бик күп галимнәр, шагыйрьләр һәм әдипләр яшәгән һәм иҗат иткән. Ул заманда ук чын мәгънәсендә дөньяви эчтәлекле матур әдәбият үсә, төрле фәннәрдән бик күп китаплар языла. Гарәпчә укып белем алган галимнәр һәм шагыйрьләр шул замандагы „төрки" телгә күп гарәп сүзләре кертәләр.

Алтын Урдада һәм шулай ук Мисырда яшәгән төрки телдә сөйләшүче шагыйрьләр фарсы һәм гарәп телләрендәге күп кенә әсәрләрне борынгы татар теленә тәрҗемә иткәннәр. Мәсәлән, Сәгъди тарафыннан язылган һәм бөтендөнья әдәбиятының гүзәл әсәрләреннән саналган „Бөстан" һәм „Гөлстан", Фирдәүсинең „Шаһнамә"се фарсы теленнән татар теленә тәрҗемә ителгәне мәгълүм. Шул ук вакытта гарәп галимнәре, төрки телләрнең грамматикаларын язганда, шул телләргә гарәп грамматикасыннан күп кенә терминнар керткәннәр. Медицина, астрономия, география, тарих, математика һ. б. китапларның да төрле гасырларда безнең телгә гарәп теленнән тәрҗемә ителгән булуларын исәпкә алсак, телебезгә гарәпчәдән кергән сүзләрнең никадәр күп булуын күз алдына китерү кыен түгел.

---

[1] К. Маркс. Капитал, т. I, Предисловие к первому изданию, Госполитиздат, 1955, стр. 7.

[2] Ковалевский А. П. Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921—922 гг., Харьков, 1956.

Менә шул чорларда һәм бигрәк тә XVIII—XIX гасырларда татар теленә кергән сүзләр һәм сүз тезмәләренең байтагы күп еллар буена татар әдәби телендә үзләштерелеп, татар теленең закончалыкларына буйсындырылган. XIX йөзнең азагында һәм XX йөзнең башларында татар матбугатында һәм әдәбиятында гарәп сүзләре шулхәтле күп була, хәтта ул татарның алдынгы, демократик әдипләренең телләренә дә зур йогынты ясый. Мәсәлән, татар халкының әдәби теленә нигез салуда күп көч куйган халык шагыйре Габдулла Тукай әсәрләрендә без бик күп кенә гарәп һәм фарсы сүзләре очратабыз. Менә 1905 нче елларда язылган „И каләм!“ исемле шигыреннән берничә юл:

...*Рәфгъ* итеп *Аурупаи* сән *гарше әгъляя кадәр*,
Нә ичен бези дөшерден *фәрше әднәя кадәр?*
*Милләт*ең бу *хале мәктүбме китабы хикмәтә?*
*Мөнхәсыйр*мы *анә гомре хале мәзмүмиятә!*
Яз *тәгаллем*нәргә *тәргыйб*, әйлә *тәкъдир кадр*ене,
Ит *надан*лыкларны *тәгъриф, зәһр*ене яз *гадр*ене...

Мондагы 37 сүзнең бары 5 е генә бүгенге татар әдәби телендә кулланыла торган саф татар сүзе булса, 24 есе исә гарәп теленнән алынган сүз.

Мондый хәл XX гасырның башына кадәр язылган барлык әсәрләрдә дә диярлек күренә. Югарыдагы өзек борынгы татар әдәбиятын махсус сүзлек-белешмәдән башка уку һәм аңлау мөмкин түгеллеген күрсәтә.

XIX йөзнең соңгы чирегендә татар теле һәм әдәбиятының үсеше тарихында яңа чор башлана. Киң хезмәт ияләре массаларына аңлаешлы булсын өчен, әдәби тел халыкка аңлашылмаган гарәп-фарсы сүзләреннән акрынлап арындырыла барыла. Милли әдәби тел булдыруда татарның демократик галимнәре, шагыйрьләре һәм әдипләре аеруча көч куялар. Атаклы галим К. Насыйри халыкны агарту, фәнне һәм әдәбиятны халыкка якынайту юлында зур эшчәнлек күрсәтә; аннан соң бу эшне татарның күренекле шагыйрьләре һәм әдипләре дәвам иттерәләр. Алар әдәбиятта татар теленең үз лексикасын мөмкин кадәр күбрәк кулланырга тырышалар, бу исә әдәбиятны киң халык массаларына мөмкин кадәр якынайту, татар теленең лексик составында неологизмнарны көчәйтү һәм алынмалар куллануны чикләү дигән сүз.

Хезмәт ияләренә аңлашылмаган гарәп-фарсы алынмаларын татар халкының сөйләм телендәге сүзләр белән алыштыру Г. Тукай заманында ук башланды.

Бу — Г. Тукайның үз иҗатында да ачык күренә. Мәсәлән, аның 1905—1907 нче елларда язылган әсәрләрендә гарәп-фарсы элементлары 60—65 процент булса, 1910—1913 нче елларда язылган әсәрләрендә инде бу элементлар нибары 25—30 процент кына тәшкил итә[1].

Әдәбият мәйданына Г. Тукайдан соң килгән язучылар һәм шагыйрьләр дә татар телен гарәп-фарсы сүзләреннән арындыруда күп көч куялар. Мондыйлардан Ш. Камал, Г. Камал, Ш. Бабич, К. Тинчурин һәм Г. Ибраһимовны күрсәтергә мөмкин.

[1] Ш. Рамазанов. Татар теле буенча очерклар, Таткнигоиздат, 1954, 58—77 битләр.

«Гарәпчә — татарча — русча алынмалар сүзлеге»нең сүз башында әйтелгәнчә, белем татар теле байлыгының зур өлешен эченә алган, ул татарларның үзләре ижат иткән хәзинәләр. Халкыбызның шагыйрь-әдипләре, мең елга якын гарәп дөньясыннан үрнәк алалар, аннан фән, әдәбият, дин, китап, мәдрәсәләр килә; татарларның гарәпләр белән киң сәүдә мөнәсәбәтләре дә була, яшьләр гарәп илләренә барып белем алып укып кайталар. Мондый мөнәсәбәтләр нәтиҗәсе буларак, татар теленә бик күп гарәп сүз һәм сүз тезмәләре кереп кала.

## ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕНДӘ АЛЫНМАЛАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛУЫ

Татар әдәби теленә кергән гарәп-фарсы сүзләре сөйләм телендә һәм әдәби әсәрләрдә (иске һәм өлешчә яңа әдәби әсәрләрдә) кулланылалар. Татар телендәге шул гарәп сүзләрен түбәндәге төр, кемчәләргә бүләргә мөмкин булыр иде:[1]

1) Дини эчтәлекле сүзләр, дини терминнар: *алла, илаһи, нәби, дин, иман, гыйбадәт, фарыз, сөннәт, хаҗ, корбан, җәһәннәм, тәсбих* һ. б. сүзләр.

2) Уку-укыту эшләренә караган сүзләр: *кыйраәт, инша* (сочинение, изложение), *имля* (орфография), *дарел-фенүн* (университет), *хөсне-хат* (чистописание), *мөгаллим, мәктәп, мәдрәсә* (училище), *дәрес, имтихан, ысулы тәгълим, ысулы тәдрис* кебек сүзләр һәм сүз тезмәләре.

3) Фән һәм матбугат өлкәсенә караган сүзләр: *һәндәсә* (геометрия, инженерлык эше), *табигать, фикер, мантыйк* (логика), *сарыф, нәху* (синтаксис), *әдәбият, хисап, мәҗмуга, матбугат, мөхәррир* һ. б.

4) Иҗтимагый-политик терминнар: *иҗтимагый, мәмләкәт, икътисади, сәясәт, казый, гавам, дәүләт, идарә, хөкем, җәллад, мәхкүм* һ. б.

5) Тормыш-көнкүреш лексикасы: *шулпа, шикәр, гаилә, нәсел, кабилә, халык, бина, бәет, кәлимә, җөббә, сандык, хат, мәктүб, ләхем, мәхәббәт, гыйшык* һ. б.

6) Хәрби һәм медицина терминнары: *хәрби, баруд* (порох), *хәнҗәр, гаскәр, тыйбб* (медицина), *табиб* (врач), *дәва, шифа* һ. б.

7) Абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләр: *ихтыяр, игътибар, мәгълүм, мөнәсәбәт, мөстәкыйль, мәсьүл, инсаният, нәфасәт, рухият* һ. б. сүзләр.

8) Кеше исемнәре: *Габдулла* (алла колы), *Габдрахман* (шул ук мәгънәдә), *Әхмәт* (ин мактаулы), *Мәхмүт* (макталган), *Кәрим* (вөҗданлы), *Зариф* (матур), *Хәсән* (чибәр), *Зәки* (зирәк), *Газизә* (кадерле), *Әминә* (турылыклы), *Сабира* (түземле, сабыр) һ. б.

Фарсы теленең татар әдәби теленә йогынтысы шулай ук бик күптәннән башланса да, аның тәэсире, гарәп теленә караганда, күп тапкыр кимрәк. Гарәп-фарсы алынмалары арасында фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре бары тик 10—12 процент чамасы гына тәшкил итә.

Фарсы теленнән кергән алынмаларны, башлыча, түбәндәгечә төркемләргә мөмкин:

---

[1] Төркемчәләргә бүлү системасы Ш. Рамазановтан алынды.

1) Дини терминнар: *хода, фәрештә, пәйгамбәр, намаз, руза, гөнаһ, дәрвиш, дию, мордар* һ. б. сүзләр.

2) Социаль мөнәсәбәтләр һәм тормыш-көнкүреш лексикасы: *ханә, дивар* (стена), *серкә, чапан, чалбар, тәрәзә, хуҗа, дүшәмбе, сишәмбе, дәрья, амбар, дивана, бәхет, дус, дошман, сәүдә, мая, бичара, җиһан* һ. б. сүзләр.

3) Кеше исемнәре: *Маһруй* (ай йөзле), *Гөлҗиһан* (дөнья чәчәге, гөле), *Бахтияр* (бәхетле) һ. б.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң татар теле өчен яңа үсеш чоры башлана. Илебезнең иҗтимагый-политик тормышына эшчеләр сыйныфы вәкилләре тартыла. Хуҗалык һәм культура мәсьәләләрен хезмәт ияләре төрле-төрле җыелышларда тикшерә. Чикләнмәгән иҗат мәйданына чыккан хезмәт халкы тормышта аралашу чарасы булган гомуми әдәби телдән киң файдалана, аны үз интересларына хезмәт иттерергә керешә.

Шулай итеп, әдәби телебезнең сүзлек составында зур гына үзгәрешләр була. Революциядән соң телебез бик күп яңа мәгънәләр белән байый бара, хезмәт ияләре куллана торган сүзләрне әдәби телгә кертергә мөмкинлек туа. Татар теле өчен зарури булмаган гарәп-фарсы, башлыча „китап“ сүзләре сөйләм телендә генә түгел, матур әдәбиятта һәм матбугатта да кулланылмый башлый.

Татар әдәби телен гарәп-фарсы сүзләреннән арындырганда, нигездә түбәндәге төп принциплардан чыгып эш ителде:

а) Теге яки бу төшенчәне аңлатыр өчен татар теленең үзендә булган сүз шул ук мәгънәне аңлаткан гарәп сүзен кысрыклап чыгара. Мәсәлән, *сорау* сүзе *сөаль* сүзен, *елга* сүзе *дәрья, нәһер* сүзләрен кысырыклап чыгардылар, *ел* сүзе *сәнә* сүзен алмаштырды.

б) Заманында әдәбиятыбызда зур урын алган һәм әдәби, фәнни әсәрләрне халыкка аңлашылмаслык хәлгә китерүгә сәбәп булган гарәп-фарсы сүзләре татар, рус яки халыкара терминнар белән алмаштырыла. Мәсәлән, *мөхәррир* — редактор, *мәгаттәәссеф* — кызганычка каршы, *истыйлях* — термин, *һәндәсә* — геометрия, *завия* — почмак һ. б. сүзләр.

в) Дини терминнар бөтенләй төшеп калдылар яки күчерелмә мәгънәдә генә кулланыла башладылар. Мәсәлән, *тәкбир, зәкят, гошер, сәвап, тәхмил, алла, җәһәннәм, оҗмах, гыйбадәт* һ. б.

г) Гарәп теленнән кереп тә халыкның сөйләм телендә киң кулланыла торган һәм әдәбиятка нык кереп урнашкан алынмаларның күпчелеге үз сүзләребез булып әверелде. Мәсәлән, *каләм, кала, ватан, мөрәҗәгать, мөнәсәбәт, идарә, илһам, һава, гади, вакыт, сәлам, ләззәт, китап, мәктәп, рәхмәт, ихтыяр, тәртип, бәла, каза, дөнья, әдәбият, дәрәҗә, фән, хак* һ. б.

Телебездә гасырлар буена яшәп килгән мондый алынмаларны кирәксезгә алыштырып, сүз эзләп маташулар телнең үсүен чикләү, телне ярлыландыру булыр иде. Шуңа күрә *шагыйрь, каләм, мәйдан, дус, дошман, хәрби, фикер, галәм, дәрес, китапханә, мәктәп, китап, җиһаз, акыл, мәхәббәт, гыйшык, хезмәт* кебек гарәп-фарсы алынмаларын һәм *пролетариат, революция, теория, марксизм, коммунизм, машина, геометрия, космос, ракета* кебек рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләрне татар теленнән чыгарып ташласак, татар теле җитәрлек үскән милли тел булу сыйфатын

югалтыр иде дисәк хата булмас. Татар әдәби телен кирәкмәгән гарәп-фарсы сүзләреннән арындыру татарлашкан сүзләрне куып чыгару дигән сүз түгел, андый бурыч бервакытта да куелмады һәм куелмый да.

Теге яки бу төшенчәне төгәл чагылдырыр өчен яраклы, күпчелек өчен аңлаешлы алынмалар хәзер дә сөйләмдә дә, язуда да кулланыла. Без ул сүзнең кайсы телдән алынган булуын хәтта уйламыйбыз да.

Менә әдәби әсәрләрдән һәм вакытлы матбугаттан берничә мисал[1]:

„Бер*вакыт* килеп, бу *зиндан* ачылса, берничә минутка *асыл* чәчәк матур кояш *нур*ына юлыкса, — алар *өчен* бу кавышу *сәгатьләре* *дөньяның* *һәммә* *бәхет*ләреннән югары булалар, *җәннәт хыял*ларын бирәләр". (Г. Ибр., „Безнең көннәр".)

„Яшьлекнең бер *дәвер*ендә күп нәрсәгә ышанасың, *алла* диләр, *гадаләт, хакыйкать* диләр, *һәммә* кешеләрнең *сәгадәте хак*ында сөйлиләр, *мәгълүм* бер *шарт*лар буенча төзелсә, *хәят та бәхет* булуын *өмит* итәләр — яшьлек боларга ышана, боларның һәрберен *саф җәүһәр* дип *кабул* итә, һәм шуның белән аның *хәяты* *мәгълүм* бер *дәвер*дә *мәгънә*ле дә, матур да була". (Г. Ибр., „Мәрхүмнең дәфтәреннән".)

„Әйе, идеология эше үз*максат* түгел. Ул коммунистик төзелеш *мәсьәлә*ләрен *хәл* итүдә *нәтиҗә*ле *чара*ларның берсе". („Социалистик Татарстан" газетасы.)

„Мондый *тенденция социалистик милләтләрнең интернациональ асылына җавап* бирә". („Социалистик Татарстан" газетасы.)

Бу соңгы җөмләдә ике генә саф татар сүзе кулланылган, калганнары гарәп һәм Көнбатыш Европа телләреннән алынган, әмма алар татар әдәби теле хәзинәсенә нык кереп урнашкан сүзләр.

Без, дини терминнар татар теленнән төшеп калдылар, дигән идек. Шулай да берәр әдәби типны аныкрак тасвирларга кирәк булса, халык телендә йөргән, әмма әдәбиятта киң кулланылмый торган сүзләрдән дә файдаланалар. Мәсәлән, шагыйрь Г. Афзал, тәкъва бер әбине көлке һәм мәсхәрәле хәлдә күрсәтер өчен, әбиләр телендә булган дини сүзләрдән һәм телебездә киң таралган бүтән гарәп сүзләреннән файдаланып, матур гына бер шигырендә колхоз милкенә кул сузучыны фаш итә, халык алдында мәсхәрәгә калдыра.

Кәҗәбезгә печән беткән,
Колхозныкы *хәләл* икән,
*Тәвәккәл*гә тугыз җирдән
*Хак тәгалә* бирәм дигән...
Атам! — диде *мәхәббәт*сез,
Әби калды *тәһарәт*сез,
Үкчәсенә китте *җаны*,
Басып калды *хәрәкәт*сез.
Тфү, *әстәгъфирулла!*

(Г. Афзал, „Тәвәккәл әби", 1955.)

---

[1] Курсив белән җыелган сүзләр гарәп яки фарсы теленнән алынганнар.

Шулай итеп, татар теленә кереп урнашкан, халык массасына аңлаешлы булган алынмаларны тел белеменең марксистик теориясенә таянып өйрәнү телнең үсеше һәм үзгәреше юлларын тирәнтен белергә мөмкинлек бирә.

## ГАРӘП ГРАММАТИК ЭЛЕМЕНТЛАРЫ

### Гарәп теле турында гомуми мәгълүмат

Хәзерге вакытта семитик телләр төркеменнән киң җәелеп киткән бердәнбер тел — гарәп теле.

Гарәп теле тарихын галимнәр өч чорга бүләләр: борынгы гарәп теле, классик тел һәм хәзерге заман гарәп әдәби теле. Гарәп әдәбиятының искиткеч бай мирасының иң зур өлеше гарәп теленең классик чорына керә. Ислам дине барлыкка килгәнче үк язылган күп кенә шигырьләр, дастаннар, бәетләр, VII гасырларда барлыкка килгән „Коръән“, гарәпләр хәлифәлеге чорында төрле фәннәр буенча язылган бик күп әсәрләр, шулай ук дини китаплар һәм матур әдәбият үрнәкләре, шул исәптән „Әлфе ләйлә вә ләйлә“ („Мең дә бер кичә“) әкиятләре дә классик телдә язылганнар.

Бу әдәбиятта гарәп теле җитәрлек үскән, нык грамматик системалы һәм гаять бай сүзлекле тел булып тора. Аның әһәмияте бигрәк тә ислам дине таралуы белән үсеп китә. Ул шул чорда Якын һәм Урта Көнчыгыштагы халыкларның мәдәни тормышларында халыкара тел итеп кулланыла. Ягъни Көнбатыш Европа халыкларының телләрендә латин теле уйнаган рольне уйный. К. Маркс сүзләре белән әйткәндә, гарәп теле Көнчыгышның латины була: шуңа күрә Көнчыгыштагы гарәптән башка мөселман халыклары телендә гарәп сүзләре бик киң кулланыла. Мәсәлән, фарсы телендә ул 50—60 процентка җитә. Төрки телләрнең дә кайсы берсендә гарәп сүзләренең күләме 30—35 процентка җитә.

Классик телнең үсеш нәтиҗәсендә хәзерге заман гарәп әдәби теле киң таралган телләрнең берсе. Гыйракта, Сүриядә, Ливанда, Иорданиядә, Мисырда, Гарәп ярымутравында, Мороккода, Алжирда, Тунисга, Ливиядә, Суданда, Мальта утравында һ. б. җирләрдә яшәүче йөз миллионга якын кеше гарәпчә сөйләшә. Шул ук вакытта гарәп илләрендә бердәм, гомумдәүләт теле булган әдәби тел белән беррәттән күп санда җирле шивәләр дә кулланыла. Аларның иң әһәмиятлеләре: Азиядә — Гыйрак шивәсе, Сүрия шивәсе, Африкада — Мисыр һәм Магриб шивәләре. Гарәп әдәби теленә иң якын булган диалект — Сүрия шивәсе.

Гарәп теле (синтетик) флектив телләр группасына керә. Аның һәрбер грамматик формасының нигезендә өч тартыклы тамыр ята. Сүзләрнең төрле формалары барлыкка килү һәрбер сүзнең эчке структурасы үзгәрүенә бәйләнгән (эчке флексия үзгәреше).

Хәзерге заман гарәп әдәби теленең сүз байлыгын төп гарәп сүзләре һәм бик аз күләмдә чит телләрдән кергән сүзләр тәшкил итә.

Синонимия, омонимия һәм күп мәгънәле сүзләр гарәп телендә киң таралган. Сүз ясалуның төп ысуллары — морфологик, синтаксик һәм семантик ысуллар.

## Гарәп әлифбасы

| Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Исеме | Әйтелеше | Аерым хәреф |
|---|---|---|---|---|---|
| ـا | ـا | ا | әлиф | а̄ — ә | ا |
| ـب | ـبـ | بـ | бә̄ | б | ب |
| ـت | ـتـ | تـ | тә̄ | т | ت |
| ـث | ـثـ | ثـ | с̱ә̄ | с̱ | ث |
| ـج | ـجـ | جـ | җӣм | җ | ج |
| ـح | ـحـ | حـ | ха̄ | х | ح |
| ـخ | ـخـ | خـ | х̣а̄ | х̣ | خ |
| ـد | ـد | د | дәл | д | د |
| ـذ | ـذ | ذ | з̱әл | з̱ | ذ |
| ـر | ـر | ر | ра̄ | р | ر |
| ـز | ـز | ز | зәйн | з̣ | ز |
| ـس | ـسـ | سـ | сӣн | с | س |
| ـش | ـشـ | شـ | шин | ш | ش |
| ـص | ـصـ | صـ | с̣а̄д | с̣ | ص |
| ـض | ـضـ | ضـ | д̣а̄д | д̣ | ض |
| ـط | ـطـ | طـ | т̣а̄ | т̣ | ط |
| ـظ | ـظـ | ظـ | з̣а̄ | з̇ | ظ |
| ـع | ـعـ | عـ | ʻайн | г | ع |
| ـغ | ـغـ | غـ | г̣айн | г̣ | غ |
| ـف | ـفـ | فـ | фа̄ | ф | ف |
| ـق | ـقـ | قـ | қа̄ф | қ | ق |
| ـك | ـكـ | كـ | кә̄ф | к | ك |
| ـل | ـلـ | لـ | лә̄м | л | ل |
| ـم | ـمـ | مـ | мӣм | м | م |
| ـن | ـنـ | نـ | нӯн | н | ن |
| ـه | ـهـ | هـ | һа̄ | һ | ه |
| ـو | ـو | و | waw | w | و |
| ـی | ـیـ | یـ | йа̄ | й | ی |
| — | — | — | һәмзә | — | ء |

## Гарәп язуы

Гарәпләр алфавит тәртибендә килгән хәрефләр белән уңнан сулга таба язалар. Хәрефләр дүрт шәкелдә (формада) язылалар: аерым, сүз башында, сүз уртасында һәм сүз ахырында. Гарәп язуында сүзләрнең тартык һәм озын сузык авазлары гына хәрефләр белән билгеләнә. Кыска сузыклар өчен аерым хәрефләр кулланылмый. Сүз дөрес укылсын өчен, тартыклардан соң килгән кыска сузык авазлар кайбер китапларда, мәсәлән, дәреслекләрдә, тартыкның өстенә, астына сызыкчалар һәм өтерләр (хәрәкәләр) куеп белдерелә. Лингвистикада аларны диакритик тамгалар дип йөртәләр. Мәсәлән: м̄ ж̊ л̱ с̊ = مَجْلِسْ мәҗлис (мәҗлес).

Ул хәрәкәләр түбәндәгеләр:

Кыска а (ә) ـَ (фәтхә, татарча „өст“) كَتَبَ кәтәбә.

Кыска и ـِ (кәсрә, татарча „аст“) مَجْلِسْ мәҗлис.

Кыска у[1] ـُ (замма, татарча „өтер“) كُتُبْ кутуб.

Сузык аваз юк ـْ (сәкен) إِلْهَامْ илһам.

Куш тартык ـّ (шәддә) تَكَبُّرْ тәкәббур.

### Кайбер гарәп авазларының транскрипциясе

| | |
|---|---|
| а̄ (ә̄) — озын сузык а (ә) | з̱ — сакау з (ذ) |
| ӣ — озын сузык и | з̣ — каты әйтелешле з (ظ) |
| ӯ — озын сузык у | т̣ — каты әйтелешле т (ط) |
| х̣ — каты әйтелешле х (خ) | д̣ — каты әйтелешле д яки з (ض) |
| х — йомшак әйтелешле х (ح) | қ — тамак төбе к (ق) |
| с̱ — сакау с (ث) | г̣ (ғ) — тамак төбе г (غ һәм ع) |
| с̣ — каты әйтелешле с (ص) | |

1 нче искәрмә: гарәп телендә булмаган авазларны белдерер өчен, фарсыча яки татарча язар өчен гарәп әлифбасына түбәндәге хәрефләр өстәлгән: п — پ; ч — چ; ж — ژ; в — ۋ; г — گ; ң — ڭ.

2 нче искәрмә: гарәп әлифбасында алты хәреф (өстәлгәннәр белән санаганда — сигез) язуда сул яктан, ягъни үзеннән соң килгән хәреф белән тоташмый: а ا; в ۋ, w و; ж ژ; з ز; р ر; з ذ; д د.

[1] Татар телендә *ө, о* ны белдерә.

Мәсәлән: ژورنال — журнал; دوام — дәwам; ذات — зат; رئیس — рәис; ۋاگون — вагун һ. б.

Борынгы заманда татарлар гарәпләр алфавитын һәм орфографиясен бик аз үзгәртеп татарча язганнар. Соңыннан татар теле өчен яраклаштырылган алфавит һәм орфографияләр хасил була, соңгы татар-гарәп алфавиты 1923 нче елны кабул ителә һәм ул иң мөкәммәле була.

**Гарәп-татар алфавитының соңгы, 1923 нче елны кабул ителгән, варианты**

| Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Әйтелеше | Аерым хәреф | Сүз ахырында | Сүз уртасында | Сүз башында | Әйтелеше | Аерым хәреф |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ـع | ـعـ | عـ | г | ع | ـا | ـا | ئا | а | ئا |
| ـف | ـفـ | فـ | ф | ف | ـه | ـه | ئه | ә | ئه |
| ـق | ـقـ | قـ | қ | ق | ـب | ـبـ | بـ | б | ب |
| ـك | ـكـ | كـ | к | ك | ـت | ـتـ | تـ | т | ت |
| ـگ | ـگـ | گـ | г | گ | ـپ | ـپـ | پـ | п | پ |
| ـڭ | ـڭـ | ڭـ | ң | ڭ | ـج | ـجـ | جـ | ж | ج |
| ـل | ـلـ | لـ | л | ل | ـچ | ـچـ | چـ | ч | چ |
| ـم | ـمـ | مـ | м | م | ـح | ـحـ | حـ | х | ح |
| ـن | ـنـ | نـ | н | ن | ـد | ـد | د | д | د |
| ـو | ـو | و | w | و | ـز | ـز | ز | з | ز |
| ـی | ـیـ | ئیـ | и | ئیـ | ـژ | ـژ | ژ | ж | ژ |
| ـو | ـو | ئو | у, ү | ئو | ـس | ـسـ | سـ | с | س |
| ـۇ | ـۇ | ئۇ | о, ө | ئۇ | ـش | ـشـ | شـ | ш | ش |
| ـئ | ـٔـ | ئـ | ы, е | ئـ | | | | | |

Бу әлифба нигезендә татар сүзләрендә булган барлык сузык авазларны хәрефләр белән билгеләргә була, ләкин язуны җиңеләйтү өчен түбәндәге искәрмәләр кертелгән.

1 нче искәрмә: *е, ы* хәрефләре беренче иҗектә һәм ябык иҗекләрдә язылмыйлар, мәсәлән: برکتمه (беркетмә), برکتْتْله (беркетелә), سزق (сызык), سزْلا (сызыла).

2 нче искәрмә: сүз эчендә калын әйтелешле ئا, ق, ع хәрефләре булмаса, сүзнең калынлыгын белдерү өчен аның алдына калынлык билгесе (ٖ) куела. Мәсәлән: ئول—үл (нечкә әйтелеш), ئول — ул (калын әйтелеш), ئون — өн (нечкә әйтелеш), ئون — он (калын әйтелеш) һ. б.

## Татар теленә кергән гарәп сүзләренең фонетик үзенчәлекләре

Мәгълүм ки, татар теле белән гарәп теле арасында бик зур аерма бар. Бу аерма ике телнең һәр тармагында, шул җөмләдән фонетикаларында да күренеп тора. Ләкин татар теленә кергән гарәп сүзләре һәм гыйбарәләре татар теле закончалыкларына буйсындырылган. Бу буйсындыру, „татарлаштыру", башлыча телнең ике бүлегендә, фонетикада һәм морфологиядә башкарыла.

Татар теленә бик күптәннән кергән гарәп сүзләренең байтагы, гасырлар буенча кулланылып килү аркасында, тәмам татарлашып беткәннәр, һәм гарәп телен белмәүчеләр аларны ана теле сүзләре дип уйлыйлар. Ләкин төрле заманда төрле хәрефләр, төрле әлифба һәм төрле орфография кагыйдәләре нигезендә язылган, шулай ук төрле-төрле үзгәрешләргә дучар ителгән гарәп-татар сүзләренең кайберләре хәзерге заман телебездә орфоэпик һәм орфографик нормаларга салынмаган, төрле кеше тарафыннан төрлечә әйтеләләр һәм хәтта төрлечә язылалар. Бу хәл, үз нәүбәтендә, мәгънәви читенлекләр дә тудыра.

Шул кимчелекләрдән арыну юлын ачу максаты белән, без түбәндәге кайбер фонетик мәсьәләләргә туктыйбыз[1].

### Сузык авазлар

#### 1. Татар сүзләрендә сузыклар гармониясе

Хәзерге татар әдәби телендә 10 сузык аваз бар. (Рус теленнән кергән *э* һәм *о* белән санаганда — 12 сузык фонема.)

Телнең торышы буенча сузыкларны классификацияләгәндә, телнең алга һәм артка таба хәрәкәте, ягъни ятма (горизонталь) хәрәкәте буенча, сузык авазлар алгы һәм арткы рәт сузыкларына бүленәләр:

а) алгы рәт сузыклар: *и, ә, ү, е, ө* (нечкә авазлар),

б) арткы рәт сузыклар: *ый, а, у, о, ы* (калын авазлар).

Татар телендә сузыкларны арткы һәм алгыларга бүлүнең зур әһәмияте бар, чөнки сузыклар гармониясе (сингармонизм) законы

---

[1] Татар теле фонетикасы буенча кайбер мәгълүматлар Р. Шакированың „Хәзерге татар теле фонетикасына кереш" исемле китабыннан алынды. Казан. Таткнигоиздат, 1954 ел.

нигезендә, сузыкларның комбинатор үзгәрешләре[1] нинди дә булса бер рәт эчендә генә булырга мөмкин: я арткы рәт, я алгы рәт. Бер сүздә, кагыйдә буларак, арткы һәм алгы рәт сузыклары чиратлашып килә алмыйлар. (Мәсәлән: *бәрүләреннәнмени* — алгы рәт сузыклар гына; *баруларыннанмыный* — арткы рәт сузыклар гына.

Гарәп телендә сингармонизм законы юк, шуна күрә анда татар теле табигатенә капма-каршы рәвештә бер сүздә алгы һәм арткы рәт сузыклары килә ала, мәсәлән: افراط ифрат, كتاب китаб, حساب хисаб, دوام дәвам, تصوير тасвир һ. б. шуның шикелле сүзләр.

Татар теленә кергән гарәп сүзләрендә сузыклар гармониясе я очраклы рәвештә була, мәсәлән: مقصد максад; مكتب мәктәб, مدرسه мәдрәсә һ. б., я гарәп сүзләре татар теленә хас булган сингармонизм законына буйсындырылган булалар, мәсәлән:

مومكن мумкин → мөмкин,

مخبر мухбир → мөхбир,

بلا бәла̄ → бәлә (орф. бәла) һ. б. шуның шикелле сүзләр.

Татар телендә гарәп сүзләрен сузыклар гармониясе закончалыгына буйсындыру, гарәп сүзләренең безгә бик күптәннән кереп калганына карамастан, әле дә дәвам итә. Мәсәлән:

| язылa: | | укыла: |
|---|---|---|
| сәлам | سلام | сәләм, |
| бәла | بلا | бәлә, |
| һәлак | هلاك | һәләк |

һ. б. шуның шикелле сүзләр.

Гомумән, татар телендә сөйләүчеләрнең сүзне мөмкин кадәр нечкәртебрәк әйтергә омтылышы түбәндәге мисаллардан да күренә. Гарәп телендә калын әйтелешле тартыклардан соң сузыклар да калын әйтелә. Әмма татар теленә кергән гарәп сүзләрендә бер генә нечкә әйтелешле сузык аваз булса да, ул калын әйтелешле тартыктан соң килгән калын сузыкны да нечкәртә.

Мәсәлән:

| гарәпчә: | татарча: |
|---|---|
| قلم каләм → | қәләм (орф. каләм) |
| صحنه сахнә → | сәхнә |
| صنعة сан'әт → | сән'әт (орф. сәнгать) |
| نصرالدين Насру-д-дин → | Насреттин (орф. Насретдин). |

---

[1] Авазларның комбинатор үзгәрүләре — тоташ сөйләмдә авазларның кара-каршы тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр.

## 2. Сузыкларның озынлыгы-кыскалыгы

Татар телендәге сузыкларны акустик яктан чыгып классификацияләгәндә, аларны озын сузыкларга һәм кыска сузыкларга бүләргә мөмкин:

а) озын (сузылмалы) сузыклар: *ә, а, у, ү, и, ый;*

б) кыска сузыклар: *о, ө, ы, э (е).*

Бу бүленеш сузыкларның тембры (төп сыйфатлары) белән бәйләнгән, шуның өчен татар телендәге сузыкларның күләм ягы аларның даими сыйфаты булып тора. Мәсәлән, *о, ы, э, (е)* авазлары, төрле фонетик чолганышларда килүләренә карамастан, *а, ә, у, ү, и, ый* авазларыннан һәрвакыт кыскараклар.

Әмма татар телендә озын һәм кыска сузыклар бер-берсенә каршы куелып алынмыйлар, ягъни бер үк сузыкның озынлыгы яки кыскалыгы ике төрле фонема хасил итми һәм сүзнең мәгънәсен һич тә үзгәртми.

Ләкин гарәп телендә нәкъ киресенчә. Анда озын һәм кыска сузыклар аерым фонемалар булып торалар һәм сүзнең мәгънәсен бөтенләй үзгәртәләр.

Гарәп телендәге алты сузыкның өчесе озын, өчесе кыска сузыклар дип санала:

а) озын сузыклар: $\bar{а}$, $\bar{и}$, $\bar{у}$;

б) кыска сузыклар: *а, и, у.*

$\bar{а}$, *а* сузыкларның нечкә вариантлары булып $\bar{ә}$, *ә* авазы йөри, ләкин ул фонема түгел, чөнки *а* яки *ә* әйтелүдән сүзнең мәгънәсе үзгәрми, әмма кыска сузык *а* урынына озын сузык $\bar{а}$ (*ә* — $\bar{ә}$) яки, киресенчә, озын сузык $\bar{а}$ урынына кыска *а* әйтелсә, сүзнең мәгънәсе бөтенләй башка була. Мәсәлән: عالم ‚гāләм — дөнья, җир йөзе; علم ‚галәм — әләм, байрак; كاتب кәтәбә — язышты, كتب кәтәбә — язды.

Гарәп теленнән алынган сүзләрдәге озын һәм кыска сузык авазлар (фонемалар) татар телендә озынлык-кыскалык белән аерылмый. Татар теленә кергән гарәп сүзенең озын һәм кыска сузыклары, татарлашканнан соң, калынлык-нечкәлек белән аерылалар. Мәсәлән: кә$\bar{т}$иб ⟶ катип, сә$\bar{л}$әм ⟶ сәлам һ. б.

Татар телендә:

а) кыска сузык *а,* сузыкның хәтта калын әйтелешле тартыктан соң килүенә дә карамастан, *ә* итеп укыла;

б) кыска сузык *и — и* итеп укыла;

в) кыска сузык *у* гарәп фонетикасына бөтенләй ят булган аваз *ө (е)* яки калын тартыклардан соң кайчакларда гына *о (ы)* белән алмаштырыла. Мондый үзгәрешләргә, татар телендәге сузыклар гармониясе законы, татар телендә сузыкның озынлык-кыскалык белән аерылмавы һәм гарәптәге кыска әйтелешле *а, у* авазларының татарның үзендәге *ө, о, ә* авазларына якын янгырашы белән бергә, иске гарәп орфографиясе дә тәэсир иткән, әлбәттә. Мәсәлән: قلم ҡаләм — ҡәләм, كتب ‚кутуб — көтеп (китаплар), قطب ҡутуб — ко-

тып (полюс), مخبر мухбир — мәхбир (хәбәрче), ممكن мумкин — мөмкин һ. б.

Озын сузык авазларны язуда билгеләү өчен, гарәп әлифбасында өч аерым хәреф бар: ا (әлиф), و (waw), ى (йа).

а) Әлиф (ا) озын сузык $\bar{a}$ (яки нечкә әйтелешле сүзләрдә $\bar{a}$ ның вариантын $\bar{ә}$) ны белдерә, мәсәлән: طاهر тāһир — ару, пакь, таза, саф; كاتب кāтиб — язучы, секретарь; معلومات мәгълумāт — хәбәрләр, белешмәләр (сведения).

Сүз башында язылганда әлиф: 1) өстендә фәтхә اَ булса, *ә* не яки *а* ны белдерә; 2) өстендә замма اُ булса, *ө*, *о* ны белдерә; 3) астында кәсрә اِ булса, *и* не белдерә.

Мәсәлән:

1) آمير әмир, آصل асыл; 2) اُمراء өмәра (әмирләр); 3) اِلهام илһам.

Татар теленә кергән гарәп сүзләрендә озын сузык $\bar{a}$ ($\bar{ә}$) не белдерүче әлиф (сүз эчендә яки азагында) күбесенчә *а* итеп укыла. Мәсәлән: معارف мәгариф, ماهر маһир, سلام сәлам, بلا бәла һ. б.

Искәрмә: әлифнең اسماعيل Исмәгил, ساعت сәгәт шикелле сүзләрдә *ә* итеп укылышы сирәк очрый.

б) Waw (و) озын сузык аваз $\bar{у}$ ны белдерә. Мәсәлән: حكومت хук$\bar{у}$мә (хөкүмәт), مرحوم мәрх$\bar{у}$м, معلوم мәгл$\bar{у}$м һ. б.

Waw (و) хәрефе гарәп язуында шулай ук ирен-ирен тартык аваз *w* ны белдерә һәм татар телендә тартык аваз *w* ны белдергәндә рус хәрефе *в* яки сүз азагында *у* (*ү*) белән алмаштырыла, мәсәлән: وطن watан — ватан, ولى wәли — вәли, عضو гадуw, газу, علو гулуw — гөлү һ. б.

Waw (و) озын сузык $\bar{у}$ ны белдерсә, ул, башлыча, гарәп теленә бөтенләй ят аваз *ү* яки сирәк очракларда *у* белән алмаштырыла. Мәсәлән: حكومت хук$\bar{у}$мәт — хөкүмәт, مرحوم мәрх$\bar{у}$м — мәрхүм, مكتوب мәкт$\bar{у}$б — мәктүп һ. б.

в) Йа (ى) озын сузык аваз $\bar{и}$ не яки ярым сузык *й* не белдерә. Татар телендә шул ук *и*, *й* авазлары белән алмаштырыла. Мәсәлән:

آسير әсир, نجيب Нәҗиб, مريم Мәрйәм һ. б. шуның шикелле сүзләр.

Кыска сузык *и* бер иҗекле сүзләрдә *е* гә алмашуы ихтимал, мәсәлән:

سِرّ (сирр) — сер, جِنّ жинн (жен) һ. б. сүзләр.

## Тартык авазлар

1) Гарәп телендә татар телендәгечә 25 тартык аваз бар. Сүзнең калын яки нечкә әйтелеше татар телендә сузыкның калын яки нечкә булуына бәйле. Гарәп тартыкларының күбесе я калын гына, я нечкә генә була. Тартыклар язуда аерым хәрефләр белән билгеләнә, һәм сүзнең калын яки нечкә әйтелеше татар телендәге кебек сузык авазга түгел, бәлки тартыкка бәйле була.

Татар теленә кергән гарәп сүзләрендә тартык авазлар түбәндәге татар авазлары (хәрефләре) белән алмаштырылалар:

а) Калын әйтелешле خ (х) һәм нечкә әйтелешле ح (х) бер үк калын тартык *х* белән белдерелә. Мәсәлән: خبر (хабәр) — хәбәр, خط (хатт) — хат, مرحوم (мәрхум) — мәрхүм, حربی (харбий) — хәрби, حیلة (хилә) — хәйлә һ. б. сүзләр.

б) Калын әйтелешле ط (т) һәм нечкә әйтелешле ت (т) бер үк *т* белән бирелә. Мәсәлән, طاهر (Таһир) — Таһир, تاریخ (тәрих) — тарих, مفتوحه (Мәфтуха) — Мәфтүхә һ. б. сүзләр.

в) Калын әйтелешле ض (д), ظ (з), сакау ذ (з) һәм нечкә ز (з) — дүртесе дә бер *з* авазы (хәрефе) белән белдереләләр. Мәсәлән: رمضان (рамадан) — рамазан, ضرر (дарар) — зарар, ظلم (зулм) — золым, زینب (Зәйнәб) — Зәйнәп, ذات (зат) — зат, ذاکر (Закир) — Закир һ. б. сүзләр.

г) Калын әйтелешле ص (с), сакау ث (с) һәм нечкә س (с) бер үк *с* белән бирелә, мәсәлән: صحنه (сахнә) — сәхнә, ساعت (сагат) — сәгать, حساب (хисаб) — хисап, ثانیه (Сәния) — Сания, مثلا (мәсәлән) — мәсәлән һ. б. сүзләр.

д) Калын әйтелешле غ (гайн) белән нечкә әйтелешле ع (айн) татар телендә бер үк *г* авазы белән белдереләләр, мәсәлән: غیر (гайр) — гәйре, عالم (галим) — галим, معارف (мәгариф) — мәгариф һ. б. сүзләр.

е) Калын тартык ق (қ) белән нечкә ك (к) татар телендәге шундый ук тартыкларга туры киләләр. Мәсәлән: قلم (қаләм) — қәләм, قدر (қадәр) — қәдәр, کتاب (китаб) — китап, فداکار (фидакар) — фидакарь һ. б. сүзләр.

ж) Гарәп теленә генә хас булган тавышсыз тартык һ ә м з ә (ء) татар телендә сүзнең башында һәм азагында бөтенләй укылмый, сүз уртасында очраган чакта, хәзерге татар орфографиясендә ул *э* хәрефе белән билгеләнә. Мәсәлән: تأمین (тәэмин) — тәэмин, مؤمین (муэмин) — мөэмин, بلاء (бәлаэ) — бәла һ. б.

2) Татар телендә сүзнең азагында яңгырау тартык аваз һәрвакыт саңгыраулаша. Гарәп теленнән кергән сүзләр шушы кагыйдәгә буйсынып үзгәрәләр. Бу бигрәк тә *б* һәм *д* авазларында ачык күренә, мәсәлән: ایجاد (ижа̄д) — ижат, مکتوب (мәктӯб) — мәктүп, کتاب (кита̄б) — китап һ. б. сүзләр.

Гарәп теленнән кергән кушма сүзләрдә тартыкларның саңгыраулашуы сүз уртасында да очрый, мәсәлән: نصرالدين (Насру-д-дӣн) — Насретдин, زين الدين (Зәйну-д-дӣн) — Зәйнетдин һ. б.

Бу күренеш безнең телебез өчен бик табигый, һәм шушы фонетик үзенчәлекләр орфографиябездә дә чагылырга тиеш, әлбәттә. Хәзерге вакытта мондый гарәп сүзләрендәге икеләшкән *д* хәрефе *тд* рәвешендә языла.

3) ة хәрефе (гарәпчә тә-мәрбута, татарча түгәрәк *т*) гарәп телендә мөәннәс (жен. род) исемнәренең азагында языла. Ялгыз сүзләрдә бу хәреф, кагыйдә буларак, укылмый, ул җөмлә эчендә булганда гына укыла.

Татар теленә кергән сүзләрдә ул я *т* итеп укылып ت хәрефе белән языла, я *ә* итеп укылып ноктасыз ه рәвешендә языла, мәсәлән: ترجمة (тәрҗумәтун) — ترجمه тәрҗемә, ساعة са̄гәтун) — ساعت сәгәт һ. б. сүзләр.

Фарсыча төзелгән гыйбарәдә ه (*ә*) дәп соң фарсы изафәсе *и* укыла (ه өстенә һәмзә хәрефе куела), мәсәлән: ترجمهٔ حال тәрҗемәи-хәл — биография, تربيهٔ بدن тәрбияи-бәдән — физкультура.

4) Гарәп сүзләрендә еш кына икеләшкән (куш) тартыклар очрый. Ул тартыклар сүзнең башында, уртасында яки ахырында булалар.

а) Сүз башында булган куш тартыклар татар телендә сирәк, билгелелек артикле „әл“ (әлифләм) булган сүзләрдә генә очрый һәм гарәп телендә укылган шикелле үк икеләштереп укыла (кара: „Артикль мәсьәләсе“, 843 бит). Мәсәлән: السلام عليكم (әс-сәла̄му гәләйкем) — тынычлык булсын сезгә (исәнмесез мәгънәсендә), بالتشكر (бит-тәшәккер) — рәхмәт белән, بالضرور (биз-зарур) — кирәклектән, кирәк булганга.

б) Сүз уртасында булган куш тартыклар шулай ук сакланалар, мәсәлән: تکبّر тәкәббер — масаю, борын чөю; ترقی тәрәккый — прогресс; بالتشكر бит-тәшәккер — рәхмәт белән.

в) Сүзнең азагында булган куш тартыклар татар теленә кергән сүзләрдә төрле очракта (һәм төрле чорда) төрлечә әйтеләләр. Әгәр дә куш тартыклар булган сүз гарәп сүз тезмәсендә очрый икән, аның куш тартыклары саклана, чөнки алар сүз эчендә калган була, ә мондый күренеш татар теленә үзенә дә хас, мәсәлән: (татарча) *урманнарда*; (гарәпчә) حق الوالدين хаккый-ль-валидәйн — ата-ана хакы.

5) Татарча төзелгән җөмлә эчендә очраганда сүзнең ахырындагы куш тартыклар элегрәк чорда һәрвакыт укыла торган булганнар, мәсәлән: حِسّ (хисс) — хис, тойгы.

Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл *хиссеми*...
(Г. Тук., „Туган җиремә".)

حَقّ хакк — хак.

„Һәр кешенең *хаккы* тигез булсын!" дип...
(М. Гафури, „1906 елдан 1907 елга васыять".)

Хәзерге заманда сүз ахырындагы куш тартыкларның, кагыйдә. буларак, берсе генә укыла. Мәсәлән:

Кунак итеп кенә туктаталмыйм
Беркайда да мин үз *хисемне*...
(Ә. Давыдов.)

„Алар милли бәйрәмнең үги балалары түгел, ирләрнең сабан туенда катнашырга никадәр *хаклары* булса, хатын-кызларыбызның да шулкадәр *хаклары* бар". (Ф. Әмир, „Сабан туенда".)

Аерым сүзләрдә татар телендә сүзнең азагында бер генә тартык укыла, мәсәлән: حق хак, حس хис, فن фән, حر хөр, سر сер һ. б. шуның шикелле сүзләр.

## Басым мәсьәләсе

Мәгълүм булганча, татар телендә сүз басымы динамик басым (көч басымы) дип санала. Кагыйдә буларак, бүтән төрки телләрдә булган шикелле үк, татар телендә басым сүзнең соңгы иҗегенә төшә. Мәсәлән:

*Кешелéк, барырлáр, югарыдá, шәһәр, иптәш, күршé, тәрәзә, сузы́к* һ. б. сүзләр.

Гарәп телендә басым:

а) Сүз эчендә озын сузыклы иҗек булса, шушы озын сузыклы иҗеккә төшә, мәсәлән: افتخار ифтихар, كاتب кәтиб شاعر шаґир, معلوم мәгълүм һ. б. сүзләр.

Сүздә озын сузыклы иҗек ике булса, беренче озын сузыклы иҗеккә ярым басым, икенче озын сузыклы иҗеккә тулы басым төшә. Мәсәлән:

بساتين бәсатин — бәстаннар, бакчалар; مساكين мәсакин — мескеннәр һ. б.

б) Сүз эчендә озын сузык булмаса, басым сүзнең азагыннан санаганда өченче иҗеккә төшә, мәсәлән:

مدرسة мәдрәсәт(ун), مكتب мәктәб(ун), منتقد мөнтәкид(ун) сүзләрендәге шикелле.

в) Ике иҗекле генә сүз булса, басым беренче иҗеккә төшә, мәсәлән: درس да́рс — дәрес, مصدر — ма́сдар һ. б. сүзләр.

Татар теленә кергән гарәп сүзләрендә басым үзгәрә, ул, татар фонетикасы закончалыгына буйсынып, сүзнең соңгы иҗегенә күчә, мәсәлән:

мәдрә́сә → мәдрәсә́, шәги́р → шаги́р (орф. шагыйрь), мәктә́б → мәктә́п, мөнтә́қид → мөнтәқи́д (орф. мөнтәкыйть) һ. б. сүзләр.

## Гарәп телендә сүз ясалу принциплары

Гарәп телендә сүз ясалу юлларының иң әһәмиятлесе — сүзнең эчке флексиясе үзгәрү юлы. Бу исә яңа сүз төрле кушымчалар ялгап түгел, бәлки төп сүзнең үзенең авазларын (хәрефләрен) алмаштыру яки аларның урыннары алмашу юлы белән ясалу дигән сүз.

Гарәп телендә сүзләрнең күпчелеге өч тартыклы тамырдан тора. Тамыр сүзнең гомуми идеясен генә чагылдыра, ул беркайчан да конкрет мәгънә аңлатмый. Конкрет мәгънә тартыклардан гына торган тамырга сузыклар, ә кайчакта өстәмә тартыклар да өстәгәннән соң гына туа. Өстәмә авазлар (хәрефләр) тамырның алдына (алкушымча—префикс), уртасына (инфикс) һәм азагына (кушымча — суффикс) куелалар. Ләкин алар очраган бер урынга түгел, бәлки телнең билгеле закончалыгы буенча куелалар һәм шуның нәтиҗәсендә төрле мәгънә тудыралар, мәсәлән:

а) **ХКМ** (حكم) тамырын алыйк. Бу өч тартык аваз (хәреф) гомумән хөкем сөрү, өстенлек идеясен чагылдыра. Без **х** белән **к** (ягъни тамырның беренче белән икенче тартыклары) арасына ***а***, к белән **м** (икенче белән өченче тартык) арасына ***и*** авазы өстәсәк, **ХаКиМ** сүзе килеп чыга. Бу сүз, формасы, үлчәве буенча, гарәп телендә сыйфат фигыль төркеменә (причастие действительного залога) керә һәм „хөкем итүче“, „судья“ һ. б. ш. конкрет мәгънәне аңлата. Шул ук тамырны бүтән үлчәүләргә (калыпларга) салып карасак, сүзнең эчке структурасы үзгәрү нәтиҗәсендә, төрле-төрле конкрет мәгънәле яңа сүзләр ясалганын күрәбез. Мәсәлән **ХөКеМ** (масдар) — фикер йөртү, өстенлек итү; **мәХКәМә** (урын исеме) — суд, хөкем итә торган урын; **мәХКүМ** (үтемсез сыйфат фигыль) — хөкем ителгән (осужденный); **мәХКүМийәт** (абстракт исем) — хөкем ителгәнлек (осужденность); **ХөКәМа** (хаким сүзенең күплеге) — хөкем итүчеләр, хөкем сөрүчеләр; **ХөКүМәт** (исем) — хөкүмәт һ. б. бик күп төрле сүзләр.

б) **ЛФТ** (لفت) тамырын алып карыйк. Бу өч тартыклы тамырда конкрет мәгънә юк, бәлки „бору“, „әйләндерү“ дигән гомуми идея генә бар. Тамыр алдына ***и***, тамырның беренче тартыгыннан соң ***ти*** иҗеге, икенче тартыгыннан (***ф*** дан) соң ***а*** куелса, **иЛтиФаТ** дигән сүз ясала. Гарәп телендә бу сүз масдар, ягъни исем фигыль төркеменә керә һәм „әйләнеп карау“ (димәк, берәүгә таба башын борып карау), „игътибар итү“ мәгънәсен белдерә.

**КТБ** (كتب) тамырын алыйк. Бу тамырның гомуми идеясе „язу". Гарәп телендә берәр эшнең урынын күрсәтүче исемнәр бар. Шул исемнәр тамырының алдына *мә* ижеге, тамырның икенче тартыгыннан (хәрефеннән) соң *ә* сузыгы өстәсәк, **мәКТәБ** (مكتب) сүзе килеп чыга. Бу сүз „язу урыны", „яза торган урын", ягъни „мәктәп" дигән конкрет мәгънә бирә.

Гарәп теленең төрле сүз төркемнәреннән алынган сүзләрнең күбесе татар телендә башлыча исем төркеменә керәләр, ягъни гарәп сыйфатлары, масдарлары, сыйфат фигыльләре, саннары бездә күбесенчә исемләшкән (субстантивлашкан) формада очрыйлар.

Мәсәлән, *тәвәккәл* сүзе гарәп телендә масдар төркемчәсенә керә. Татар телендә бу сүз иң элек сыйфат булып кулланыла — *тәвәккәл кеше.* Шул ук сүзгә *-лек* кушымчасы өстәлә дә, абстракт исем *тәвәкәллек* килеп чыга, яки *-сез* кушымчасы ярдәмендә сыйфатның юклык белдерүче төре ясала — *тәвәккәлсез.* Алыйк *тәнкыйд* сүзен. Бу сүз татар грамматикасы нормаларына бөтенләй буйсынган һәм гарәп телендә икенче бап масдары булганлыгы бер дә сизелми дип әйтеп була. *Тәнкыйд* бездә саф исем (тәнкыйть, тәнкыйтьче) ролендә йөри. Шулай ук гарәптә үтемсез сыйфат фигыль булган *мәхрүм* сүзе дә *-лек* кушымчасы ярдәмендә абстракт төшенчә белдерүче исемгә әверелә — *мәхрүмлек* (житешмәүчәнлек, юклык). Димәк, татар теле морфологиясе кагыйдәләренә буйсынып гарәп сүзләре төрле-төрле формаларга да керәләр.

Әмма бу татар телендә гарәптән алынган саф сыйфатлар, масдарлар, сыйфат фигыльләр үз функцияләрендә бөтенләй кулланылмый дигән сүз түгел. Шунлыктан без монда, гарәп грамматикасы күзлегеннән карап, татар теленә алынган төрле гарәп (һәм өлешчә фарсы) сүзләренең төп грамматик үзенчәлекләренә тукталабыз.

## Исем

### Грамматик җенес

Гарәп исемнәре, рус исемнәре шикелле, татар исемнәреннән үзләрендә грамматик җенес категориясе булу белән аерылалар.

Гарәп телендә ике грамматик җенес бар: *мөзәккәр* (мужской род) һәм *мөәннәс* (женский род).

Гарәп телендә *мөәннәс* исемнәр формаль яктан *мөзәккәр* исемнәрдән түбәндәге кушымчалары белән аерылалар: $\bar{a}$ (иске язуда — әлиф ا): سماء сәма̄ — күк; صحراء сахра̄ — чүл, дала; دنيا дөнйа̄ — дөнья;

*а-ә* (иске язуда түгәрәк „*т*" — ة, ه): مدرسة мәдрәсә, معلمة мөгаллимә, قطعة кыйтга;

*әт-ат-ят* (иске язуда ات ،يات) سياست сиясәт (сәясәт) — политика; سياحت сәяхәт — гизү; محبة мәхәббәт — ярату; تعليمات тәгълимат — өйрәтүләр; معلومات мәгълүмат — хәбәрләр; آدبيات әдәбият — язма әсәрләр; نشريات нәшрият — китап басу һәм тарату.

Гарәпчә яки фарсыча сүз тезмәсендә гарәп сыйфатлары сыйфатланмышлары белән грамматик җенестә ярашалар, мәсәлән: مدرسهٔ جدیده (ф) — мәдрәсән җәдидә — яңа мәдрәсә; المدرسةالجديدة (г) — әл-медрәсәту-л-җәдидә — яңа мәдрәсә.

Татар телендә гарәп сүзләренең җенес аерымлыгын без сизмибез, фәкать хатын-кызларга караган сүзләрдә генә, бигрәк тә хатын-кыз исемнәрендә бу категорияне кулланабыз, мәсәлән: معلم мөгаллим — укытучы, ир кеше; معلمة мөгаллимә — укытучы, хатын кеше, шулай ук *Кәрим—Кәримә, Нәкый—Нәкыя, Шакир—Шакирә, Әмин—Әминә* һ. б. шуның шикелле кеше исемнәре.

Элекке әдәбиятта да гарәп сүзенең мөәннәстә килүе бик сирәк очрый торган хәл. Мәсәлән, Г. Тукайның „Булмаса" шигырендә саф гарәпчә кулланылган мөәннәс исем очрый:

Бирмәде Ләйлә кеби ***мәхбүбәгә*** дөнья бәһа,
Ул болай бер кыз гына, каршында мәҗнүн булмаса.

## САН КАТЕГОРИЯСЕ

Гарәп телендә сүзләр берлек, икелек һәм күплек санында килә.

### 1. Икелек саны

Икелек саны берлеккә ***-ан, -әйен*** (ان، ين) кушымчасы ялгау юлы белән ясала, мәсәлән: نهر нәһер — نهران нәһран яки نهرين нәһрәйен — ике елга; طرف тараф — طرفين тарафәйен — ике як; والد (wалид) — тудыручы, والدين (wалидәйен) — ике тудыручы, ата-ана.

Икелек санындагы гарәп исемнәре бездә бик сирәк очрыйлар.

### 2. Күплек саны

Татар теленә кергән гарәп исемнәренең күбесе берлектә, әлбәттә. Ләкин кайбер сүзләрнең күплек формалары да кулланыла. Дөрес, элегрәк күплектәге сүз күплек мәгънәсендә кулланылган булса да, гарәп теле белән таныш булмаган татар кешесенә бу гарәп сүзләренең күплектә булганлыгы хәзерге вакытта бер дә сизелми, мәсәлән:

Кыйраәт әйләдем, әзбәрләдем бән җөмлә *асарең*,
Керен гөлзарыңа, бән дә тәнавел иттем *әсмарең*...
(Укып чыктым, ятладым мин бөтен *әсәр*ләреңне,
Кереп гөлбакчаңа, *җимеш*ләреңнән авыз иттем.)

(Г. Тук., „Пушкинга".)

Без хәзер күплек санында килгән гарәп сүзләрен күбрәк семантик яктан аерабыз, мәсәлән:

حق — хаққ (орф. хак) (берлек) һәм حقوق хоқуқ (күплек) сүзләре; хақ — күбесенчә гади (гомуми) хак мәгънәсендә йөри, хоқук — политик хак мәгънәсендә кулланыла.

Без элек чикләндек *хокукта*,
Җигелдек алпавыт эшенә ..
(М. Җәлил.)

...*Хаккым* бармы минем абынырга,
*Хаккым* бармы арып калырга?..

(М. Җәлил, „Ышанма".)

Бер төркем сүзләр грамматик формалары белән күплек санында килсәләр дә, татар телендә алар берлек булып кулланылалар. Мәсәлән, *мәгълумат, тәгълимат* һ. б. шуның шикелле гарәпчә күплектәге сүзләр.

Күплек саны гарәп телендә ике төрле юл белән ясала:

1) Кушымчалар кушу юлы белән. Бу юл белән ясалган күплек саны „бөтен" күплек саны дип йөртелә.

2) Берлектәге сүзнең сузык авазларын урыннарыннан күчерү, я, бөтенләй төшереп, сүзнең төрле урынына яңа сузыклар өстәү юлы белән. Бу юл белән ясалган күплек саны „ватык" күплек саны дип йөртелә.

### „Бөтен" күплек саны

а) Күплек саны ясаучы *-ат* (ات) кушымчасы, мәсәлән:

берлек — күплек

معلوم (мәгълүм) — معلومات (мәгълүмат) — хәбәрләр (сведения);

تعليم (тәгълим) — تعليمات (тәгълимат) — белем, өйрәнү (учение);

معلمه (мөгаллимә) — معلمات (мөгаллимат) — мөгаллимәләр (учительницы).

Югарыдагы мисалдан чыгып, без *-ат* кушымчасы исемләшкән сыйфат фигыльләргә (мәгълүм), исемләшкән масдарларга (тәгълим) һәм мөэннәстә (жен. род) булган исемнәргә (мөгаллимә) ялгана дип әйтә алабыз. Татар телендә мондый гарәпчә күплек санында килгән сүзләргә татарча күплек саны кушымчасы *-ләр-лар* ялгана, мәсәлән: „Мәктәпкә керүемнең икенче елында миңа хәез-нифаслар хакында да бик кыйммәтле *мәгълүматлар* бирделәр". (Ф. Әмир., „Минем тәрҗемәи хәлем".)

б) Күплек саны ясаучы *-ун, -ин* (ون, ين) кушымчасы ир женесенә караган мөзәккәр сүзләрнең азагына ялгана, мәсәлән:

مسلم (муслим) — мөселман, مسلمون (муслимун) — мөселманнар;

مستمع (мустәмиг) — тыңлап торучы, مستمعين (мөстәмигин) — тыңлап торучылар.

„Хикәяләр китереп *мөстәмигин*нәрнең күңелен хуш кылырлар..." (К. Нас., „Фәвакиһелҗөләса".)

в) Күплек саны ясаучы *-ийат (-ият)* يات кушымчасы. Бу кушымча сүзнең күплектә булганлыгыннан бигрәк аңа түбәндәге мәгънәләрнең берсен бирә:
фәннәр исемен (атамасын) белдерү;
идеяләр һәм предметлар (әйберләр) бердәмлеген белдерү;
абстракт төшенчәләрне белдерү.

Мәсәлән: شرق (шәрқ) — көнчыгыш, شرقيات (шәрқийат) шәрқыят — көнчыгышны өйрәнү фәне (востоковедение); مصر (миср) — Мисыр, مصريات (мисрийат) мисрият — Мисырны өйрәнү фәне (египтология); ادب (әдәб) — әдәп, тәрбия, ادبيات (әдәбийат) әдәбият (литература); نظر (назар) — караш, نظريات (назарийат) — теория; نشر (нәшер) — тарату, نشريات (нәшрийат) — издательство (конкретлашкан мәгънәдә); فكر (фикер) — уй, فكريات (фикрийат) — идеология.

„Гомумән, мәҗмуга әдәбиятыбыз белән иштигаль итүчеләрнең җөмләсенең дикъкатьләрен җәлеп итәрлек вә Габдулла Әфәнде *муаффәкыяте* белән шаян тәбриктер". (Ф. Әмир., „Габдулла Тукаев шигырьләре".)

Бу җөмләдә *муаффәкыят* сүзе „уңыш", „казаныш" мәгънәсен аңлата, ягъни берәр предметның күплеген түгел, бәлки абстракт төшенчәне белдерә.

## „Ватык" күплек саны

Югарыда әйткәнебезчә, гарәп телендә күплек саны кушымчасыз, сүзне „ватып", аның сузыкларын алмаштыру ярдәмендә дә ясала.

„Ватык" күплекнең төрләре бик күп булганга, без татар әдәбиятында ешрак очрый торган берлекнең алдына *ә* авазы өстәп, беренче сузыкны төшерү һәм икенче сузыкны *а* га алмаштыру юлы белән ясалган күплекләргә берничә мисал гына китереп чикләнәбез, мәсәлән:

| берлек саны | күплек саны |
|---|---|
| فرس (фәрәс) — ат, | افراس (әфрас) — атлар; |
| شخص (шәхес) — кеше, зат, | اشخاص (әшхас) — шәхесләр; |
| شعر (шиѓер) — шигырь, | اشعار (әшѓар) — шигырьләр; |
| خبر (хәбәр) — хәбәр, | اخبار (әхбар) — хәбәрләр; |
| طرف (тараф) — як, | اطراف (әтраф) — яклар; |
| عمل (ѓамәл) — эш, | اعمال (әѓмал) — эшләр һ. б. |

...Без күчәрбез иң элек күчсен безем *әмсарымыз* (шәһәрләребез),
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем *әгъсарымыз* (гасырларыбыз)...

(Г. Тук., „Китмибез".)

## Абстракт исемнәр

Татар телендә *-лык, -лек* кушымчасы ярдәмендә кайбер исемнәрдән кешелек, егетлек, батырлык шикелле абстракт төшенчәләрне белдерүче сүзләр ясала.

Югарыда әйткәнебезчә, гарәп телендә абстракт төшенчәле исемнәр *-ийәт, -ийат (-ият)* кушымчасы ярдәмендә барлыкка килә. Бу кушымча башлыча сыйфат фигыльләргә һәм кайбер исемнәргә генә ялгана. Фигыль, рәвеш һәм асыл сыйфаттан абстракт исемнәр ясалмый. Мәсәлән:

كاتب (ка̄тиб) — язучы,

كاتبيت (ка̄тибийәт) — язучылык;

انسان (инса̄н) — кеше,

انسانيت (инса̄нийәт) — кешелек (человечество), гуманизм;

حيوان (хайва̄н) — хайван, җанвар,

حيوانيت (хайва̄нийәт) — хайванлык, җанварлык;

عصفور (гусфӯр) — чыпчык,

عصفوريت (гусфӯрийәт) — купшылык (пижонство);

مدنى (мәдәни) — әдәпле, культуралы,

مدنيت (мәдәнийәт) — культура, цивилизация (һ. б. шуның шикелле сүзләр).

## Масдар (исем фигыль) һәм сыйфат фигыль

Татар теленә кергән гарәп сүзләренең (гарәп грамматикасыннан чыгып караганда) күбесе я масдар, я сыйфат фигыль, я исем була.

Исем белән фигыль арасында торган бер төркемчә сүзләр гарәп телендә масдар дип йөртелә һәм ул татар теленә *-у, -ү* бетемле исем фигыль белән тәрҗемә ителә (русча „отглагольное имя, имя действия").

Сыйфат фигыль дип татар телендә *-че, -гән, -се, -чәк* кушымчалары ярдәмендә ясалган фигыльләргә әйтәләр. Гарәп телендә моңа муафикъ сүз төркемчәсе (اسم الفاعل) исеме-фагыйль белән (اسم المفعول) исеме-мәфгуль була. Беренчесе аның русча „причастие действительного залога", икенчесе „причастие страдательного залога". Татар телендә „сыйфат фигыль" дигән термин бу төркемчәнең грамматик асылын һәм үзенчәлеген булганынча чагылдыра алмаганнан, без аларның беренчесен (үтемле сыйфат фигыльне) „фагыйль", икенчесен (үтемсез сыйфат фигыльне) „мәфгуль" дип алдык. (Фагыйль — эшләүче, эшләгән; мәфгуль — эшләнүче, эшләнгән). Гарәп сыйфат фигыльләрендә заман төшенчәсе юк.

Татар телендә масдарлар һәм сыйфат фигыльләр күбесе исемләшкән һәм саф исем итеп кулланылалар, мәсәлән:

Масдарлар — *тәртип, тәнкыйть, гыйлем* һ. б.;

Фагыйльләр — *шагыйрь, шаһит, мөгаллим* һ. б.;
Мәфгульләр — *мәктүп, мәрхум, мәхрүм* һ. б.

Ләкин аларның саф төрләре дә азмы-күпме очрый. Һәрхәлдә исемләшкән масдар һәм сыйфат фигыльләрнең асылларын белү сүзнең төп мәгънәсенә төшенер өчен бик зарур:

... Милләтең бу хәле *мәктүбме* китабы хикмәтә?

(Г. Тук., „И, каләм".)

(Милләтнең бу хәле хикмәт китабына *язылганмы*?)

Монда *мәктүб* саф мәфгуль „язылган" мәгънәсендә кулланылган.

...Бәнем шәэнемме — *тәфтиш* мәзһәбеңне, дине мәнсүбең?..

(Г. Тук., „Пушкинга".)

(Синең нинди караштa һәм диндә булуыңны *тикшерү* минем эшемме?)

Монда *тәфтиш* масдары үзенең саф мәгънәсендә кулланылган. Тәфтиш сүзе исемләшкән булса, ул татарча *итәргә* дигән ярдәмче фигыль белән кулланылыр иде, мәсәлән, *тәнкыйть итәргә, тәгъбир итәргә, исраф итәргә* дип сөйлибез.

Гарәп телендә фигыльләр 15 бапка (форма, төр) бүленәләр, ләкин татар телендә ун баптан гына ясалган сүзләр очрый. Һәр бапның, ягъни фигыль формасының, үзенә генә хас гомуми мәгънәсе бар. Бу гомуми мәгънә шушы баптагы барлык сүзләргә һәм беренче нәүбәттә масдарга күчә[1].

Һәрбер бапның (беренчедән башка) бер масдары, бер фагыйле һәм бер мәфгуле була. Мәсәлән: тамыр **шкл** (شكل) „чикләү, формага салу" идеясен белдерә. Бу тамырны 2 нче бапның үлчәүләренә салгач, конкрет мәгънәләр хасил була:

| | |
|---|---|
| фигыль — шәккәлә | شَكَّلَ — ул формалаштырды; |
| масдар — тәшкил | تشكيل — формалаштыру; |
| фагыйль — мөтәшәккил | متشكِّل — формалаштыручы; |
| мәфгуль — мөтәшәккәл | متشكَّل — формалаштырылган. |

Түбәндәге җәдвәл (таблица) төрле баптагы сүзләрнең формаларын тиешле тәртиптә күрсәтә. Бу таблица белән танышу гарәпчә сүзләрне өйрәнергә һичшиксез зур ярдәм итәр иде.

Беренче бапның кырыктан артык масдар формалары бар, ләкин без монда иң күп таралган өчесен генә күрсәтәбез.

Сүзләргә үлчәү (форма, үрнәк, калып) итеп кенә мәгънәсез (бу очракта) өч тартык алына **фгл** (فعل). Масдарларның ясалышын күрсәтер өчен, тамырның асыл тартыклары цифрлар белән алмаштырылды.

---

[1] Гарәп филологиясе буенча рус галимнәре масдар фигыльдән ясала, һәм соңыннан аның үзеннән бүтән сүзләр барлыкка киләләр, дип раслыйлар.

### Масдарлар ясалу таблицасы [1]

| Бап | Масдарның өч тартыклы тамырга (цифр) яңа хәрефләр өстәп ясалуы | Масдарның үлчәве | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| 1 | Ясалу формалары билгеле типта түгел | ф̧гәл — فَعَلْ<br>фәгил — فَعِلْ<br>фигл — فِعْلْ | гамәл<br>кәсеб<br>фикер һ. б. |
| 2 | тә -1-2-и-3 | тәфгил — تَفْعيل | тәқсим — бүлү |
| 3 | мө-1-а-2-ә-3-ә<br>1-и-2-а-3 | мөфагәлә — مفاعله<br>фигал — فِعالْ | мөхарәбә — сугышу<br>китаб — язу |
| 4 | и-1-2-а-3 | ифгал — افعال | ислах — төзәтү, яхшырту |
| 5 | тә-1-ә-2-2-е-3 | тәфәггел — تـفعّل | тәшәккер — рәхмәт белдерү; тәкәббер — масаю, зураю |
| 6 | тә-1-а-2-е-3 | тәфагел — تفاعل | тәҗаһел — белмәмешкә салышу |
| 7 | ин-1-и-2-а-3 | инфигал — انفعال | инкишаф — ачу, кәшеф итү |
| 8 | и-1-ти-2-а-3 | ифтигал — افتعال | имтихан — сынау, экзамен |
| 10 | исти-1-2-а-3 | истифгал — استفعال | истигмал — куллану |

Искәрмә: *тәрҗемә, зәлзәлә* һ. б. шуның шикелле дүрт тартыклы (хәрефле) масдарлар безнең телебездә сирәк очраганга, без аларның җәдвәлен күрсәтмибез.

---

[1] Гарәп сүзләрен таблицаларга салып анализлау С. Майзельгә иярәп эшләнде.

**Фагыйльнең (үтемле сыйфат фигыль, причастие действительного залога) ясалышы**

| Бап | Фагыйльнең өч тартыклы тамырдан (цифрдан) ясалышы | Фагыйльләрнең үлчәве | Мисаллар |
|---|---|---|---|
| 1 | 1-а-2-и-3 | фаҕил — فاعل | шаһид — күрүче (шһд) |
| 2 | мө-1-ә-2-2-и-3 | мөфәҕҕил — مفعّل | мөҕаллим — укытучы (ҕлм) |
| 3 | мө-1-а-2-и-3 | мөфаҕил — مفاعل | мөхатыйб — хөтбә сөйләүче (хтб) |
| 4 | мө-1-2-и-3 | мөфҕил — مفعل | мөхбир — хәбәрче (хбр) |
| 5 | мө-тә-1-ә-2-2-и-3 | мөтәфәҕҕил — متفعّل | мөтәккәлим — сөйләүче (клм) |
| 6 | мө-тә-1-а-2-и-3 | мөтәфаҕил — متفاعل | мөтәҗаһил — белмәмешкә салышучы (җһл) |
| 7 | мө-н-1-ә-2-и-3 | мөнфәҕил — منفعل | мөнкалиб — революционер (қлб) |
| 8 | мө-1-тә-2-и-3 | мөфтәҕил — مفتعل | мөнтәқид — тәнкыйтьче (нқд) |
| 10 | мө-стә-1-2-и-3 | мөстәфҕил — مستفعل | мөстәҕмил — файдаланучы (ҕмл) |

Мәфгульнең (үтемсез сыйфат фигыль, причастие страдательного залога) ясалышы 2—10 бапларда икенче асыл тартыктан соң

*и* урынына *ә* кую белән генә аерыла. Әмма 1 нче бапка килгәндә, ул махсус مفعول мәфг̄ул үлчәве буенча ясала, мәсәлән:

(мә-1-2-у-3) мәктуб مكتوب — язылган (ктб);

мәгълум معلوم — билгеле (глм).

Җәдвәлдә китерелгән сүзләрнең ясалышларын күрдек. Әмма шушы формадагы сүзләрнең эчтәлеген ачар өчен, һәр бапны һәм аңа мөнәсәбәте булган масдар һәм сыйфат фигыльләрне кыскача тикшереп карыйк.

## Баплар

### Беренче бап

1) Ике яки өч төрле сузык белән төрлечә сузыкландырылган (хәрәкәләнгән) өч тартыклы тамыр беренче бапның масдарын тәшкил итә, мәсәлән:

өч тартык — *ф, г, л*;

ике (өч) сузык — *(ә) а, и, у*.

*Фигл — фикер*[1], *фагил — сарыф, фәгәл — кәләм, фугл — кутыб, фәгәлә — гәләбә* һ. б. шуның шикелле өч тартыклы беренче бап масдарлары.

Беренче бап масдарлары сүзлекләрдә һәрвакыт күрсәтеләләр, чөнки аларның саны бик күп. Татар телендә беренче бап масдарлары бөтенесе диярлек исемләшкән һәм саф татар исемнәре белән беррәттән йөриләр.

2) Үтемле сыйфат фигыль беренче бапта „фагил“ (فاعل) үлчәвенә салынып түбәндәгечә ясала: тамырның беренче тартыгыннан соң (озын) сузык *а̄-ә̄* (ا — әлиф), икенче тартыктан соң (кыска) сузык *и* (кәсрә, аст) куела, мәсәлән:

тамыр — ГЛМ (علم) „белем“ идеясен чагылдыра,

га̄лим (عالم) — галим, белүче, белгеч;

тамыр — ГШК (عشق) „мәхәббәт“ идеясен чагылдыра,

га̄шик (عاشق) — сөюче, яратучы, гыйшык тотучы.

---

[1] Гарәп сүзендә икенче тартыктан соң сузык булмаса да, татар телендә ул күбесенчә *е (ы)* формасында әйтелә (языла), мәсәлән: *шәкл — шәкел; гилм — гилем; котб — котыб.*

Мондый сүзләр татар телендә зур урын алалар һәм күбесенчә исемләшеп саф исем булып йөриләр (*шағир* (орф. шагыйрь), *шаһит, малик, ғалим* һ. б. шуның шикелле сүзләр).

Үтемсез сыйфат фигыль беренче бапта мәфгуль (مفعول) үлчәвенә салынып түбәндәгечә ясала: тамырның беренче тартыгы алдына ***ма-мә*** алкушымчасы (префикс), икенче тартыктан соң озын сузык **ӯ** (татарчада күбрәк **ү**) куела, мәсәлән:

тамыр — **ЗЛМ** (ظلم) „изү", „карангылык" идеясен чагылдыра,
мазлӯм (مظلوم) — изелгән, җәберләнгән;
тамыр — **ТБҒ** (طبع) „басу" идеясен чагылдыра,
матбӯғ (مطبوع) — басылган, матбугат, пресса.

Татар телендә гарәп мәфгульләре:

а) *булырга, итәргә* шикелле ярдәмче фигыльләр белән бергә кушма фигыль тәшкил итәләр, мәсәлән, *мәҗбур итәргә, мәхрүм ителде, мәлгун булды* һ. б. шуның шикелле сүзләр.

Кич мине, мин башны бөкмим, мин үземчә зур хәзер;
Син дә бер *мәгърүрә* булсаң, мин дә бер *мәгърүр* хәзер.

(Г. Тук., „Алдандым".)

б) саф сыйфат фигыль ролен үтәп, җөмләдә аергыч функциясендә йөриләр, мәсәлән, *мәхрүм кеше* — берәр нәрсәдән коры калдырылған кеше, *мәрхүм кеше* — үлгән кеше.

*Мәрхүм* бабам утлы октябрьда
Ирек таңы өчен сугышкан...

(М. Хөсәен, „Минем имзам".)

в) исемләшкән мәфгульләр исем ролендә кулланылалар, мәсәлән: *мәҗнүн* („җенләнгән") — тиле, дивана, акылсыз.

Тәбрик итеп милләтемә язам *мәктүп* (хат)...

(М. Гаф., „Шатлык шигыре".)

## Икенче бап (تفعيل тәфғил)

1) Икенче бапның масдары тамырның беренче тартыгы алдына ***тә-та*** алкушымчасы (префикс), икенче тартыктан соң озын сузык **ӣ** (ـِيـ) кую белән ясала. Икенче бапның төп мәгънәсе — тамырда булган гомуми идеяне тормышка ашыру (конкрет төшенчәдә тәгъбир итү, русча — понудительность), мәсәлән:

тамыр — **ШКЛ** (شكل) „форма" идеясен чагылдыра,
тәшкил (تشكيل) — формалаштыру, формага салу, оештыру;

тамыр — ГЛМ (علم) „белем“ идеясен чагылдыра,

тәглим (تعليم) — укыту, белем бирү, татарча әйткәндә

„гыйлемләтү“, белемле итү.

Икенче бап масдарлары татар телендә:

а) „саф“ масдар (отглагольное имя, имя действия) ролен үтиләр, мәсәлән:

Фикремез *тәфрикы* өммәт җилләрен истермәсен,
Истереп, *тәүхиде* милләт юлларын кистермәсен.

(Г. Тук., „Фикер“ газетасына гына махсус түгел“.)

Монда *тәфрикъ* — аеру, таркату һәм *тәүхид* — берләштерү, бердәм итү — ике сүз икесе дә грамматик һәм семантик яктан саф масдар булып алынганнар. Татар теле морфологиясе буенча булганда „Милләтне *тәүхид итү* (берләштерү) юлларын“ ...дип язылыр иде. Ул чакта „*тәүхид*“ сүзендә фигыль сыйфаты калмаган була, чөнки „*итәргә*“ сүзе гамәлне белдерә.

б) Масдарларның зур өлеше саф исем төркеменә күчкән һәм исем функциясен үти, мәсәлән: *тәртип, тәнкыйть, тәкъдир* һ. б.

в) *Итәргә* ярдәмче фигыле белән бергә кушма фигыль тәшкил итә, мәсәлән, *тәнкыйть итәргә, тәкъдим итәргә, тәбрик итәргә* һ. б. шуның шикелле фигыльләр.

Кара йөзләр безне булмас эшкә *тәклиф иттеләр*:
— Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! — диләр...

(Г. Тук., „Китмибез“.)

г) Масдарларның бер өлеше, татар морфологиясе законнарына буйсынып, фигыль ясаучы кушымча алып гади татар фигыле шикелле төрләнә, мәсәлән: *тәшвиш-лә-нү, тәнкыйть-ләргә, тасвир-ларга* һ. б. фигыльләр.

1 зат — тасвир*ладым* — тасвир*лыйм*
2 зат — тасвир*ладың* — тасвир*лыйсың*
3 зат — тасвир*лады* — тасвир*лый* һ. б. төрләнешләр.

2) Икенче бапның фагыйле (причастие действительного залога) тамырның алдына ***мө-мо*** алкушымчасы (префикс), беренче асыл тартыктан соң ***а*** яки ***ә***, икенче тартыкны икеләштерү һәм аннан соң кыска сузык ***и*** кую юлы белән ясала.

Шул ук баптагы мәфгуль (причастие страдательного залога) фагыйльдән икенче белән өченче асыл тартык арасында ***и*** урынына ***а***, ***ә*** булу белән аерыла [1].

---

[1] Икенче баптан унынчыга кадәр мәфгульнең фагыйльдән аермасы шул ике тартык арасындагы кыска сузык ***и*** урынына кыска ***а***, ***ә*** куелудан гыйбарәт.

| Тамыр | 2 нче бап масдары | Фагыйль | Мәфгуль |
|---|---|---|---|
| **ҒЛМ** | тәғлӣм تعليم | мөғәллим مُعلِّم | [мөғәлләм][1] — укытылучы |
| **ДРС** | тәдрӣс تدريس | мөдәррис — дәрес бирүче مدرِّس | [мөдәррәс] — дәрес алучы |
| **ҚДС** | тәқдис تقديس | [мөқәддис] مقدِّس | мөқәддәс — изге |

Татар теленә кергән икенче бап сыйфат фигыльләре башлыча исемләшкәннәр һәм саф исем яки сыйфат булып йөриләр.

И сабыйлар, эшләгез сез, иң *мөкаддәс* нәрсә — эш...

(Г. Тук., „Эшкә өндәү“.)

**Өченче бап** (مفاعله — فعال **мөфа̄ғәлә — фиға̄л**)

1) Өченче бапның масдары ике төрле. Берсе тамырның алдына ***мө-мо*** алкушымчасы (префикс) кую юлы белән ясала. Масдарның болай башка баплардагы сыйфат фигыльләрчә ясалышы өченче бапта гына очрый.

Тамырның беренче тартыгыннан соң озын сузык ***а̄ (ә̄)***, икенче белән өченче тартыклар арасында кыска[2] сузык ***а (ә)*** куела. Бу масдарның мөәннәс (жен. род) кушымчасы да бар: ***а (ә), ат (әт)***.

Мәсәлән:

тамыр — **РЖГ** (رجع) „кайту“ идеясен чагылдыра,

масдар — мөра̄жәғәт (مراجعة) — берәүгә мохатәбәт итү, сүз кушу, кайту;

тамыр — **НСБ** (نسب) „бәйләнеш“ идеясен чагылдыра,

масдар — мөнә̄сәбәт (مناسبة) — берәр нәрсә белән бәйләнештә булу (иметь отношение к чему-либо).

---

[1] Квадрат җәя эченә алынган сүзләр татар телендә кулланылмыйлар.

[2] Татар авазларына карата әйткәндә „озын“ һәм „кыска“ сузык дигән атамаларның фонематик әһәмияте юк.

Өченче бапның икенче төр масдары беренче тартыктан соң кыска сузык аваз *и*, икенчесеннән соң озын сузык *ā* куелып ясала, мәсәлән:

тамыр — **ФРК** (فرق) „аерылу“ идеясен чагылдыра,

масдар — фирāк (فراق) — аерылышу;

тамыр — **КТБ** (كتب) „язу“ идеясен чагылдыра,

масдар — китāб (كتاب) — язу (конкретлашкан мәгънә „китап“).

Өченче бап башлыча уртаклашу идеясен гәүдәләндерә. Татар телендә аның масдарлары:

а) *Итәргә* (кылырга) ярдәмче фигыле белән бергә кушма фигыль тәшкил итә, мәсәлән:

„... анлар да мөселманнарга начар күз илә карамыйлар иде, чөнки алар төрек офицерлары илә *мөҗаләсә кылалар* икән“. (Ф. Әмир., „Юл истәлеге“.)

б) „Саф“ исем итеп кулланылганнарын еш кына очратып була, мәсәлән:

„Ләкин китап караса, *моталәгадә* булса, кимемәс тә...“

(Г. Ибр., „Яшь йөрәкләр“.)

2) Өченче бапның сыйфат фигыльләре беренче формадагы масдарларыннан мөәннәс (жен. род) кушымчасы булмау белән генә аерылалар.

| Тамыр | Өченче бапның масдарлары | Фагыйль | Мәфгуль |
|---|---|---|---|
| НСБ | мөнāсәбәт مناسبت | мөнāсиб مناسِب | [мөнāсәб] مناسَب |
| СФР | мөсāфәрәт مسافرت | мөсāфир—юлчы مسافِر | [мөсāфәр] مسافَر |

Татар телендә өченче бап сыйфат фигыльләре икенче баптагылардан азрак кулланыла, алар: а) тулысынча исемләшкән булып исем ролендә йөриләр, б) төп функцияләрен югалтмыйча җөмләдә аергыч ролен үтиләр, мәсәлән:

а) „... шуннан, *мохатәбенең* өстенә күз салып, аның... чапаннан ... икәнен күрде дә...“ (Г. Ибр., „Яшь йөрәкләр“.)

б) ...Әйләнәндә әйләнеп йөргән *монафикъ* муллалар әйләнеп тә карамаслар, тотса мәскәүләр якаң. (Г. Тук., „Тотса мәскәүләр якаң“.)

## Дүртенче бап (افعال ифг̅ал)

1) Дүртенче бапта масдарлар тамырның беренче тартыгы алдына *и* авазы, икенче белән өченче тартыкларның арасына озын сузык *ā (ǝ̄)* кую юлы белән ясала. Дүртенче баптагы масдар башлыча йөкләтү идеясен белдерә. Моның белән ул икенче бапка якын тора. Мәсәлән:

тамыр — **ЗҺР** (ظهر) „күренү“, „күз алдында булу“ идеясен чагылдыра,

масдар — изһāр (اِظهار) — күрсәтү;

тамыр — **ФҺМ** (فهم) „аңлау“, „төшенү“ идеясен белдерә,

масдар — ифһāм (اِفهام) — аңлату, төшендерү.

Дүртенче бап масдарлары татар телендә:

а) Саф исем яки сыйфат булып кулланылалар, мәсәлән: *илһам* — рух күтәренкелеге, кәеф; *ихлас* — чын-чынлык, саф күңеллелек; *ислах* — төзәтү, реформа һ. б.

... *Илһамлы* йөрәктә һәр чакта
Комсомол җылысын сакладым...

(М. Хөсәен.)

б) *Итәргә* (кылырга) ярдәмче фигыле белән бергә кушма фигыль тәшкил итә, мәсәлән: *Инкяр итәргә, иҗат итәргә, исраф итәргә* һ. б. шуның шикелле кушма фигыльләр.

...Ушбу эшне безгә *изһар кылгыл* имди...

(К. Гал., „Кыйссаи Йосыф“.)

2) Дүртенче бапның сыйфат фигыльләре дә шулай ук *мө-мо* алкушымчасы (префикс) ярдәмендә ясалалар.

Фагыйль тамырның икенче тартыгыннан соң кыска сузык *и* куеп, мәфгуль — шул ук урында *и* урынына *а (ә)* куеп ясала, мәсәлән:

тамыр — **ХБР** (خبر) „хәбәр“, „белдерү“ идеясен чагылдыра,

фагыйль — мөхбир (مخبِر) — хәбәр итүче, хәбәрче;

мәфгуль — мөхбәр (مخبَر) — хәбәр ителүче, аның турында мәгълүмат бирелгән.

| Тамыр | Дүртенче бап масдары | Фагыйль | Мәфгуль |
|---|---|---|---|
| **ХБР** | ихбāр (اخبار) | мөхбир (مخبِر) — хәбәрче | [мөхбәр] (مخبَر) — хәбәр ителгән |
| **МКН** | имкян (امكان) | мөмкин (ممكِن) | [мөмкән] ممكَن |

Татар телендә дүртенче бап сыйфат фигыльләре:

а) Әдәбиятыбызда гарәптәгечә саф фагыйльләр итеп кулланылалар, мәсәлән:

„...Ни дә булса, каяндыр *мөһлик* бер тавыш килде дә...“

(Г. Ибр., „Яшь йөрәкләр.“)

Монда *мөһлик* (**ҺЛК** дән), „куркытучы“, „кот алучы“ мәгънәсендә фагыйль буларак, җөмләдә аергыч функциясендә килә.

б) Тулысынча исемләшкән булып саф исем урынына йөри, мәсәлән:

...Җыелды газета *мөхбир*ләре (хәбәрчеләре)...

(Г. Ибр., „Габдрахман Салихов“.)

**Бишенче бап** (تفعّل **төфәггел**)

1) Бишенче бап масдарлары татар телендә еш очрый торган форма; иске әдәбиятыбызда гына түгел, хәзерге әдәби телдә дә мондый формадагы сүзләр кулланыла. Бу масдар тамырның алдына ***тә-та*** кушымчасы (префикс) куеп, икенче тартыгын икеләштереп, аның артыннан гарәпчә кыска сузык ***у*** („замма“), татар телендә ***е*** һәм бик сирәк ***ә*** авазы өстәп ясала, мәсәлән:

тамыр — **ФКР** (فكر) — „уй“, „фикер“ мәгънәсен чагылдыра,

маслар — тәфәккер (تفكّر) — уйлану, фикер йөртү;

тамыр — **БСМ** (بسم) „елмаю“ мәгънәсен чагылдыра,

масдар — тәбәссем (تبسّم) — елмаю.

Бишенче бапның гомуми мәгънәсе — икенче баптагы сүзнең (башлыча масдарның) кайтым юнәлешен белдерү, мәсәлән:

икенче бап — тәкбир (تكبير) — олылау, хөрмәт күрсәтү;

бишенче бап — тәкәббер (تكبّر) — үз-үзенә хөрмәт күрсәтү, ягъни олылану, масаю.

Татар телендә бишенче бап масдары:

а) Сирәк булса да, саф масдар булып кулланыла, мәсәлән:

... Юк *тәкәллеф*, юк эрелек, утырышасың син дә мин...

(М. Гаф., „Мин кайда“.)

б) Күбесе, исемләшкән булып, саф исем ролен үтиләр, мәсәлән: *тәрәккый* — алга китү, прогресс; *тәбәссем* — елмаю һ. б.

в) *Итәргә* (кылырга) ярдәмче фигыле белән бергә кушма фигыль тәшкил итә, мәсәлән:

...*иткән тәҗәссем* (гәүдәләндергән) халыкның көчен...

(М. Гаф., „Кызыл байрак“.)

г) Татар грамматикасы закончалыгы буенча:

фигыльгә әверелә, мәсәлән: *тәкәббер*ләнергә — олыланырга, масаерга;

сыйфат була (ягъни аергыч функциясен үти ала), мәсәлән: *тәкәббер* кеше — масаючы кеше, *тәвәккәл*сез — кыюсыз, икеләнүчән;

абстракт мәгънәле исем ясала, мәсәлән: *тәкәббер*лек — масаючылык һ. б. сүзләр.

... *Тәвәккәл*гә тугыз җирдән
Хак тәгалә бирәм дигән...

(Г. Афзал, „Тәвәккәл әби".)

2) Бишенче бапның сыйфат фигыльләре түбәндәгечә ясала: масдарның алдына ***мө-мо*** алкушымчасы, икенче белән өченче тартыклар арасына фагыйль өчен ***и***, мәфгуль өчен ***а***, ***ә (е)*** сузыклары куелалар, мәсәлән:

| Тамыр | Бишенче бапның масдары | Фагыйль | Мәфгуль |
|---|---|---|---|
| **ХСС** | тәхассыс تخصص | мөтәхассыйс متخصّص — специалист | [мөтәхассас] متخصَّص |
| **WКЛ** | тәwәккәл توكّل | мөтәwәккил متوكّل | мөтәwәккәл متوكَّل |
| **ҒЛҠ** | тәғәллеҡ تعلّق | мөтәғәллиҡ متعلِّق — бәйләүче | мөтәғәлләҡ متعلَّق — бәйләнгән, бәйләнүче |

Татар телендә бишенче бап сыйфат фигыльләре:

а) саф исем ролендә йөриләр, мәсәлән:

*мөтәхассис* (орф. мөтәхассыйс) — специалист, *мөтәгассиб* — (орф. мөтәгассыйп) — фанатик;

б) сыйфат фигыль мәгънәсендә кулланылалар, мәсәлән:

... Кесәсеннән кызыл яулыкның очын тышка салындырып йөри торган көяз вә *мөтәкәллиф* егетләр ... (Г. Ибр., „Яшь йөрәкләр".)

Монда аергыч функциясен үтәүче *мөтәкәллиф* сүзе фагыйльдән гыйбарәт („церемонный", „напускной", „кыланышлы" мәгънәсендә).

### Алтынчы бап (تفاعل тәфағел)

1) Алтынчы бапның масдары шулай ук ***тә*** белән башлана, беренче тартыктан соң озын сузык ***ā*** (ә̄) һәм икенче тартыктан соң кыска сузык ***у*** куела, мәсәлән:

**тамыр — HWЛ** (نول) „алу" идеясен белдерә,

масдар — тәнаwел (تناول) — ашап карау, тәмен тату;
тамыр — **КМЛ** (كمل) „тулылык“ идеясен белдерә,
масдар — тәкамел (تكامل) — тулылык.

Алтынчы бап масдарлары татар телендә сирәк кулланыла, чөнки бу формада булган уртаклык идеясе ешрак кулланыла торган өченче бапта да бар, мәсәлән:

тамыр — **КТБ** (كتب) „язу“ идеясен чагылдыра,
III бап масдары — мөкатәбә (مكاتبة) — язышу;
VI бап масдары — тәкатеб (تكاتب) — язышу.

*Тәшагырь* итмә, зинһар, кермә шагыйрь битлегенә син,
Кисәрләр койрыгыңны, кермә былбыл читлегенә син.

(Г. Тук., „Мөтәшагыйрьгә“.)

Бездә очрый торган алтынчы бап масдарлары күбесенчә исемләшкәннәр һәм татар теле грамматикасының нормаларына буйсыналар.

2) Алтынчы бапның сыйфат фигыль формалары бишенче бап формаларыннан тамырның икенче тартыгы икеләшмәү һәм беренче асыл тартыктан соң кыска *ә* урынына озын сузык *ā* кую белән аерыла, мәсәлән:

V бапта — мөтәбәддил — алмашынучы,
VI бапта — мөтәбāдил — бирәү белән алмашып торучы.

Татар телендә алтынчы бапның сыйфат фигыльләре:

а) күбесенчә саф исем ролендә йөриләр һәм б) сирәк кенә сыйфат фигыль булып кулланылалар, мәсәлән:

... тик табигатендә булган кылларны аңлап, шуңа *мөтәнасиб* юлы табылсын ... (Г. Ибр., „Яшь йөрәкләр“.)

## Җиденче бап (إنفعال инфигал)

1) Җиденче бапның масдарлары тамырның беренче тартыгы алдына ***ин*** алкушымчасы, беренче белән икенче тартык арасына кыска сузык ***и***, икенче белән өченче тартыклар арасына озын сузык ***ā (ә̄)*** куеп ясалалар, мәсәлән:

тамыр — **ҚЛБ** (قلب) „әйләндерү“, „аудару“ идеясен чагылдыра,
масдар — инқилāб (انقلاب) — алмашыну, переворот, революция;
тамыр — **ГКС** (عكس) „әйләндерү“, „чагылдыру“ идеясен белдерә,
масдар — ингикāс (انعكاس) — чагылыш.

Җиденче бапның төп мәгънәсе — беренче баптагы фигыльне төшем юнәлешендә кую, мәсәлән:

I бап — қәсәмә (قسم) — бүлде,

VII бап — инкәсәмә (انقسم) — бүленде. Бу мәгънә масдарга да күчә, мәсәлән: инкисām (انقسام) — бүленү, өлешләнү.

2) Җиденче бапның сыйфат фигыль формалары *мө-мо* алкушымчасы һәм тамырның икенче белән өченче тартыклары арасына *и* (фагыйль) яки *ә* (мәфгуль) сузыгы кую юлы белән ясалалар, мәсәлән:

тамыр — ҒКС (عكس), масдар — инғикāс (انعكاس),

фагыйль — мөнғәкис (منعكِس) — капма-каршы чагылдыручы,

мәфгуль — мөнғәкәс (منعكَس) — чагылдырылучы.

Татар телендә җиденче бап формалары бик сирәк очрый, аның масдарлары да, сыйфат фигыльләре дә күбесенчә исемләшкән булалар.

... Бер-беренә *мөнгакис*[1] (капма-каршы) булыр, бер-беренә каршы куелмыш ике көзгегә охшар... (К. Нас., „Фәвакиһелҗөләса".)

## Сигезенче бап (افتعال ифтиғал)

1) Сигезенче бапның масдарлары түбәндәгечә ясалалар: тамырның алдына *и* сузыгы куела, беренче белән икенче тартык арасына *ти* иҗеге (инфикс) кертеп, икенче белән өченче тартык арасына озын сузык *ā (ә)* куела, мәсәлән:

тамыр — **ҖҺД** (جهد) „көч кую" идеясен чагылдыра,

масдар — иҗтиһāд (اجتهاد) — тырышу, үзе көч кую;

тамыр — **ЛФТ** (لفت) — „бору" мәгънәсен белдерә,

масдар — илтифāт (التفات) — игътибар, әйләнеп карау (берәүгә таба башны борып дикъкать белән тыңлау, карау һ. б.).

Сигезенче бапның төп мәгънәсе — беренче баптагы масдарга кайтым юнәлеше („үзе өчен", „үзенә") бирүдән гыйбарәт, мәсәлән:

I бап — җәһед (جهد) — көч кую,

VIII бап — иҗтиһад (اجتهاد) — „үзе өчен көч кую", ягъни „тырышу";

I бап — назар (نظر) — карау,

VIII бап — интизар (انتظار) — „үзе өчен өмет итеп карап тору", ягъни „көтеп тору".

Татар телендә сигезенче бапның масдарлары:

а) Саф масдар булып кулланылалар.
Ник болай бу? — дип гаҗәпләнгән базар.
Әйләмәктә пассажирлар *интизар*.

(Г. Тук., „Печән базары".)

---

[1] Бу җөмләдә *мөнғакис* сүзе рәвеш ролен үти.

б) Күбесе исемләшкән булып саф исем ролен үтиләр, мәсәлән: *истыйлях* — термин, атама.

... Мәдрәсәне дәвам иттерерлек *икътидары* (көче, сәләте) юк иде... (Г. Ибр., „Йөз ел элек".)

в) *Итәргә* (кылырга) ярдәмче фигыле белән бергә кушма фигыль тәшкил итә, мәсәлән: *илтифат итәргә, икътибас итәргә* һ. б.

...тир белән тапсын ашарын, *итсен* әлбәт *иҗтиһад*...

(Г. Тук., „Эшкә өндәү".)

2) Сигезенче бапның сыйфат фигыльләре дә шулай ук ***мө-мо*** алкушымчасы ярдәмендә ясалалар, мәсәлән:

| Тамыр | Сигезенче бапның масдары | Фагыйль | Мәфгуль |
|---|---|---|---|
| НКД | интикад انتقاد — тәнкыйть | мөнтәкид منتقد — тәнкыйтьче | [мөнтәкәд] منتقد — тәнкыйтьләнүче |
| ГБР | игтибар اعتبار | [мөгтәбир] معتبر — игътибар итүче | мөгтәбәр معتبر — игътибарга лаеклы, хөрмәтле |

Татар телендә сигезенче бапның сыйфат фигыльләре шул ук баптагы масдарлар шикелле үк бик күп кулланыла.

а) Сыйфат фигыльләрнең күбесе исемләшкән һәм алар саф исем булып йөриләр, мәсәлән:

...Күп сөйләдем, яхшы инде *мөнтәкыйть*ләр сукмаса,
Берсе барлык язганымны читкә сибереп түкмәсә...[1]

(Г. Тук.)

Монда *мөнтәкыйть* сүзе „тәнкыйтьче" мәгънәсендә, саф исем булып кулланылган.

б) *Кылырга* ярдәмче фигыле белән иске әдәбиятта кушма фигыльнең исем өлеше булып йөри, мәсәлән:

...Шимди безгә тиешле
*мөхтәсәр кылыб* бетәргә...

(Халык иҗаты, „Урта Тигәнәле бәете".)

---

[1] Мисаллар „Татар поэзиясе антологиясе"ннән алынды, гарәп сүзләренең орфографиясе шундагыча.

## Унынчы бап[1] (استفعال истифғāл)

1) Унынчы бапның масдарлары түбәндәгечә ясалалар: тамырның алдына *исти* алкушымчасы, икенче белән өченче тартык арасына озын сузык *ā (ә)* куела, мәсәлән:

тамыр — **ХСН** (حسن) „яхшылык“ идеясен чагылдыра,

масдар — истихсāн (استحسان) — хуплау, раслау (яхшы дип күрү, мәгъкуль табу);

тамыр — **ҒМЛ** (عمل) „эш“ идеясен белдерә,

масдар — истиғмāл (استعمال) — эштән үзең өчен нәтиҗә чыгару, ягъни файдалану.

Унынчы бапның төп мәгънәсе — сүзнең тамырында булган гомуми мәгънәне зат файдасына бирү, мәсәлән:

истиғмāл — гамәлдән (эштән) файда күрү, ягъни файдалану;

истиғфāр (استغفار) — гафу үтенү.

Татар телендә унынчы бапның масдарлары:

а) „Саф“ исем булып кулланылалар, мәсәлән: *истикъбаль* — киләчәк, киләчәк заман; *истибдад* — золым (деспотизм, произвол).

> ... *Истикъбаль*ләреннән өмит кискән,
> Ник тудым, дип еглый, анадан...
>
> (Г. Тук.)

б) *Итәргә* (кылырга) ярдәмче фигыле белән бергә кушма фигыль тәшкил итәләр, мәсәлән:

„Менә бу вакыйга әүвәлге думалар вакытында булса, ул думалар моннан назыйрларның мәсьүл булулары кирәклеген *истихраҗ итәрләр* иде“. (Ф. Әмир., „Дума ачылды“.)

2) Унынчы бапның сыйфат фигыльләре шулай ук ***мө-мо*** алкушымчасын масдарның алдына куеп, тамырның икенче белән өченче тартыклары арасына ***и*** (фагыйль) яки ***ә*** (мәфгуль) сузыгы кертү юлы белән ясалалар, мәсәлән:

| Тамыр | Унынчы бапның масдары | Фагыйль | Мәфгуль |
|---|---|---|---|
| **ҒМЛ** | истиғмāл استعمال | мөстәғмил مستعمِل — файдаланучы, кулланучы | мөстәгмәл مستعمَل — кулланылган |
| **ҚЛЛ** | истиқлāл — استقلال бәйсезлек | мөстәқилл مستقِل — бәйсез | [мөстәқәлл] مستقَل |

[1] Тугызынчы баптагы сүзләр татар телендә юк дәрәҗәдә аз, шуна күрә аларның морфологик шәкелләрен күрсәтү файдасыз булыр дип, тугызынчы бапны төшереп калдырдык.

Татар телендә унынчы бапның сыйфат фигыльләре:

а) Сыйфат фигыль булып кулланылалар (бик сирәк), мәсәлән: ...Халән „Мәҗмәгыль-әдәб“ китабы кулларда *мөстәгъмәл*дер. („Каюм Насыйри“, 1948, 12 бит.)

б) Күбесе исемләшкән булып саф татар исемнәре ролендә йөриләр, мәсәлән:

...Әйдәгез тиз *мөстәбид*ләрне изик!.. (Н. Исәнбәт, „Коммуна тимерлегендә“.)

Масдарлар һәм сыйфат фигыльләрнең ясалышын (819—820 битләрдәге таблицаны кара), аларның нигездә нинди мәгънәдә йөргәннәрен өйрәнү — татарлашкан гарәп сүзләренең этимологиясен тикшерергә, аларны татар телендә семантик һәм стилистик яктан дөрес кулланырга киң мөмкинчелек бирер иде.

Мәсәлән, текстта *истиҗваб* сүзен беренче тапкыр очраткан кеше ***исти*** алкушымчасыннан сүзнең унынчы бап масдары икәнлеген таный. Сүзнең тамырында ***җвб*** тартыклары бар икән, ул татар телендәге *җаваб* сүзен күрсәтә. Унынчы бапның гомуми идеясе — тамырда булган мәгънәне зат файдасына таләп итү, шулай булгач *истиҗваб* сүзенең мәгънәсенә дә тиз төшенә алабыз: „зат өчен җавап таләп итү“, димәк „сорашу“, „җавап алу“ (допрос).

## „Авыру“ хәрефле фигыльләр

Гарәп тел галимнәре алфавиттагы (ء) ***һәмзә,*** (ى) ***и*** һәм бездә ***в, у*** хәрефләре белән бирелә торган (و — w) хәрефләрне „авыру“ хәрефләр дип атыйлар. Һәрбер гарәп сүзе асылда өч тартык аваздан (хәрефтән) торганлыгы югарыда әйтелде. Менә шушы өч асыл хәрефләрнең берсе „авыру“ хәрефләрдән булса, фигыль дә „авыру хәрефле фигыль“ дип йөртелә. Язуда андый фигыльләрдән ясалган сүзләрнең төрле үзенчәлекләре була, чөнки „авыру“ хәрефләрнең бүтән хәрефләргә алмашынулары яки бөтенләй төшеп калулары бар. „Авыру“ хәрефле масдарларның һәм сыйфат фигыльләрнең кайсы бапта булганлыкларын аерырга читен булганга, бу мәсьәләгә без монда бераз туктап китәргә тиеш.

1) Тамырның беренче тартыгы — һәмзә яки (و) w. Мондый тамырдан ясалган сигезенче бап масдарында тамырдагы ***w*** (و) өстәмә иҗектәге (инфикстагы) ***т*** га охшаштырыла (башкача әйткәндә ***т*** тарафыннан ассимиляцияләнә), мәсәлән:

тамыр — **WФҚ** (وفق) „килешү“ идеясен чагылдыра,

масдар — и-w-тифа̄қ ⟶ иттифа̄қ (اتفاق) — союз, берләшмә.

Бу кагыйдә масдардан ясалган сыйфат фигыльләргә дә күчә, мәсәлән:

масдар — иттифа̄қ (اِتِّفَاق) — союз, килешү, бердәмлек,

фагыйль — мөттәфиқ (مُتَّفِق) — туры килә торган, охшашлы, разый, килешүчән.

Тамырның беренче тартыгы „авыру“ хәрефле сүздән ясалган һәм сигезенче һәм унынчы баптагы масдарларда „авыру“ хәреф ***w*** (و)

булса, ул элек *и* гә күчә, ى (*и*) булса, шул хәленчә үзеннән элек килгән кәсрәгә кушылып, озын *и* (ـِ) барлыкка килә. Мәсәлән:

тамыр — **WЖД** (وجد) „барлык" идеясен чагылдыра,

IV бап масдары — иwҗа̄д → иҗа̄д (ایجاد) — иҗат, барлыкка китерү;

тамыр — **WЛИ** (ولى) „ия булу" мәгънәсен аңлата,

X бап масдары — истиwла̄ә → истила̄ә (استلاء) — басып алу.

2) Тамырның икенче тартыгы (و) *w* яки (ى) *и*. Мондый тамырдан ясалган кайбер сүзләрдә икенче асыл тартык (*w* яки *и*) бөтенләй төшеп кала, мәсәлән:

тамыр — **ДWМ** (دوم) „дәвам итү" идеясен белдерә,

I бап фагыйль — да̄-w-им (داوِم) → да̄им (دائم) — шуннан нисби сыйфат *даими* ясала.

тамыр — **НИЛ** (نيل) „алу" мәгънәсен чагылдыра,

I бап фагыйль — на̄иил (نايِل) → на̄ил (نائل) — алучы.

Дүртенче һәм унынчы бапта мондый тамырлардан ясалган масдарларга *а* яки *ә* кушымчасы өстәлә, мәсәлән:

тамыр — **ДWР** (دور) „әйләндерү" идеясен чагылдыра,

IV бап масдары — идwа̄р (ادوار) → идар + ә → ида̄рә (ادارة) — башкару, администрация (правление).

тамыр — **ФИД** (فيد) „файда" идеясен белдерә,

X бап масдары — истифиа̄д → истифа̄д + ә → истифа̄дә (استفاذة) — файдалану, файда табу.

Бу масдарлардан ясалган сыйфат фигыльләрдә дә „авыру" тартык төшеп кала, мәсәлән **ДWР** тамырыннан:

IV бап масдар — ида̄рә (ادارة),

фагыйль — мөдӣр (مدير) — идарә итүче;

**ФИД** тамырыннан:

X бап масдар — истифа̄дә (استفاده),

фагыйль — мөстәфӣд (مستفيد) — файдаланучы.

„...бер төрлесе үзенең тимер кулы, куәтле *ирадәсе* белән әхвальне үзе теләгән якка бора — болар хәятның чыннан иясе, *идарә* кылучысы булалар..." (Г. Ибр., „Уты сүнгән җәһәннәм".)

Бу җөмләдә *ирадә* сүзе („ихтыяр") **РWД** тамырыннан ясалып, *идарә* сүзе белән бер үк формада языла.

3) Тамырның икенче һәм өченче тартыклары бер үк төрле булсалар, алар күп вакытта икеләштерелеп укылалар. Мондый тамырдан ясалган сыйфат фигыльләрнең икенче белән өченче асыл тартыклары арасында булган *и* (фаг̣ил) яки *ә* (мәфгуль) хәрефләре бөтенләй төшеп кала, яки алгарак күчә, мәсәлән:

тамыр — **ҲСС** (خصص) „үзенчәлек“ идеясен чагылдыра,

I бапның фагыйле — х̄асис → х̄асс (خاصّ) → хас (особенный);

тамыр — **РДД** (ردد) „кире кагу“ идеясен белдерә,

VIII бапның фагыйле — мөртәдид → мөртәдд (مرتدّ) → мөртәт — баш тартучы, хыянәтче, ренегат;

тамыр — **ҚЛЛ** (قلل) „азлык“ идеясен чагылдыра,

X бапның масдары — истиқл̄ал (استقلال) — бәйсез булу;

Фагыйль — мөстәқлил → мөстәқилл (مستقل) → мөстәкыйль — бәйсез, ирекле.

Бу соңгы мисалда *и* ике *л* арасыннан *к* белән *л* арасына (алга) күчә.

4) Тамырның өченче тартыгы ی (*и*) яки و (*w*). Мондый тамырдан ясалган икенче бапның масдарына сүз азагындагы хәреф урынына *ә (а)* кушымчасы ялгана, мәсәлән:

тамыр — **РБW** (ربو) „үсү“, „арту“, „үрчү“ идеясен чагылдыра,

II бапның масдары — тәрбиw (تربيو) → тәрби + йа (تربيه) — тәрбия (воспитание).

5) Шундый ук тамырдан ясалган бишенче бап масдары *и* хәрефе (авазы) белән тәмамлана, мәсәлән:

тамыр — **РҚИ** (رقى) „күтәрелү“, „алга бару“ идеясен аңлата,

V бапның масдары — тәрәққи (ترقّى) — прогресс, алга бару.

Шул ук хәл алтынчы бапта да күренә, мәсәлән:

тамыр — **СWИ** (سوى) „тигезләнү“ идеясен бирә,

VI бапның масдары — тәсāwи (تساوى) → тәсави — тигезлек.

Бу ике бапның фагыйльләренең дә азакларында *и* хәрефе (авазы) була, мәсәлән:

V бап масдар — тәрәққи (ترقّى);

фагыйль — мөтәрәққи (مترقى) — алдынгы, алга баручы;

VI бап масдар — тәсаwи (تساوى);

фагыйль — мөтәсаwи (متساوى) — тигез, тигез хокуклы.

## Башка төрле сүз төркемнәре

### Урын исемнәре

Гарәп телендә „урын-вакыт“ белдерүче исемнәр махсус „урын-вакыт“ үлчәүләренә салынып ясалалар. „Вакыт“ күрсәтүче исемнәр гарәп теленең үзендә дә бик сирәк очрыйлар, татар телендә алар бөтенләй юк. Әмма берәр эшнең урынын күрсәтүче гарәп исемнәре бездә кулланылалар.

Гарәп телендә урын исемнәре өч төрле үлчәүле була: мәфгәл (مفعَل), мәфгәлә (مفعلة) һәм мәфгил (مفعِل).

Алар гарәп теле грамматикасы нигезендә түбәндәгечә ясалалар: тамырның беренче тартыгы алдына *мә-ма* алкушымчасы (префикс), икенче белән өченче асыл тартык арасына (кыска) сузык аваз *и*, *ә* яки *а* куела. Кайбер очракларда сүзнең ахырына *ә* өстәлә.

Мәсәлән:

тамыр — **ҖЛС** (جلس) „утыру" идеясен белдерә,

урын исеме — мә + җлис → мәҗлис (مجلس) — утырыш, мәҗлес, совет, парламент;

тамыр — **КТБ** (كتب) „язу" идеясен чагылдыра,

урын исеме — мәктәб مكتب — яза торган урын, мәктәп;

тамыр — **ГРБ** (غرب) „бату", „кояш баю" идеясен белдерә,

урын исеме — магриб (مغرب) — кояш бата торган як, көнбатыш;

тамыр — **ДРС** (درس) дәрес сүзенең тамыры „сугу" идеясен аңлата,

урын исеме — мәдрәсә (مدرسة) — дәрес бирелә торган урын, мәктәп;

тамыр — **ТБГ** (طبع) „басу" идеясен чагылдыра,

урын исеме — матбага (مطبعة) — баса торган урын, типография.

... ага-энене *мәхкәмә*гә тарттырырга ... бик ихлас булмаса да... (Г. Ибр., „Йөз ел элек".)

## Корал исемнәре

Гарәп теленнән кергән „корал" исемнәре татар телендә бик сирәк очрый, аларның күбесе кеше исемнәрендә була, мәсәлән: *Мифтах, Мисбах* кебек.

Корал исеме гарәп телендә — مِفْعَل (мифгәл) яки مِفْعَال (мифгал) үлчәве белән ясала, ягъни тамыр алдына *ми* алкушымчасы, икенче асыл тартыктан соң я кыска сузык *а (ә)*, я озын сузык *а* куела. Мәсәлән:

тамыр — **СБХ** (صبح) „яктылык" мәгънәсен белдерә,

корал исеме — мисбах (مصباح) — яктырткыч, лампа;

тамыр — **ФТХ** (فتح) „ачу" идеясен чагылдыра,

корал исеме — мифтах (مفتاح) — ачкыч, ача торган корал;

тамыр — **НБР** (نبر) „күтәрелү" идеясен чагылдыра,

корал исеме — минбәр (مِنْبَر) — күтәрелү коралы, трибуна.

## Һөнәр иясенең исемнәре

Татар телендә кайбер сүзләрнең азагына ***че-чы*** кушымчасы ялганып, һөнәр иясенең исеме аңлатыла, мәсәлән: *сабанчы, язучы, укучы* һ. б.

Гарәп телендә мондый исемнәр я فاعل (фа̄ғил), я فَعَّال (фәғға̄л) үлчәүләре белән ясалалар.

Беренче үлчәү белән ясалганда, тамырның беренче белән икенче тартыклары арасына озын сузык ***а̄***, икенче тартыктан соң кыска ***и*** куела, мәсәлән:

тамыр (исем) — **ЛХМ** (لحم ләхем) — ит,

һөнәр исеме — ла̄хим (لاحِم) — итче.

Бу үлчәү беренче бапның сыйфат фигыленә („фагыйль" — причастие действительного залога) туры килә. Татар телендә һөнәр иясенең исеме мәгънәсендә сирәк очрый. Бездә икенче үлчәү белән ясалган сүзләр ешрак кулланыла. Икенчесе болай ясала: тамырның беренче тартыгыннан соң кыска ***ә*** сузыгы куела, икенче тартык икеләштерелә һәм аннан соң озын сузык ***а̄*** куела.

Мәсәлән:

тамыр — **РСМ** (رسم) „рәсем" идеясен белдерә,

һөнәрче исеме — рәсса̄м (رَسَّام) — рәсем ясаучы, художник;

тамыр — **БҚЛ** (بقل „яшелчә" сүзенең тамыры,

һөнәрче исеме — бәққа̄л (بقّال) — яшелчә сатучы;

тамыр — **ЖЛД** (جلد) „тире" сүзенең тамыры,

һөнәрче исеме — җәлла̄д (جلّاد) — тире тунаучы; палач.

Мең вә мильюн афәрин бу сурәтнең *нәққашына*[1]... (Г. Тук., „Бер рәсем".)

## Сыйфатлар

Исем, масдар, сыйфат фигыльләрдән башка татар теленә гарәптән бик күп сыйфатлар да кереп калган.

Татар телендә булган шикелле үк, гарәп телендә дә сыйфатлар асыл һәм нисби сыйфатларга бүленәләр.

### 1. Асыл сыйфат

Асыл сыйфатлардан татар теленә кергәннәрнең иң зур күпчелеге (فَعِيل) „фәғӣл" үлчәве белән ясалганнар, мәсәлән:

тамыр — **ФҚР** (فقر),

сыйфат — фәқӣр (орф. фәкыйрь) — (فقير) — ярлы;

[1] *Нәққаш* — бизәүче, ягъни **НКШ** тамырыннан ясалган һөнәрче исеме.

тамыр — **НФС** (نفس),

сыйфат — нәфис (نفيس) — ямьле, матур, нәзакәтле;

тамыр — **ЛББ** (لبب),

сыйфат — ләбиб (لبيب) — акыллы һ. б.

Асыл сыйфатлар татар теле грамматикасы законнарына тулысынча буйсындырылганнар һәм саф татар сыйфатлары шикелле үк аергыч функциясендә кулланылалар, мәсәлән: *фәкыйрь*[1] *кеше, нәфис гөлләр* һ. б.

Бер заман, иңмәс борын иблис *ләгыйнь*,
Торды инсан ал да гөл дә, син дә мин...

(Ш. Баб., „Газазил".)

Асыл сыйфатлар татар телендә ялгызлык исем — кеше исеме функциясендә еш очрый, мәсәлән:

*Җәлил* — лаеклы (достойный),

*Кәрим* — вөжданлы, намуслы,

*Шәриф* — вөжданлы, мәрхәмәтле,

*Нәҗип* — яхшы тумышлы, затлы һ. б. шуның шикелле исемнәр һәм аларның *Кәримә, Шәрифә, Салихә, Әминә* кебек мөәннәс (жен. род.) вариантлары.

## 2. Нисби сыйфат

а) Нисби сыйфатлар исемнәрнең азагына (ى) ***и*** кушымчасы ялгау ярдәмендә ясалалар.

Алар рус телендәге ***ий*** бетемле сыйфатларга туры киләләр, мәсәлән: *советский — суфийати, казанский — казани* һ. б.

Татар теленә нисби сыйфатлар әзер килеш кереп калганнар, чөнки бездә ***и*** кушымчасы сүз ясагыч кушымчага саналмый. Ләкин элек заманда гарәп телен яхшы белүче татар интеллигенциясе, ***и*** кушымчасыннан файдаланып, аерым сүзләрдән (башлыча ялгызлык исемнәрдән) нисби сыйфатлар тудырганнар. Мәсәлән, Баруд (дары) → Баруди, Казан → Казани, Болгар → Болгари һ. б.

Нисби сыйфатлар үзләре бәйләнгән предметларның урынын, вакытын яки берәр билгесен, үзлеген аңлаталар, мәсәлән: قزان (Казан) + (ى) قزانى (казани) — Казанныкы, Казанга караган (казанский);

مصر (Мисыр) + (ى) مصرى (мисри) — Мисырныкы, Мисырга караган (египетский);

تتار (татар) + (ى) تتارى (татари) — татарныкы, татарга караган (татарский);

---

[1] *Фәкыйрь, Ләбиб, Кәрим* шикелле сүзләр беренче бапның үтемле сыйфат фигыль (فاعل) үлчәве белән ясалган *Камил, Залим, Фатих* кебек сүзләргә охшыйлар, ләкин аларны бутарга ярамый.

خصوص (хосус) + (ی)خصوصی (хосусый) — үзенчәлекле (особенный, характерный) һ. б.

„Анын матурлык вә үзенә бер төрле нәфасәт белән тулы шигырьләре рус милләте тарафыннан гына түгел, бәлки рус телен белә торган милләтләр тарафыннан *хосусый* бер мәхәббәт белән укыладыр". (Ф. Әмир., „Олуг милләтнең олуг шагыйре".)

б) Нисби сыйфат формасына кергән исемнәр башка исемнәрне сыйфатлыйлар (аергыч булып киләләр), мәсәлән: انسان‌قزانی (инсан қазани) — Казан кешесе, کلام‌عربی (кәлам̄ г̦әрәби) — гарәп сүзе һ. б.

„Татардагы *фикри* вә *мәдәни* инкыйлап сабан туенда да тәэсирсез калмады". (Ф. Әмир., „Сабан туенда".)

в) Нисби сыйфат мөәннәс (жен. род.) исеменең аергычы булып килгән вакытта ахырындагы *u* (ی) фәтхәле һәм тәшдидле (икеләшкән) булып түгәрәк *m* (ة) белән языла, ягъни *иййа* кушымчасы ялгана, мәсәлән: کلمهٔ‌عربیه (кәлимә — гарабийййа) — гарәп сүзе; مدرسهٔ‌عالیه (мәдрәсә-галийййа) — гали (югары) мәдрәсә һ. б.

г) „Фәгыйләт" (فعیلت) үлчәвендәге исемнәрдән нисби сыйфат ясалганда ахырларындагы (ت) *әт-ат* төшеп кала, мәсәлән: حقیقت (хәқиқәт) → حقیقی (хәқиқи); طبیعت (табиг̦ат) → طبیعی (т̆абиг̦и), һ. б. сүзләр.

д) Ахырында *a* авазын белдерүче (ا һәм ی) булган сүзләрдән нисби сыйфат ясалганда әлифләре (و) *waw* га алмашына (хәзерге язуда сүз азагындагы *a* га *ви* (*wu*) өстәлә, мәсәлән: دنیا (дөнйа) → دنیوی (дөнйаwи); صحراء (сахра) → صحروی (сахраwи); موسی (муса) → موسوی (мусаwи) һ. б.

е) Ахырында *m* (ت яки ة) булган кыска сүзләрдән нисби сыйфат ясалганда *m* төшеп кала һәм бер و (waw) өстәлә (хәзерге язуда *в*) мәсәлән: سنة (сәнә) → سنوی (сәнәwи)— елга караган, еллык; کرة (көрә) → کروی (көрәwи) — йомры (круглый, шарообразный); لغت (лөг̦әт) → لغوی (лөг̦әwи) — телнеке (языковый).

ж) Кайбер сүзләрдән нисби сыйфат ясалганда *u* хәрефеннән алда *ан* (ان) кушымчасы арттырыла, мәсәлән: روح (рух) — җан, рух; روحانی (рухани) — рухныкы, җанныкы; дин эшлеклесе (духовный; религиозный деятель); جسم (җисем) — гәүдә, тән; جسمانی (җисмани) — гәүдәнеке (телесный) һ. б. шуның шикелле сүзләр.

Искәрмә: *рухани* сүзе тулысынча исемләшкән, сыйфат функциясендә шул ук тамырдан *рухи* сүзе кулланыла.

з) Нисби сыйфатның нигезендә булган исемнең хәзерге татар телендә булмавы да ихтимал, мәсәлән: حربی хәрби → „хәрб“ — сугыш (татар телендә юк), مدنی мәдәни → „мәдинә“ — шәһәр (татар телендә юк).

### 3. Сыйфатның артыклык дәрәҗәсе

Татар әдәби телендә гарәп сыйфатларының артыклык дәрәҗәләре дә очрый. Күп вакытта артыклык дәрәҗәсе кергән сыйфатның гади дәрәҗәсе безнең телебездә бөтенләй булмый.

Сыйфатның артыклык дәрәҗәсе أَفْعَل (әфгәл [1]) үлчәвенә салына, мәсәлән: کبیر (кәбир) — зур, اکبر (әкбәр) — иң зур, иң бөек; سعید (сәгид) — бәхетле, اسعد (әсгад) (орф. Әсгать) — иң бәхетле; حلوی (хәлwа) — татлы, احلی (әхла) — татлырак; شریف (шәриф) — намуслы, اشرف (әшрәф) — иң намуслы, намуслырак.

Я ходая! Нигә төрле-төрле кылдың бәндәни?
Ни сәбәп соң җөмлә *әднә* бәндәләрдән бән дәни?
(Г. Тук., „Сөальләр“.)

Монда Тукай *„бәндәни“* сүзе белән ифрат төгәл рифмалашкан *„бән дәни“* (түбән) сыйфатның гади дәрәҗәсе белән бергә аның артыклык дәрәҗәсен *„әднә“*не дә кулланган.

## *Ан-ән* кушымчасы белән ясалган гарәп рәвешләре

Бүтән сүз төркемнәре шикелле үк, татар теленә гарәп теленнән рәвеш тә кергән. Телебездә гарәп рәвешләре башлыча рәвеш урынында, өлешчә кереш сүз итеп кулланыла.

Гарәби исемнәргә, сыйфатларга, сыйфат фигыльләргә, саннарга һәм масдарларга ***ан-ән*** кушымчасы (гарәп грамматикасында төшем килеше кушымчасы) ялгау ярдәмендәге төрле рәвешләр ясала [2].

---

[1] Шул ук үлчәүдә төс һәм гариплек белдерүче сыйфатлар да ясала, мәсәлән: *әхмәр* — кызыл, *әгрәҗ* — аксак.

[2] Шундый ук ***ан*** бетемле (масдарлар) исемнәр дә була, аларны форма ягыннан рәвешләрдән аерып булмый, ләкин җөмлә эчендә андый исемнәр рәвеш хәл ролен үтәмиләр. Мәсәлән:

Бер мөкатдәс хис белән һәрбер кеше *хәйран* бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен: бәйрәм бүген!
(Г. Тук., „Бәйрәм бүген“.)

Мәсәлән:

а) исем — شرق шәрек — көнчыгыш,

рәвеш — شرقا шәркән — көнчыгыштан;

исем — مثل мәсәл — үрнәк,

рәвеш — مثلا мәсәлән — үрнәк итеп, үрнәк йөзеннән;

б) сыйфат — عموم гумум — барысына да хас (общий),

рәвеш — عموما гумумән — барысына да хас рәвештә (вообще);

в) сыйфат фигыль (мәфгуль) — مظلوم мазлум — җәберләнгән, изелгән,

рәвеш — مظلوما мазлумән — җәберләнеп;

сыйфат фигыль (фагыйль) — ظاهر заһир — күренүче, тыш,

рәвеш — ظاهرا заһирән — күренештә, тыштан (внешне);

г) сан — اول әүүәл — беренче, әүвәл,

рәвеш — اولا әүүәлән — беренчедән, беренче итеп (во-первых);

д) масдар — اجمال иҗмаль — җыю (собирание),

рәвеш — اجمالا иҗмалән — җыеп, туплап (в итоге, в сумме, в совокупности);

масдар — تأديب тәэдиб — әдәп бирү, әдәпкә өйрәтү,

рәвеш — تأديبا тәэдибән — әдәп бирү өчен, әдәпкә өйрәтү өчен (с целью воспитания).

## Рәвешләрнең морфология ягыннан классификациясе

Семантик һәм синтаксик яктан караганда, ягъни рәвешләрнең җөмлә эчендә хәл ролендә нинди мәгънәдә кулланылуын тикшергәндә, аларның күбесе түбәндәге төркемчәләргә керә:

а) Рәвеш хәле функциясен үтәүче рәвешләр мәгънәләре буенча күбесенчә татар телендәге ***ып-еп*** кушымчалы хәл фигыльгә (рәвеш фигыльләре) туры киләләр. Җөмләдә фигыль алдында килеп эшнең билгесен белдерүче сүзләр булып киләләр. Татар телендә сирәк кулланылалар. Мәсәлән: Мөгаллим мәсьәләне *иҗмалән* аңлатты (мөгаллим мәсьәләне җыеп аңлатты). Мин бу хәбәрне сезгә *мәмнүнән* (сөенеп, шатланып) сөйлим.

б) Урын рәвешләре, мәсәлән: Русия *шәркан* (көнчыгышта, шәрыкта) Кытай белән чиктәш.

в) Вакыт рәвешләре, мәсәлән: Ул сәгадәт *даимән* булыр мәзид... (Ул бәхет даими рәвештә артып торыр...) (Мөхм., „Нуры сыдур".)

г) Сәбәп рәвешләре, мәсәлән: Ул бу эшне гайбәттән *хәуфән* (гайбәттән куркып) эшләмәде.

д) Төрле рәвешләр төркемчәсенә без максат, охшату-чагыштыру, күләм-чама, нәтиҗә һ. б. рәвешләрне кертәбез. Мәсәлән:

> *Җөмләтән* мәсгут саныйрдым мөслимин әүлядени:
> Кәндеми, әүлядеми, әүлядемең әүлядени...
>
> (Г. Тук., „Тәрбиятель этфаль"гә.)

Балаларны *тәгъзибән* түгел, *тәэдибән* орышалар (ягъни җәза бирү өчен түгел, әдәпкә өйрәтер өчен).

> Бу эш *гадәтән* мәкъбүл түгел (гадәт, йола буенча).
> Мин хәзер шундый кеше, *җисмән* дә кол, *фикрән* дә кол.
>
> (Г. Сөнгати, „Коллыкта".)

Гарәп рәвешләре бездә шулай ук кереш сүз функциясендә бик күп кулланылалар, мәсәлән: Алар, *гомумән*, бу мәсьәлә белән күптән танышканнар.

## Алмашлыклар

انا (әнә̄) — мин, نحن (нәхне) — без, انت (әнтә) — син, انتم (әнтөм) — сез, هو (һүwә) — ул, هى (һия) — ул *(мнс)*, هم (һөм) — алар шикелле зат алмашлыклары татар әдәбиятында бик сирәк очрый. Татар теленә кергән гарәп алмашлыкларыннан күбрәк зат кушымчалары (*һи, көм, кем, һа*) кулланыла. Алар барысы да я бәйлекләргә (күбесенчә), я исемнәргә ябышып кергәннәр, мәсәлән:

عليكم — ғаләй-кем (көм) — сез-гә (2 нче зат, күплек) (әс-сәлә̄му *галәйкем*);

عليه — ғәләй-һи (3 нче зат, берлек) (мәкъсүм *галәйһи* — булүче);

فيها — фи-һа — анда (3 нче зат, берлек, жен. род.) (ма *фиһа* — аңарда булган нәрсә);

Гарәп сүз тезмәләрендә еш кына ما (ма) — „нәрсә" алмашлыгы очрый. Пәрдәи фиркатьлә өртелмеш безем *ма* бәйнәмез (арабыз)... (Г. Тук., „Мәхү идәрмисән?")

Билгеләү алмашлыкларыннан هذا (һәзә) — бу, هذه (һәзиһи) — бу (мөәннәс) һәм ذلك (заликә) — „теге" кулланыла.

„Фәлән", „берәү", „мәгълүм бер җан иясе" мәгънәсендә *мән* алмашлыгы очрый, мәсәлән:

> ...Озакламый кәрван илә иблис килә!
> Күп заманнан бирле көткән *мән* килә...
>
> (Ш. Баб., „Газазил".)

## Билгелелек артикле („тәгъриф“ яки „әлифләм“)

Билгелелек һәм билгесезлек артикле мәсьәләсе белән безнең татар укучылары немец, инглиз яки француз теле өйрәнү аркасында таныш. Татар телендә дә билгесезлек төшенчәсе бар. Мәсәлән:

„...борынга тоелырлык мәртәбәдә булган *бер тәм* аңкый иде. Бу үзенә башка *бер рәхәтлек* бирә иде...“ (Г. Ибр., „Яз башы“, 51 бит.)

Бу мисалларда *бер* дигән сүз санау максаты белән түгел, бәлки *тәм* һәм *рәхәтлек* сүзләренең формаль *билгесез хәлдә* булганлыкларын күрсәтер өчен кулланылган. Ягъни *бер* билгесезлек артикле функциясен үти.

Гарәп телендә билгесезлек артикле махсус кисәкчә белән күрсәтелми. Әмма сүзнең билгеле хәлдә булганлыгын күрсәтер өчен, сүзнең башына *әл-* (ال әлифләм) кисәкчәсе куела, мәсәлән:

مكتب мәктәб — нindидер бер мәктәп,

المكتب әл-мәктәб — мәгълүм булган мәктәп;

العرب әл-г̣әрәб — гарәпләр (мәгълүм халык).

Билгелелек артикле сөйләүченең дә, тыңлаучының да һәр икесенә мәгълүм булган сүз алдына һәм шулай ук барысына да билгеле төшенчәләрне белдерүче сүзләр алдына куела. Мәсәлән: без кичә *бер мәктәптә* булдык, *ул мәктәп* яңа икән дип әйткәндә, без *ул* мәктәп дибез. Бу урында гарәпчә билгелелек артикле куелыр иде, чөнки сөйләүче һәм тыңлаучы икесе дә нинди мәктәп турысында сүз барганын беләләр: без кичә барган мәктәп.

Әлифләмнең (артикльнең) „ләм“е кайбер хәрефләр алдында укылмый. Ул сүз башында беренче булып килгән хәрефкә охшатып укыла, ягъни ассимиляцияләнә. Андый хәрефләргә „кояшлы хәрефләр“ (хөруф шәмсия) дип әйтәләр.

س (с), ز (з), ر (р), ذ (з̱), د (д), ث (с̱), ت (т), ن (н), ل (л), ظ (з̣), ط (т̣), ضى (з̣—д̣), ص (с̣), ش (ш) хәрефләре һәрвакыт артикльнең „ләм“ен ассимиляцияли, мәсәлән: الشمس әш-шәмс — кояш (әл-шәмс түгел); عبدالناصر Габде-н-насыйр (Габде-л-насыйр түгел) (икенче мисалда артикльнең *ә* се татар теле законлалыгына буйсындырылып *е* итеп укыла).

Телим булырга мин инсане гали,
Тели күңлем тәгали *биттәвали*.

(Г. Тук., „Үз-үземә“.)

Монда „*биттәвали*“ сүзе мондый кисәкләрдән тора: *би* — белән мәгънәсендәге бәйлек; „*әл*“ — әлифләм (артикль) „кояшлы хәреф“ „*т*“ тарафыннан ассимиляцияләнгән һәм „*би-әл-тәвали*“ урынына „*би-әт-тәвали*“ дип укылырга тиешле сүз татарлашканнан соң „*биттәвали*“ итеп укыла. „*Тәвали*“ — „туктаусыз“ мәгънәсендә алынган.

Артикль татар теленә сүзләргә ияреп кенә кергән һәм шул кергән килеш үзгәртелмичә кулланыла да. Ул я сүзнең алдына, я ике сүз арасында булып уртада килә. Әлифләмле сүзләр бездә сирәк очрый. Алар фәкать кеше исемнәре һәм аерым гыйбарәләрдә генә булалар, мәсәлән:

عبدالرحمان — Габд-ер-рахман (мәрхәмәтленең колы),

عبدالقادر — Габд-ел-кадыйр (сәләтленең колы),

دار الفنون — дар-ел-фөнүн (фәннәр йорты, университет),

السلام عليكم — әс-сәлāму галәйкем (тынычлык булсын сезгә),

سيف الملوك — Сәйф-ел-мөлүк (патшалар кылычы).

... Кашың җәя, керфегең ук, *өммел-хайә* (оят анасы)...
(Мөхм., „Төхфәи мәрдән".)

... Гашыйк ярым *әл-фиракъ*, мәгъшук ярым *әл-фиракъ*... (аерылдык, сау бул мәгънәсендә). (Курмаши, „Таһир-Зөһрә".)

## Бәйлекләр (предлоги)

Гарәп телендә рус телендәге кебек бәйлекләр бар. Алар татар телендәге килеш кушымчалары белән кайбер теркәгечләрнең рольләрен үтиләр. Гарәп бәйлекләре татар телендә мөстәкыйль рәвештә кулланылмыйлар, алар тик аерым сүзләргә генә ябышып кергәннәр.

Әдәбиятыбызда һәм сөйләм телендә ешрак очрый торган гарәп бәйлекләреннән түбәндәгеләр:

1). Би (بِ) — „белән" (с). Мәсәлән:

بعينه — (*би*гайниһи) — нәкъ, нәкъ үзе, үзе шикелле үк;

به (*би*һ) — аның белән (с ним);

بالواسطه — (*бил*wасита) — бер урталык аркылы (посредством);

بالضرورة — (*би*з-зарурә) — ирексездән, чарасыз, үтә кирәк булганга.

2) Ли (ل) — күбесенчә „өчен", „файдасына" мәгънәсендә йөри (для). Мәсәлән:

له (*лә*һ) — аның өчен, аның файдасына (для него, ему);

لله (*ли*лләһи) — алла өчен (ради аллаха);

ولهذا (wа-*ли*һазә) — шуның өчен (и поэтому).

3) Кә (ک) — „кебек", „шикелле", „охшашлы" (как, вроде). Мәсәлән:

کما فی السابق (*кә*ма фи-с-сабикъ) — әүвәлдәге кебек (как);

کماهو (*кә*ма һуә) — шуның шикелле, аның кебек һ. б.

4) Фи (فی) — дә (в). Мәсәлән:

فی الحال (*фил*-халь) — хәзер үк;

فيه — (фиh) — анда (в нём);

مافى الضمير (ма-*фи*-з-замир) — күңел эчендә булган нәрсә h. б.

5) Илә‌ — иля (الى) — „гә“, „гә кадәр“ (к, до). Мәсәлән:

اليه (*иләйhи* — ана (к нему);

الى الابد (*илә*-л-әбәд) — мәңгегә h. б.

6) Ғәлә (على) — „гә“, „өстенә“, „буенча“, „рәвешенчә“ (на, над, против). Мәсәлән:

السلام عليكم (әс-сәләму *ғаләйкем*) — тынычлык булсын сезгә, „исәнмесез“ мәгънәсендә;

على القول (*ғалә*-л-каwел) — бер сүз буенча;

على هذا (*ғалә* hәзә) — шуна күрә.

7) Мин (من) — „дән“ (из). Мәсәлән:

من بعد (*мин* бәғде) — соңыннан;

منه (*мин*hе) — аннан;

من كل وجه (*мин* көлле wажhе) hәр яктан h. б.

Нәрсәдә ләззәт икән? Чөнки ялан дөньяда кәм —
*Мин* ләзиз шәйләр, вә *ли* кайсында ләззәт, кайда тәм?

(Г. Тук., „Ләззәт вә тәм нәрсәдә?“)

(*Мин* ләзиз шәйләр — тәмле әйберләр*дән*.)

8) Ғән (عن) - „дән“ (о, от). Мәсәлән:

عنه (*ғән*hе) — аннан;

عن قريب (*ғән* қәриб) — тиз заманнан;

عن اصل (*ғән* аслин) — түбәннән, тамырыннан, асылыннан.

9) Мәғ (مع) — „белән бергә“ (с). Мәсәлән:

مع هذا (*мәғ* hәзә) — шуның белән бергә;

مع ما فيه (*мәғ* ма фиh) — шулай булса да;

مع التأسف (*мәғ*-т-тәәссеф) — кызганычка каршы, кайгы белән әйтәм ки... h. б.

10) Биля (بلا) — „-дән башка“, „-сез“. Мәсәлән:

بلاتفكر (*биля* тәфәккер) — уйламыйча, фикерләмичә;

بلادليل (*биля* дәлил) — дәлилсез.

11) Фәүқә (فوق) — „өстендә“, „тыш“ (над). Мәсәлән:

فوق العادة (*фәүқә*-л-ғадә) — гадәттән тыш (чрезвычайный).

12) Бәйнә (بين) — „арада“ (между). Мәсәлән:

بين الملل (*бәйнә*-л-милəл) — милләтләр арасында, милләтара, интернационал, халыкара.

13) Wараэ (وراء) — „артта“, „артында“, „аръягында“ (за). Мәсәлән:

ماوراءالنهر (ма-*wара*-эн-нәһер) — елга аръягында.

Һөҗүм кирәк ишаннарга — сорыкорт, гөмбә башларга;
Бетер, сындыр, кырып ташла *мәғ*-аль-урра вә *би*-л-банзай.

(Г. Тук., „Сорыкортларга“.)

Бу шигырендә Тукай „*ура*“ һәм „*банзай*“ сүзләрен билгелелек артикле белән ала һәм икесенең дә алдына „белән“ мәгънәле „*мәғ*“ һәм „*би*“ бәйлекләре куя. Бу бәйлекләрне аерым алып гарәп сүзе булмаган исемгә кушу татар шагыйре тарафыннан күрсәтелгән бердәнбер мисал. Югыйсә әдәбиятыбызда очраганнарның барысы да гарәп сүзләре белән бергә кереп калган бәйлекләр.

## Сүз тезмәләре

Татар әдәби теленә күп кенә гарәп сүз тезмәләре кергән, ул иске һәм яңа әдәбиятта, халык иҗатында очрый, җанлы сөйләм телендә киң кулланыла. Аларның бер төрләре катып калган сүз тезмәләре, мәкальләр, әйтемнәр төсендә булса, икенчеләре сыйфатлау һәм изафә тәркибе төсендә очрыйлар.

### 1. Катып калган сүз тезмәләре

Болар төрле алмашлыклар, бәйлекләр һәм исемнәр катнашында тулысынча гарәп синтаксисы нигезендә төзелгәннәр. Мәсәлән: بين الخوف والرجاء — *бәйнә-л-хәүф вә-р-риҗаэ* (курку белән өмет арасында) шикелле әйтемнәр.

على كل حال — *ғәлә көлле халь* (һәрхәлдә дә);

السلام عليكم — *әс-сәлāму-ғәләйкем* (тынычлык булсын сезгә);

بتمامها — *битәмамиһа* (бөтенләе белән);

مابه الافتخار — *ма-биһи-л-ифтихар* (аның белән мактану, горурлану);

لايعدولايحصى — *ля йоғәдде вә ля йохса* (исәпсез-хисапсыз) шикелле катып калган гыйбарәләр.

„... руслар үзләренең Олег, Владимир кебек тарихта мәгълүмрәк кешеләре, хәтта бик соң килгән Бөек Петрлары хакында әллә никадәр экиятләр сөйлиләр: аларны *фәукыльгадә* бер адәм ясыйлар“. (Г. Ибр., „Әдәбият мәсьәләләре“, 40 бит.)

Монда боларга анализ ясау максат түгел, фәкать лексикага якын торган һәм иске әдәбиятыбызда еш кулланылган сыйфатлау һәм изафә тәркипләре (тезмәләре) турында гына сүз алып барыла.

## 2. Сыйфатлау тәркибе, ягъни сыйфат һәм сыйфатланмыштан тора торган сүз тезмәсе

а) Сыйфатланмыш алда, сыйфат артта (ягъни икенче урында) булып, ике сүз икесе дә артикль (әлифләм) белән булса, *гарәпчә* төзелеш дип санала. Мәсәлән:

الدواءُ الشافي — әд-даwае-ш-шафи (шифалы дәва),

المكتب الجديد — әл-мәктәбе-л-җәдид (яңа мәктәп),

الحق المعلوم — әл-хаққе-л-мәгълүм (билгеле хак) һ. б.

Ләкин андый гарәби тезмәләр кайсы бер вакытта артикльсез (әлифләмсез) дә була. Ул чакта сыйфатланмышның ахырында я *е* авазы (хәрефе) була, я бер нәрсә дә булмый. Мәсәлән:

مكتب جديد — мәктәб*е* җәдид (яңа мәктәп),

مكتب جديد — мәктәб җәдид ( „ ).

„... Менә сиңа *хөррияте шәхсия* (шәхес иреге) ...“ (Г. Ибр., „Яшь йөрәкләр“.)

Бу ике төрле тәркип икесе дә: русча „согласованное определение“ дип атала.

б) Сыйфатланмыш алда, сыйфат артта, ике сүзнең арасында *и* авазыннан (хәрефеннән) гыйбарәт „фарси изафә“ булса, *фарсыча* төзелеш дип санала (гәрчә сүзләр гарәпчә булса да). Мәсәлән:

دواءِ شافی — дәва-*и*-шафи (шифалы дару),

مكتب جديد — мәктәб-*и*-җәдид (яңа мәктәп),

حق معلوم — хаққ-*и*-мәгълүм (билгеле хак) һ. б.

## 3. Изафә тәркибе

Изафә тәркибе дип без иялек килешендә килгән аергыч белән аерылмыштан тора торган сүз тезмәләренә әйтәбез. Татар телендә алар *-нең,-ның* кушымчасы ярдәмендә төзеләләр. Мәсәлән, бүлмә*нең* ишеге, Вәли*нең* китабы. Беренче сүз иялек килешендә куела.

Гарәп телендә изафә тәркибе сүзләрнең нинди тәртиптә килүләре ягыннан рус теле тәркибенә охшый, мәсәлән:

شارع المدينه — шаригъу-л-мәдинә—улица города (шәһәрнең урамы) һ. б. Гарәпчә икенче сүз шулай ук иялек килешендә килә. Изафә тәркибе дә, сыйфатлау тәркибе кебек, гарәпчә һәм фарсыча төзелә.

а) *Гарәпчә* төзелеш дип беренче сүз (аерылмыш) артикльсез (әлифләмсез), икенчесе (аергыч) артикльле булган сүз тезмәсенә әйтелә, мәсәлән: بيت الفقير — бәйте-л-фәкыйр — ярлы*ның* йорты (дом бедняка).

Ләкин татар әдәбиятында гарәпчә төзелешләр (изафә һәм сыйфатлау тәркибе) күбесенчә ялгызлык исемнәрендә генә очрый, мәсәлән: دار المعلمين — даре-л-мөгаллимин — мөгаллимнәр әзерләү йорты, педучилище; العصر الجديد — әл-гасрел-җәдид - яңа гасыр һ. б.

„Казанда гимназия һәм *дарелә́йтам* тәэсис итәргә карар бирдек, Астраханьда *дарелмөгаллимин вә-л-мөгаллимат* ачарга булдык...“ (Ф. Әмир., 2 т., 425 бит.)

Гарәп изафәсе кеше исемнәрендә еш очрый, мәсәлән:

مفتاح الدين — Мифтахе-д-дин (диннең ачкычы),

شمس الدين — Шәмсе-д-дин (диннең кояшы),

عبدالرزاق — Гәбде-р-раззақ (ризык бирүченең колы) һ. б.

б) Татар телендәге гарәп сүзләре күбрәк фарсы изафәсе *и* ярдәмендә бәйләнәләр. (Фарсы изафәсе белән фарсы сыйфатлау тәркибе арасында берниндн дә аерма юк, алар бертөрле итеп әйтеләләр һәм язылалар). Мәсәлән:

بيت فقير — бәйт-*и*-фәқир — ярлы өй һәм ярлының өе.

شربة شيطان — ширбәт-*и*-шайтан — шайтан ширбәте;

ترجمهٔ حال — тәржемә-*и*-халь — биография һ. б.

Хөббе дөнья илә калбем мәел итмеш би гөман,
Дөнья сәүмәк *ширбәти-шайтан* икәндер белмәдем.

(Һ. Сал., „Тәндә җаным“.)

в) Исемнәр изафәсе дип аергыч ролендә килгән сүз ялгызлык исеменнән гыйбарәт булган изафәгә әйтелә, мәсәлән:

مملكت روسيا — мәмләкәт*и*-Русия — Русия дип аталган дәүләт,

بلدهٔ قزان — бәлдә*и*-Казан — Казан шәһәре,

ملت تتار — милләт*и*-татар — татар халкы һ. б. шуның шикелле сүз тезмәләре.

г) Сыйфатлы изафә дип беренче сүз сыйфаттан, икенче сүз артикльле яки артикльсез исемнән гыйбарәт булган кушма сыйфатка әйтелә, мәсәлән:

سوء الحظ — суэ-ел-хаз — начар бәхет (бәхетсезлек);

حسن الخلق — хөсне-л-холық — яхшы холыклы;

فصيح اللسان — фасыйх-ел-лисан — татлы телле һ. б. шуның шикелле сүз тезмәләре.

„...Һәр заманда була килгән кебек, бездә дә "милли" дигән сыйфатны хәзер *суэ истигъмаль* итә башладылар“. (Г. Ибр., „Әдәбият мәсьәләләре“.)

Югарыда күрсәтелгәннәрдән тыш, татар әдәби телендә башка төрле сүз тезмәләре дә очрый. Мәсәлән, бер сүз гарәпчә, икенчесе татарча булган татар сүз тезмәсе: *лаякыл исерек, сафсата сату* шикелле; *кәеф-сафа, исәп-хисап* шикелле парлы сүзләр һ. б.

## ФАРСЫ ГРАММАТИК ЭЛЕМЕНТЛАРЫ

### Фарсы сүзләре

1) Татар әдәби теленә гарәп сүзләре күләмендә булмаса да фарсы сүзләре дә катнашкан дип алда әйтелгән иде. Аларның да грамматик үзенчәлекләре турында берникадәр әйтеп үтмичә бул-

мас, чөнки фарсы элементлары һәм грамматик, һәм семантик яктан татар теленнән аерылып торалар. Аларда мөзәккәр һәм мөәннәс категориясе юк, сүзнең азагында *ә* (ه) хәрефе булса да, ул гарәптәге шикелле мөәннәс исемгә саналмый. Шул сәбәптән аларның сыйфатлары (аергычлары) мөзәккәр формасында булырга тиеш. Мәсәлән:

خانه (ханә) — өй, خانهٔ جدید *(ханаи-җәдид)* — яңа өй;

نامه (намә) — язу, نامهٔ عجیب *(намәи-ғәҗиб)* — гаҗәп язу;

بنده (бәндә) — кол; кеше, بندهٔ فقیر *(бәндәи-фәкир)* — ярлы кеше һ. б.

خانه (ханә) сүзе татар телендә актив кушымчага әверелгән, аның ярдәмендә яңа сүзләр ясалалар, мәсәлән: *ашханә, чәйханә, китапханә* (элекке *көтепханә* урынына ясалган өр-яңа сүз) һ. б. шуның шикелле сүзләр.

2) Гарәп-татар алфавиты белән язылган әдәбиятыбызда фарсы сүзләрендә (خ) *х* хәрефеннән соң килгән (ا) әлиф күбесенчә (وا) рәвешендә языла (ләкин барыбер *„а“* итеп кенә укыла), мәсәлән خواه (хаһ) — өстә, خوار (хар) — хур, خواجه (хаҗә) — ия һ. б. (خان (хан) — патша, خانه (ханә) — йорт кебек сүзләр бүтән кагыйдә буенча язылалар).

3) که *ки* (кем) һәм тәрҗемә ителми торган модаль кисәкчә چه *чи* (нәрсә) сүзләре, *ә* (ه) белән язылсалар да, *и* итеп укылалар, мәсәлән: یا که — яки, بلکه — бәлки, چونکه — чөнки, گویا که — гүяки һ. б. шуның шикелле сүзләр.

Мин сөям, *хәтта ки* гаклымнан шашам,
Сөйгәнемнән шүрәле төсле ка‹ч›ам.

(Г. Тук., „Кызык гашыйк“.)

4) Җан иясен белдергән фарсы сүзләренең күплекләре (*ан*) ان кушымчасы ярдәмендә ясала, мәсәлән: مرد мәрд — ир, مردان мәрдан — ирләр; شیر шир - арслан, شیران ширан — арсланнар; مسلم мөслим — мөселман, مسلمان мөслиман — мөселманнар; معتبر мөғтәбәр — игътибарлы, معتبران мөғтәбәран — игътибарлылар.

„... Кунакка шактый итеп чакырылган *мөғтәбәран* тарафыннан зур бер мәхәббәт белән каралды“ (Ф. Әмир., „Сәхнәбезнең ун яше мөнәсәбәте белән“.)

5) Җансыз затны белдерүче сүзләрнең күплеге *һа* кушымчасы ярдәмендә ясала, мәсәлән:

آب аб — су; آبها абһа — сулар; دریا дәрья — диңгез, دریاها дәрьяһа — диңгезләр, зур елгалар; خانه ханә — йорт, خانه‌ها ханәһа — йортлар һ. б.

## Фарсы теле кушымчалары

1) Татар телендә түбәндәге фарсы алкушымчалары (префикслары) гарәп яки фарсы сүзләренең башында очрый [1].

а) از әз — „-дән", ازقديم *әз*кадим — искедән.

б) در дәр — „үк", درحال *дәр*хәл — хәзер үк, шунда ук, бик тиз.

Күрсә, ул кулларны *дәрхәл* уйгатыр,
Аннары кул күздән утлар уйнатыр!

(Ш. Баб., „Кандала".)

в) بِ бә — „-гә", بحق دوست *бә*хаққи дуст — дуслар хакына.

г) با ба — „белән", باترتيب *ба*тәртиб — тәртип белән.

д) بى би — „-сез", بى حساب *би*хисаб — хисапсыз, بى گناه *би*гөнаһ — гаепсез.

Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби;
*Бинићая, бихисабтыр*, гаскәри Чыңгыз кеби.

(Г. Тук., „Шүрәле".)

е) نا на — „түгел", ناحق *на*хак — хак түгел, نامعلوم *на*мәгълүм — мәгълүм түгел, ناكس *на*кәс — кеше түгел.

Ушбу тәнбиһләр соңында чар-*на*-чар,
Сафи абзый хатынның гайбен ачар.

(Г. Тук., „Кечкенә генә бер көйле хикәя".)

Монда *чар-на-чар* — ирексездән, теләсә-теләмәсә дә дигән мәгънәдә.

ж) نه нә — „да-да", „дә-дә", نه يازا، نه اوقى нә яза, нә укый — язмый да, укымый да мәгънәсендә.

з) تا та — „хәтле, чаклы" (дә), تاابد *та*әбәд — мәңгегә.

Калыр бакый бу журнал *та кыямәт*,
Идәрмез без химаять һәм сыянәт.
(Бу журнал мәңге яшәр,
Без аны сакларбыз да якларбыз.)

(Г. Тук., „Әлгасрел җәдид"ә матдәтән".)

и) سر сәр — „баш" سرلوحه *сәр*ләүхә — шигырь (мәкалә) исеме (заголовок).

2) Татар телендә түбәндәге кушымчалар ялгау юлы белән ясалган күп төрле фарсы сүзләре очрый:

а) بان бан — „-чы", باغبان баг*бан* — бакчачы.

---

[1] Гарәп язуында кайберәүләре аерым язылса да, безнең хәзерге орфографиябездә кушылып языла.

б) دان дан — „лек-лык“, قلمدان қәләм*дан* — каләм савыты.

в) زار зар — „лек-лык“, گلزار гөл*зар* — гөллек, чәчәклек.

г) ران ран — „-чы“, خامه‌ران хамә*ран* — язучы.

д) ساز саз — „-чы“, خاطرساز хәтер*саз* — хәтер табучы.

е) ستان стан — „лек-лык“, گلستان гөл*истан* — гөллек.

ж) کار кяр — „-чы“, حیله‌کار хәйлә*кяр* — алдаучы.

з) گر гәр — „-чы“ سوده‌گر, сәүдә*гәр* — сатучы.

и) کین кин — „-ле“, غمکین гамь*кин* — кайгылы.

Аһ, бу көннәр *гамькин* күңелләрне кисә,
Үткән гомер бер-бер искә төшә имди.

(Г. Тук., „Яз галәмәтләре“.)

к) گاه гяһ — вакыт һәм урын белдерә торган кушымча.

л) ور wәр — „-лы“, جانور җан*вар* — җанлы;

м) یار йар — „-ле“, بختیار бәхти*йар* — бәхетле.

3) Татар телендә кулланыла торган боерык фигыль кушып ясалган фарси сыйфат фигыльләр:

а) افروز әфруз — яктырт,

دلافروز диләфруз — күңел яктыртучы.

б) پرست пәрәст — табын, ярат,

وطنپرست ватан*пәрәст* — илен яратучы, патриот;

پوتپرست потпәрәст — потка табынучы.

„...Табигатьне катыштырып йөртерлек *хыялпәрәстлек* кирәк булачактыр“. (Ф. Әмир., „Россиядә Советлар власте һәм төрек милләтчелеге“.)

в) پرور пәрвәр — асра, ярат,

ملتپرور милләт*пәрвәр* — үз милләтен сөюче.

„Әсәрләренең һәрбересендә гаять самими *ватанпәрвәрлек*, ягъни *Польшапәрвәрлек* изһар итә иде“. (Ф. Әмир., „Поляк мөхәррире Сенкевич“.)

г) پوش пуш — капла,

کله‌پوش кәллә*пуш* — баш каплаучы, кәләпүш.

д) دار дар — ия бул, тот,

خبردار хәбәр*дар* — хәбәр тотучы, белүче.

Кача күр, кош кеби, мактауларыннан,
*Хәбәрдар* бул ки шунда ау барыннан.

(Г. Тук,. „Киңәш.“)

е) شناس шинас — бел, таны,

موسيقیشناس мусика*шинас* — музыка белгече, көйләр танучы.

Кадре гөл былбыл *шинас* һәм кадре җәүһәр җәүһәри.
Итмә тәрҗих бән кеби мәфтүнеңә бер җаһили.

(Г. Тук., „Мәхү идәрмисән?")

(Гөлнең кадрен былбыл белер, җәүһәрнең кадрен — җәүһәр, Үзеңне минем кебек сөйгән кешедән бер наданны артык күрмә.)

(Г. Тук., 1 томдагы тәрҗемә алынды.)

ж) كش кәш — тарт,

زحمتكش зәхмәткәш — хезмәт иясе;

دخانكش доханкәш — тәмәке тартучы;

з) گير гир — тот, ал,

جهانگير жиһан*гир* — дөньяны тотучы (властелин).

## Абстракт исемнәрнең фарсыча ясалышы

Гарәп телендә сүзнең абстракт мәгънәсен чыгару өчен, аның азагына тәшдидле (икеләшкән) ی (*и*) белән бер ت (*т*) (хәзерге язуда ***ийәт*** кушымчасы) арттырыла, ә фарсы сүзләренең ахырына бер ***и*** генә өстәлә, мәсәлән:

гарәпчә

مسعود (мәсґуд) — бәхетле, مسعوديت (мәсґудийәт) — бәхетлелек,

تاجر (тажир) — сатучы, تاجريت (тажирийәт) — сатучылык;

фарсыча

بختيار (бәхтийар) — бәхетле, بختيارى (бәхтийари) — бәхетлелек,

سوده گر (сәүдәгәр) — сатучы, سوده گرى (сәүдәгәри) — сатучылык һ. б.

## *Ана-анә* кушымчасы белән ясалган сүзләр

Фарсы телендә сүзләрнең охшату формалары бар. Алар ***ана-анә*** кушымчасы белән ясалалар, мәсәлән:

پدر (пәдәр) — ата, پدرانه (пәдәранә) — ата кебек, ата шикелле, аталарча;

عاقل (ґакил) — акыллы, عاقلانه (ґакиланә) — акыллыларча.

Яктылыкка иң элек атлау вә эз салу белән,
Гайбебезгә туп-туры *дустанә* күз салу белән...

(Г. Тук., „Мәрхүм Мөхәммәтзаһир әфәндегә".)

Искәрмә: сүзнең азагында ا (әлиф) яки و (w) булса, *анә* урынына یانه (*йанә*), сүз азагында ه (ә) булса, گانه (*гянә*) кушымчасы ялгана, мәсәлән:

دانا (дана) — галим, دانایانه (данайанә) — галимнәрчә;

ساده (садә) — гади (простой), سادهگانه (садәгянә) — гадиләрчә (по простому).

Татар телендә мондый сүзләр күбесенчә рәвеш төркемчәсендә булып, рәвеш хәле функциясендә кулланылалар, мәсәлән:

ممنون (мәмнүн) — шат, ممنونانه (мәмнүнанә) — шат хәлдә.

Исемдә: курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар,
*Гафифанә* вә *мәгъсуманә* көлгән, уйнаган чаклар...
(Г. Тук., „Исемдә".)

* * *

Кыскача гына язылган бу мәкаләдә татар әдәби теленә кергән гарәп һәм фарсы алынмаларына тулы гыйльми анализ бирелмәде, әлбәттә. Алай гына да түгел, гарәп-фарсы лексикасы семантик яктан бөтенләй каралмады; хәер, андый максат куелмаган да иде.

Әгәр дә сүзлектәге сүзләр, сүз тезмәләре, гыйбарәләр һәм аерым лексик берәмлекләрнең иң зур күпчелегенә мәкаләдә грамматик аңлатмалар табылса һәм алар укучыны канәгатьләндерсә, автор үзенең вазифасын үтәгән дип санар иде.

## КУШЫМТАНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ


Кереш сүз . . . . . . . . . 795
Татар әдәби телендә алынмаларның кулланылуы . . . 798
Гарәп грамматик элементлары . . . . . 801
  Гарәп теле турында гомуми мәгълүмат . . . . . 801
  Гарәп язуы . . . . . . . . . 802
  Татар теленә кергән гарәп сүзләренең фонетик үзенчәлекләре . . . . . . 805
    Сузык авазлар . . . . . . . 805
    Тартык авазлар . . . . . . . 809
  Басым мәсьәләсе . . . . . . . 811
  Гарәп телендә сүз ясалу принциплары . . . . . 812
  Исем . . . . . . . . . 813
  Масдар (исем фигыль) һәм сыйфат фигыль . . . . 817
  Баплар . . . . . . . . . 821
    Беренче бап . . . . . . . 821
    Икенче бап . . . . . . . 822
    Өченче бап . . . . . . . 824
    Дүртенче бап . . . . . . . 826
    Бишенче бап . . . . . . . 827
    Алтынчы бап . . . . . . . 828
    Җиденче бап . . . . . . . 829
    Сигезенче бап . . . . . . . 830
    Унынчы бап . . . . . . . 832
  „Авыру“ хәрефле фигыльләр . . . . . . 833
  Башка төрле сүз төркемнәре . . . . . . 835
    Урын исемнәре . . . . . . . 835
    Корал исемнәре . . . . . . . 836
    Һөнәр иясенең исемнәре . . . . . . 837
  Сыйфатлар . . . . . . . . . 837
  *Ан-ән* кушымчасы белән ясалган гарәп рәвешләре . . . 840
  Алмашлыклар . . . . . . . . 842
  Билгелелек артикле („тәгъриф“ яки „әлифләм“) . . . . 843
  Бәйлекләр (предлоги) . . . . . . 844
  Сүз тезмәләре . . . . . . . 846
Фарсы грамматик элементлары . . . . . . 848

Сдано в производство 7.09.93 г. Подписано в печать 14.10.93 г. Объем 15 п. л. Тир. 10000. Зак. Я-564. Отпечатано в типографии Татарского газетно-журнального издательства. 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.